В.Н.Рудницкая

# БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘПТӘ МАТЕМАТИКАДАН КОНТРОЛЬ ЭШЛӘР

1-3, 1-4 СЫЙНЫФЛАР



«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

**В. Н. Рудницкая**

# БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘПТӘ МАТЕМАТИКАДАН ТЕМАТИК ҺӘМ ЙОМГАКЛАУ КОНТРОЛЬ ЭШЛӘРЕ

*Методик ярдәмлек*

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2001

УДК 373.167.1:51
ББК 74.262.21
Р71

**Рудницкая В. Н.**

Тематические и итоговые контрольные работы по математике в начальной школе: Метод, пособие.— М.: Дроф, 1996.

**Рудницкая В. Н.**

Р71 Башлангыч мәктәптә математикадан тематик һәм йомгаклау контроль эшләре: Методик ярдәмлек /Русчадан Ф. М. Хафизова тәрж.— Казан: Мәгариф, 2001.— 199 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-0527-7

Ярдәмлектә математикадан өчьеллык һәм дуртьеллык башлангыч мәктәп программаларына туры китереп төзелгән язма контроль эшләр текстлары тупланган.

Контроль эшләр өч төрле катлаулылыктагы алты вариантта тәкъдим ителгән.

Ярдәмлектән гомуми белем мәктәпләрендә һәм гимназияләрдә, шулай ук математика тирәнтен өйрәнелә торган сыйныфларда яки мәктәпләрдә файдаланырга мөмкин.

БЗ—б(64)-77—98/99

ISBN 5-7761-0527-7

© Рудницкая В. Н., 1996
© Татарчага тәрҗемә,
«Мәгариф» нәшрияты, 2001

# КЕРЕШ СҮЗ

Укытучылар игътибарына тәкъдим ителә торган әлеге контроль эшләр өчьеллык һәм дүртьеллык башлангыч мәктәпләр өчен математика буенча дәүләт программаларына туры китерелеп төзелгән.

Укучыларга математика өйрәтеп, укытучы даими рәвештә аларның белемнәренә, күнекмәләренә, осталыкларына контроль ясый.

Укытучы билгеле бер шактый зур вакыт араларында үз укучыларының математик хәзерлек дәрәҗәләре торышы турында белергә тиеш. Практикада бу вакыт аралары уку чирекләренә туры килә. Һәр чирек азагында язма контроль эш үткәрелә, аның нәтиҗәсе укытучыга киләчәктәге эшне оештыру өчен юнәлдергеч булып тора. Мондый эшләрдәге биремнәр эчтәлеге буенча төрлечә булуы мөмкин: мәсәлән, исәпләү характерындагы биремнәр, арифметик текстлы мәсьәләләр, геометрик материал һ.б.

Чирек контроль эшләреннән тыш, һәр чирек «эчендә», программаның бик мөһим темалары укучылар тарафыннан ничек үзләштерелүен тикшерү өчен, бер яки ике эш үткәрү максатка ярашлы (мәсәлән, кушу яки тапкырлау таблицасын белү, арифметик гамәлләр башкаруның аерым алгоритмнарын үзләштерү, фигура мәйданын, хәрәкәт тизлеген исәпли белүне тикшерү). Кагыйдә буларак, мондый эшләр тәкъдим ителгән биремнәренең характеры буенча бертөрле, һәм алар укытучыга укучыларның белемнәре турында реаль фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

Яңа уку елын башлаганда, укытучы укучыларының хәзерлек дәрәҗәсен исәпкә алырга тиеш. Бу максаттан чыгып, сентябрьнең беренче атнасында һәр сыйныфта узган ел программасы буенча контроль эш (аны кереш эш дип атыйк) үткәрү файдалы.

Һәр сыйныфның контроль эшләр комплектында бер кереш эш, дүрт уку елы чирекләре буенча контроль эшләр һәм берничә тематик эш бар.

Һәр чирек азагында үткәрелә торган контроль эшләрнең һәркайсы бертөрле төзелгән: алар төп һәм өстәмә өлешләрдән тора.

Эшнең төп өлеше барлык балалар да үзләренең хәзерлек дәрәҗәләре буенча үти алырлык стандарт биремнәрне үз эченә ала.

Биремнәре йолдызчыклар белән билгеләнгән өстәмә өлешкә авыррак мәсьәләләр кертелгән. Алар, башлыча, чишү өчен укучыдан тапкырлык һәм мөстәкыйльлек таләп итә торган стандарт булмаган. биремнәрдән гыйбарәт.

Чирек азагында үткәрелә торган контроль эшне башкару өчен — 30—40 минут (1 йче сыйныфта 30 мин ка кадәр), ә тематик контроль эшләргә 26 минут вакыт бирелә.

Укытуда индивидуаль якын килү максатын тормышка ашыру өчен, һәр контроль эш тексты өч төрле катлаулылыктагы алты вариантта бирелгән.

Беренче ике варианты — математиканы авыр һәм уртача үзләштерүче укучыларга, өченче һәм дүртенче вариантлары — уртача «4»ле билгесенә үзләштерүчеләргә, ә бишенче һәм алтынчы вариантлары яхшы хәзерлекле, «5»ле билгесенә укып баручы укучыларга тәкъдим ителә.

Беренче сыйныфта укыта башлаган укытучы уку елы башында балаларның мәктәпкәчә булган математик хәзерлекләре торышы турында әле тулысынча белми. Шуңа күрә дә 1 нче сыйныф өчен кереш контроль эш текстлары барлык вариантлар өчен дә бер үк катлаулылыкта бирелә.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның барысы да балалар бакчасына йөрмәвен искә алып, 1 нче сыйныф өчен кереш контроль эштә балалар бакчасы программасы нигезендә балаларның математика буенча белемнәрен тикшерү максаты куелмый.

Берурынлы саннарны кушу һәм тапкырлау таблицаларын укучылар ничек үзләштерүен тикшерү максатыннан тәкъдим ителгән биремнәрнең 6 варианты да бер үк катлаулылыкта; бу тема һәр укучы тарафыннан аның өлгереш дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә үзләштерелергә тиеш.

Һәр контроль эш 6 варианттан тора. Ләкин бу — укытучы бер үк сыйныфта барлык вариантларны да кулланырга тиеш дигән сүз түгел. Конкрет шартлардан (аерым алганда, укучыларның математик хәзерлек дәрәҗәсеннән) чыгып, укытучы үз сыйныфы өчен вариантларны үз теләге белән сайлый ала. Мәсәлән, әгәр сыйныфта укучылар төрле хәзерлекле булсалар — беренче, өченче һәм бишенче вариантларны, әгәр сыйныф көчле булса, бишенче, алтынчы вариантларны тәкъдим итәргә мөмкин. Әгәр сыйныф уртача хәзерлекле булса, бишенче, алтынчы вариантларны бөтенләй кулланмаска мөмкин. Моннан тыш, сыйныфның һәм аерым укучыларның эш тизлеген исәпкә алып, укытучы, биремнәр санын арттырып яки киметеп, эш күләмен үзгәртә ала; шулай ук ул кайбер биремнәрне алыштыра ала.

Контроль эшләр укучыларга язмача башкару өчен бирелә, телдән исәпләү биремнәре язма эш текстлары эченә кертелгән.

Дәрестә укучылар бирелгән вакытка сыешсыннар өчен, контроль эш биремнәренең бер өлеше яки эш тулысынча укытучы тарафыннан алдан әзерләнгән индивидуаль карточкаларда башкарылуы мөмкин.

Һәр эшкә кыскача методик күрсәтмәләр бирелгән. Аларда эшнең максаты аңлатылган, программаның нинди темалары яки сораулары буенча укучыларның белемнәре тикшерелүе күрсәтелгән; җаваплар яки контроль эшнең өстәмә өлешендәге мәсьәләләрнең чишелешләре китерелгән.

Арифметик мәсьәләләрне чишүнең язу формасын, укытучы аерым күрсәтмә бирмәгәндә, укучы үзе сайлый ала (чишүне аерым гамәлләр ярдәмендә язу, аңлатма төзү һ.б.).

Укучыларның эшләре билгеләр куюның гамәлдәге нормалары буенча бәяләнә. Ләкин катнаш характердагы (мәсәлән, исәпләүләр һәм арифметик мәсьәлә) эшкә бер генә билге кую укучының белеме турында дөрес фикерләргә мөмкинлек бирмәвен укытучы исәпкә алырга тиеш. Мәсәлән, укучы барлык исәпләүләрне дөрес башкара, ләкин мәсьәлә чишкәндә арифметик гамәлне дөрес сайлый алмый. Бу очракта «3»ле билгесе генә куела. Ләкин бу укучыда мәсьәлә чишү сәләте формалашмаган, һәм аны уңай билге белән бәяләргә ярамый. Шуңа күрә мондый контроль эшләргә ике билге —берсен исәпләүләр, икенчесен мәсьәлә чишкәне өчен куярга кирәк.

Эшнең төп һәм өстәмә өлешләре шулай ук аерым бәяләнә. Төп өлешкә— «5», «4», «3» һәм «2» билгеләре, ә өстәмә өлешкә фәкать «5» һәм «4» билгеләре куела.

Язма контроль эшләрне бәяләү — катлаулы һәм бик четерекле эш. Укучы эшен тикшереп, укытучы хәзерге вакытта аның белемен, сәләтен һәм күнекмәләрен бәяләргә тиеш, җибәрелгән хаталар санына карап эшне бәяләү дөрес түгел. Мәсәлән, тикшерү моментына укучылар тапкырлау таблицасын яхшы белергә тиеш. Бу очракта «5», «4», «3» һәм «2» билгеләре белән эшләрне түбәндәге шкала буенча бәяләргә мөмкин: тәкъдим ителгән мисаллар 100%, дөрес чишелсә— «5»ле, 90% тан 99% ка кадәр—«4»ле, 60% тан 89% ка кадәр—«3»ле, 60% тан түбән булса, «2»ле билгесе белән бәяләнә.

Әгәр күнекмәләр әле формалашу дәрәҗәсендә генә булса, бәяләү шкаласы башкача булырга мөмкин (дөрес җавапларның проценты түбәнрәк булуы мөмкин). «4»ле билгесен — дөрес җаваплар 80—90%, ә «3»ле билгесен 50—80% булганда куярга мөмкин.

Укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен һәм сәләтләрен бәяләгәндә, төп күрсәткеч булып биремнең дөрес башкарылуы санала. Начар язганы өчен (геометрик төзүләрне — кисемтә, күппочмак һ.б. начар башкарган очраклардан тыш), грамматик хаталар өчен, язуның кабул ителгән формалары үтәлмәгән өчен

билгене төшермәскә кирәк, чөнки бу күрсәткечләр укучының математик хәзерлеген чагылдырмый.

Исәпләүләрне «рациональ» башкара белү, арифметик мәсьәләләрне «рациональ» чишү укучының математик үсешенең югары дәрәҗәсен сыйфатлый. Мондый осталык бик озак формалаша, һәм башлангыч мәктәптә 3—4 ел уку дәверендә генә барлык укучыларда ул формалашып бетмәскә дә мөмкин. Моны истә тотып, «рациональ» чишмәгән яки «рациональ булмаган» юл белән чишкән дип кенә билгене төшерергә ярамый.

Контроль эшләрне билгеләр белән бәяләүдән тыш, аларның сыйфат анализын үткәрү файдалы. Мондый анализ укытучыга кимчелекләрне, ялгышларны, укучыларның ялгыш фикер йөртүләрен бетерү буенча эшне дөрес планлаштыруга ярдәм итәр.

Укучылар тарафыннан башкарылган кайбер контроль эшләрнең нәтиҗәләрен анализлау схемасын китерәбез.

**1.** Кушу (тапкырлау) таблицасын үзләштерүне тикшерү.

Эшне кеше башкарган.
Барлык мисалларның җавапларын кеше дөрес язган.
Барлык мисалларның 90—99% ын кеше,
барлык мисалларның 60—89% ын кеше,
барлык мисалларның 60% тан кимен кеше дөрес чишкән.
Хата җибәргәннәр яки җавапларны язмаганнар:
бер-ике мисалда кеше,
барлык мисалларда кеше.

**2.** Арифметик гамәлләр башкару алгоритмнарын үзләштерүне тикшерү.

Эшне кеше башкарган.
Барлык мисалларны кеше дөрес чишкән.
Хата җибәргәннәр:
алгоритмнарны кулланганда _ ______ кеше,
кушу һәм тапкырлау таблицаларын кулланганда һәм аларга тиңдәш алу һәм бүлү очракларында кеше.

**3.** Тезмә аңлатмаларның кыйммәтләрен табу.

Эшне кеше башкарган.
Аңлатма кыйммәтен кеше дөрес исәпләгән.
Хата җибәргәннәр:
гамәлләр эшләү тәртибендә кеше,
исәпләүләрдә_____кеше.
Эшне башкара алмаганнар (алда саналган ике төр ялгыш җибәргәннәр) кеше.
Чишүне тәмамламаганнар____ кеше.
Чишәргә керешмәгәннәр____ кеше.

**4.** Арифметик мәсьәләләр чишү.

а) Гади мәсьәлә (арифметик гамәлне бер тапкыр куллану):
мәсьәләне чишкәннәр_ кеше,
тулысынча чишкәннәр____ кеше.
Хата җибәргәннәр:
арифметик гамәл сайлауда____ кеше,
исәпләүләр башкарганда____ кеше,
җавап язганда____ кеше.
Чишәргә керешмәгәннәр____ кеше.

б) Катлаулы мәсьәлә:
мәсьәләне чишкәннәр_ кеше,
мәсьәләне Дөрес чишкәннәр____кеше.
Хата җибәргәннәр (гамәлләр язылышында):
беренче гамәлне сайлаганда___кеше,
икенче гамәлне сайлаганда____ кеше.

I ιθр гамәлне сайлаганда____кеше,
мәсьәлә җавабын ялгыш язган (аңлатма язганда)_____кеше,
аңлатманы ялгыш төзегән_____кеше,
исәпләүләрдә кеше.
Мәсьәләне чишә алмаганнар____ кеше.
' I ишәргә керешмәгәннәр___ кеше.

**5.** Тигезләмәләр чишү.

Эшне башкарганнар____ кеше.
Тигезләмәне дөрес чишкән____ кеше.
Хата җибәргәннәр:
арифметик гамәл сайлауда____кеше,
исәпләүләрдә___ кеше.
Чишәргә керешмәгәннәр____ кеше.

**6.** Бирелгән озынлыкта кисемтә төзү.

Эшне башкарганнар____ кеше.
Тулысынча эшләгәннәр____ кеше.
Кимчелекләр җибәргәннәр:
кисемтәне төгәл төземәгәннәр _______ кеше,
кисемтә очларын билгеләмәгәннәр____ кеше.
Хата җибәргәннәр:
кисемтә озынлыгын дөрес сызмаганнар______ кеше,
кисемтә озынлыгын язганда_____кеше.
Кисемтә төзүгә керешмәгән____ кеше.

**7.** Турыпочмаклыкның периметрын (мәйданын) табу.

Эшне башкарганнар____ кеше.
Тулысынча эшләгәннәр____ кеше.

Хата җибәргәннәр:

турыпочмаклыкны (квадратны) дөрес сызмаганнар__ кеше.

Мәсьәлә чишкәндә:

периметр тапканда____кеше,

мәйдан тапканда____ кеше,

исәпләүләрдә____кеше.

Зурлык берәмлеген язганда:

периметр берәмлеген__кеше,

мәйдан___ кеше.

Чишүне тәмамламаганнар_____кеше.

Чишәргә керешмәгәннәр____ кеше.

Әгәр укытучы укучыларның контроль эшләре нәтиҗәләрен вариантлап анализларга кирәк дип санаса, тәкъдим ителгән схемага үзгәрешләр кертә ала.

Укучылар башкарган контроль эшләрдәге башка төрдәге биремнәр нәтиҗәләрен анализлау өчен, укытучы тиңдәшле схеманы үзе төзи ала.

# ДҮРТЬЕЛЛЫК МӘКТӘП

## БЕРЕНЧЕ СЫЙНЫФ

I ЧИРЕК

### Беренче контроль эш

Эшнең максаты — алты яшьлек беренче сыйныф укучыларының мәктәпкә кадәр алган математик күзаллауларының дәрәҗәсен ачыклау.

Контроль эшнең эчтәлеге түбәндәге биремнәрдән тора: аларда укучыларның натураль саннар турындагы күзаллаулары (бирелгән сандагы предметларны сурәтләү: өч флажок, дүрт кыяр һ.б.); таныш цифрларны яза белүләре; «шулкадәр» сүзенең мәгънәсен аңлаулары; геометрик һәм пространство күзаллаулары (формасын саклап, барлык детальләрен урнаштырып бирелгән рәсемне төгәл күчереп ясау, йомык яки йомык булмаган кәкре сызыкны күчереп ясау) тикшерелә.

Балалар рәсемнәрне кулдан ясыйлар. Эш өчен һәр баланың төсле карандашлары булырга тиеш (6 данә).

**Вариант 1**

1. Кызыл карандаш белән өч флаг рәсеме ясагыз.
2. Укытучы өстәлендәге уенчыкларны карагыз. Уенчыклар ничә булса, шуның кадәр яшел түгәрәкләр ясагыз.
3. Үзегез белгән барлык цифрларны языгыз.
4. Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 1).

**Вариант 2**

1. Яшел карандаш белән дүрт кыяр ясагыз.
2. Сул кулда ничә бармак булса, шулкадәр кызыл таяклар ясагыз.
3. Үзегез белгән барлык цифрларны языгыз.
4. Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 2).

**Вариант 3**

1. Төрле төстәге дүрт һава шары ясагыз.
2. Уң кулда ничә бармак булса, шулкадәр зәңгәр түгәрәкләр ясагыз.
3. Үзегез белгән барлык цифрларны языгыз.
4. Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 3).

**Вариант 4**

1. Өч слива ясагыз.
2. Сыйныфта ничә тәрәзә булса, шулкадәр яшел таяклар ясагыз.
3. Үзегез белгән барлык цифрларны языгыз.
4. Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 4).

**Вариант 5**

1. Төрле төстәге биш туп ясагыз.
2. Урындыкның аягы ничә булса, шулкадәр зәңгәр таяклар ясагыз.
3. Үзегез белгән барлык цифрларны языгыз.
4. Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 5).

**Вариант 6**

1. Кызыл карандаш белән өч помидор рәсеме ясагыз.
2. Песи баласының аягы ничә булса, шулкадәр яшел таяклар ясагыз.
3. Үзегез белгән цифрларны языгыз.
4. Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 6).

## I чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты — алты яшьлек беренче сыйныф укучыларының беренче чирек ахырына алган белем дәрәҗәләрен һәм күнекмәләрен тикшерү. Түбәндәге күнекмәләр тикшерелә:

— яссылыкта ориентлашу («сулдарак», «уңдарак», югарырак, хәзерлек дәрәҗәсе: «уң як өске почмак», «уң як аскы почмак», «сул як өске почмак», «сул як аскы почмак» сүзләренең мәгънәләрен аңлау);

— әйберләр күплеген аларның саны буенча чагыштыру, ягъни күплекләрнең кайсында әйберләр күбрәк (азрак) булуын ачыклау; тагын да югарырак дәрәҗәдә: берсендә икенчесенә караганда берничә предметка күбрәк яки азрак булган күплекне сурәтләргә;

— предметларны санау һәм аларны тиңдәшле цифр белән күрсәтү; тагын да югарырак дәрәҗәдә: тәкъдим ителгән рәсемдәге ситуациягә туры килерлек санны бирелгән тигезлекләр арасыннан сайлап алу.

Укучылар контроль эшләрне һәр вариант биремнәренә туры китереп алдан әзерләнгән аерым битләрдә яки карточкаларда башкаралар. Эш өчен укучыларга төсле карандашлар кирәк (6 данә).

Укучыларга биремнәр тәртип буенча телдән тәкъдим ителә. Киремне башкару өчен вакыт билгеләнә, ул вакыт үткәч, укытучы җитәкчелегендә берьюлы алдагы биремне башкарырга керешәләр.

Йолдызчык белән билгеләнгән авыррак типтагы биремнәргә махсус аңлатмалар бирелә.

**Вариант 1**

1. Сулдарак нәрсә урнашкан: чиләкме яки тупмы? Сулдарак урнашкан әйберне зәңгәр карандаш белән буягыз (рәс. 7).
2. Нәрсә күбрәк — түгәрәкләрме яки өчпочмаклармы? Күбрәк булган фигураларны кызыл карандаш белән буягыз (рәс. 8).
3. Гөмбәләр ничә (рәс. 9)? Тиеш цифр язылган түгәрәкләрне буягыз.

4*. Мәрҗәннәрне түбәндәге тәртиптә буягыз: кызыл, яшел, зәңгәр, шуннан соң тагын — кызыл, яшел, зәңгәр һәм шулай дәвам итегез (рәс. 10).

5*. Әбисе Наиләгә ике пар носки бәйләгән. Наиләгә әбисе ничә носки бәйләгән? Әбисе ничә носки бәйләгән булса, шакмак эченә шулкадәр сызык сызыгыз (рәс. 11).

**Вариант 2**

1. Уңдарак нәрсә урнашкан: чыршымы яки гөмбәме (рәс. 12)? Уңдарак урнашканын сары карандаш белән буягыз.
2. Нәрсә азрак: алмалармы яки грушалармы (рәс. 13)? Азрак булганын яшел карандаш белән буягыз.
3. Конфетлар ничә (рәс. 14)? Тиеш цифр язылган карточканы буягыз.

4*. Квадратларны түбәндәге тәртиптә буягыз: ике кызыл, бер яшел, шуннан соң тагын — ике кызыл, бер яшел һәм шулай дәвам итегез (рәс. 15).

5*. Кайсы сан зуррак: 4 ме яки 5 ме? Зуррак санлы карточканы кызыл карандаш белән буягыз (рәс. 16).

**Вариант 3**

1. Шардан уңдарак урнашырлык итеп, флагчык ясагыз (рәс. 17).
2. Кыярларны яшел карандаш белән буягыз (рәс. 18). Сливалар никадәр булса, шулкадәрле булырлык итеп, кыярлар өстәп ясагыз.

3. Цифр белән нинди сан күрсәтелсә, шулкадәрле прәнник ясагыз (рәс. 19).
4*. Ал иянең чикләвекләре 3 тән күбрәк һәм 5 тән азрак. Алиянең чикләвеге ничә? Бу чикләвекләрне шакмак эченә ясап куегыз (рәс. 20).
5*. Нинди дә булса дүртпочмак төзегез.

**Вариант 4**

1. Куяннан сулдарак булырлык итеп, кишер рәсеме ясагыз (рәс. 21).
2. Квадратлар ничә булса, шулкадәрле булырлык итеп, өстәп таяклар ясагыз (рәс. 22).
3. Цифр белән нинди сан күрсәтелсә, шулкадәрле алма ясагыз (рәс. 23).
4*. Салихка әнисе икенче номердан бишенче номерга кадәрле «Салават күпере» журналлары биргән. Салих ничә журнал алган булса, шулкадәрле таяк сызыгыз.
5*. Ишегалдында тавыклар йөри. Наил барлык тавыкларның аяклары 6 дип санап чыгарган. Ишегалдында ничә тавык йөрсә, шакмак эченә шулкадәрле түгәрәк ясап куегыз (рәс. 24).

**Вариант 5**

1. Шакмакның сул ягының өске почмагына өчпочмак, ә уң ягының аскы почмагына шар ясагыз (рәс. 25).
2. Өчпочмаклардан 2 гә кимрәк түгәрәкләр ясагыз (рәс. 26).
3. 27 нче рәсемгә туры килгән язуны сары карандаш белән буягыз.
4* . Фатирда ике бүлмә. Берсеннән ике бүлмә ясаганнар. Бүлмәләр саны ничә булса, шулкадәрле квадрат ясагыз.
5* . Гади карандаш белән 5 һава шары ясагыз. Зәңгәр шарлар сары шарлардан күбрәк булырлык итеп, шарларны зәңгәр һәм сары карандашлар белән буяп куегыз.

**Вариант 6**

1. Шакмакның сул ягының аскы почмагына флагчык, ә уң ягының өске почмагына түгәрәк ясагыз (рәс. 28).
2. Түгәрәкләрдән 3 кә артыграк итеп, өчпочмаклар ясагыз (рәс. 29).
3. 30 нчы рәсемгә туры килгән язуны кызыл карандаш белән буягыз.
4*. 6 китапны, берсендә икенчесенә караганда 2 китапка артыграк булырлык итеп, ике шүрлеккә урнаштырырга кирәк. Һәр китапны таяк белән сурәтләп, рәсемне ясагыз.

5*. Люстрада 5 лампочка. Беркадәр вакыттан соң аларның өчесе янып чыга. Ничә лампочканы алыштырырга туры килер? Җавапны цифр белән шакмак эченә языгыз (рәс. 31).

II ЧИРЕК

## «1 һәм 2 саннарын кушу һәм глу» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның 1 һәм 2 саннарын кушу һәм алуның (беренче дистә эчендә) таблицалы очракларын ничек үнләштерүләрен тикшерү.

Эшне балалар индивидуаль карточкаларда башкаралар.

### Вариант 1

Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 5 + 1= | 6 - 1 = | 9 - 2= |
| 2 + 1= | 3 - 1 = | 3 - 2= |
| 3 + 1= | 4 - 2 = | 2 + 2= |
| 3 + 2= | 5 - 2 = | 6 + 1= |

### Вариант 2

Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 1 + 1= | 9 - 1 = | 8 - 1= |
| 4 + 1= | 7 - 1 = | 8 + 1= |
| 9 + 1= | 3 - 2 = | 5 - 2= |
| 5 + 2= | 6 - 2 = | 9 - 2= |

### Вариант 3

Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 8 + 1 = | 5 - 1 = | 9 - 2= |
| 6 + 2 = | 6 - 1 = | 9 + 1= |
| 4 + 2 = | 10 - 2 = | 9 - 1= |
| 7 + 2 = | 8 - 2 = | 7 - 2= |

### Вариант 4

Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 3 + 1 = | 7 - 1 = | 6 - 2= |
| 5 + 1 = | 5 - 2 = | 9 - 1= |
| 8 + 2 = | 9 - 2 = | 8 - 2= |
| 3 + 2 = | 4 - 2 = | 7 + 2= |

**Вариант 5**

Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 7 + 1 = | 9 - 1 = | 8 - 2= |
| 8 + 2 = | 3 - 3 = | 6 + 2= |
| 5 + 2 = | 9 - 2 = | 7 - 2= |
| 4 + 0 = | 6 - 0 = | 5 - 5= |

**Вариант 6**

Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 7 + 1 = | 6 - 1 = | 9 - 9= |
| 7 + 2 = | 9 - 2 = | 6 + 2= |
| 9 + 0 = | 5 - 0 = | 10 - 2= |
| 10 - 1 = | 4 - 4 = | 8 - 0= |

## II чирек өчен контроль эш

Контроль эшкә укучыларның берурынлы саннарны цифр белән яза белүләрен, арифметик мәсьәләне чишү өчен кирәкле гамәлне (кушу яки алу) сайлый белүләрен һәм чишелешне тигезлек рәвешендә яза белүләрен тикшерергә ярдәм итүче биремнәр кергән.

Һәр вариантның арифметик мәсьәлә текстын укытучы башта үзе укырга тиеш. Бу вакытта бернинди дә күрсәтмәлелек (рәсемнәр, схемалар һ.б) кулланылмый.

**Вариант 1**

1. Карточкаларга рәттән 1 дән алып 6 га кадәрге саннарны (6 ны да кертеп) языгыз (рәс. 32).
2. Мәсьәләнең чишелешен языгыз:
   Өч слива булган, берсен ашаганнар. Ничә слива калган?

3*. Кош сүзендә өч хәреф. 1 хәрефкә артыграк булган сүз уйлап табыгыз һәм язып куегыз.

4*. Рөстәмнең 2 пар бияләе бар. Сул кулына ничә бияләй туры килә?

Искәрмәләр:

3*. Әгәр кайбер укучылар 3 нче биремне тиз эшләп бетерсәләр, аларга тагын шундый берничә сүз уйлап табарга һәм язарга тәкъдим итегез.

4*. Әгәр укучы җавапка 2 санын гына язып куйса, мәсьәлә чишелгән дип санарга.

**Вариант 2**

1. Карточкаларга рәттән 2 дән алып 7 гә кадәрге саннарны (7 не кертеп) языгыз (рәс. 33).
2. Мәсьәләнең чишелешен языгыз:
   5 юкә һәм 1 имән агачы утыртканнар. Ничә агач утыртканнар?

3*. Әнисе Алсуга конфетлар биргән. Ул 2 конфетны үзендә калдыра, 3 сен сеңлесенә бирә. Әнисе Алсуга ничә конфет биргән?

4*. Шакмакка иң кечкенә санны языгыз.

Искәрмә:

4*. Ихтимал, күп балалар 1 санын язарлар. Ләкин дөрес җавап булып 0 саны тора, чөнки 0 саны һәр натураль саннан кечкенә.

**Вариант 3**

1. Марат карточкаларга рәттән 1 дән алып 10 га кадәрге барлык саннарны яза һәм кайбер карточкаларны әйләндереп куя. Бу карточкаларга саннарны языгыз (рәс. 35).
2. Мәсьәләнең чишелешен языгыз:
   Мәрьямнең 5 аюы һәм 2 куяны бар. Мәрьямнең барысы ничә уенчыгы бар?

3*. Гаиләдә 4 бала. Кыз балалар ничә булса, ир балалар да шулкадәр. Кызлар ничә?

4*. Мичкәдән 2 тапкыр 2 шәр тулы чиләк су алалар. Мичкәдән ничә чиләк су алалар?

Искәрмәләр:

3*. Балалар җавапта 2 санын гына язулары мөмкин. Бу очракта мәсьәлә чишелгән дип санарга.
4*. Кайбер балалар җавапта 4 санын, ә кайберләре 2 + 2=4 дип язулары мөмкин. Һәр очракта да мәсьәлә чишелгән дип санарга.

**Вариант 4**

1. 10 нан алып 1 гә кадәрге саннарны кирегә санаганда ничек атыйлар, шул тәртиптә языгыз (рәс. 36).
2. Мәсьәләнең чишелешен языгыз:
   Тәрәзә төбендә 3 яшел помидор булган. Бер атнадан соң 2 помидор кызарган. Ничә яшел помидор калган?

3*. Кәрзиндә песи балалары утыра. Барлык песи балаларының 3 пар колаклары бар. Кәрзиндә песи балалары ничә?

4*. Тауда 6 бала шуып уйныйлар. Аларның икесе төшке ашка кайтып китә, ләкин ашаганнан соң алар тауга әйләнеп кайталар. Тауда ничә бала булды?

Искәрмәләр:

3*. Балалар кәрзиндә 3 песи баласы булуын гына чамаларга һәм җавапта 3 не язарга тиешләр.

4*. Мәсьәләне чишү өчен бернинди арифметик гамәл эшләргә кирәкми. Җавап: 6. Балалар 6-2 = 4 булган ялгыш чишелешне язулары ихтимал.

## Вариант 5

1. Һәркайсы 7 дән кечерәк булган дүрт сан языгыз (рәс. 37).
2. Мәсьәләнең чишелешен языгыз:
   Вазада 2 кызыл роза һәм шулкадәр үк ак роза бар. Вазада барысы ничә роза?

3*. Үрмәкүчнең 4 пар аягы бар. Үрмәкүчтә барысы ничә аяк?

4*. Азатның 2 тубы, ә Ниязның 3 тубы бар. Өстәлдә 4 туп сыярлык тартма бар. Малайлар тупларын тартмага урнаштыра алырлармы?

Искәрмә:

4*. Укучы җавапка «юк» дип язса, мәсьәлә чишелгән дип санарга. Ихтимал, кайбер укучылар тулырак җавап бирерләр: 3 + 2 = 5; 5 саны 4 тән зур (яки 4 саны 5 тән/кечкенә). Җавап: Юк.

## Вариант 6

1. Һәркайсы 3 тән зуррак булган биш сан языгыз (рәс. 38).
2. Мәсьәләнең чишелешен языгыз:
   8 стакан бар. 2 стаканга кофе салалар, ә калганнарына — сөт. Сөтле стаканнар ничә?

3*. Коңгызның 3 пар аягы бар. Коңгызның аяклары ничә?

4*. Кара тап белән нинди сан капланган (рәс. 39)? Шакмакка дөрес җавапны языгыз.

Искәрмә:

4*. Текстны укыгач, укытучы укучыларга тап астындагы санны чамаларга, ә аннан соң шакмак эченә язарга тәкъдим итә.

III ЧИРЕК

## «3 һәм 4 саннарын кушу һәм алу» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты булып укучыларның 10 эчендә (±3 һәм ±4) кушу һәм алуның таблицалы очракларын үзләштерү нәтиҗәләрен тикшерү тора. Эш индивидуаль карточкалар кулланып үткәрелә.

### Вариант 1

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 + 3 = | 4 + 3 = | 5 - 4 = | 6 - 4= |
| 5 + 3 = | 7 + 3 = | 6 - 3 = | 3 - 3= |
| 3 + 4 = | 3 + 0 = | 8 - 3 = | 10 - 3= |
| 4 + 4 = | 5 + 4 = | 4 - 4 = | 7 - 4= |

### Вариант 2

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 + 3 = | 6 + 4 = | 5 - 3 = | 9 - 3= |
| 4 + 5 = | 7 + 3 = | 6 - 4 = | 4 - 3= |
| 3 + 0 = | 6 + 3 = | 3 - 0 = | 4 - 4= |
| 3 + 3 = | 4 + 4 = | 7 - 4 = | 6 - 3= |

### Вариант 3

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 + 4 = | 7 + 3 = | 5 - 4 = | 10 - 4= |
| 3 + 4 = | 3 + 6 = | 7 - 4 = | 4 - 3= |
| 4 + 0 = | 3 + 3 = | 10 - 3 = | 4 - 4= |
| 3 + 7 = | 4 + 5 = | 9 - 4 = | 8 - 3= |

### Вариант 4

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 + 3 = | 6 + 4 = | 10 - 3 = | 9 - 4= |
| 6 + 3 = | 5 + 3 = | 6 - 4 = | 3 - 3= |
| 0 + 4 = | 4 + 3 = | 9 - 3 = | 7 - 4= |
| 3 + 7 = | 4 + 5 = | 7 - 0 = | 8 - 3= |

### Вариант 5

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 4 = | 3 + 6 = | 8 - 4 = | 10 - 3= |
| 3 + 3 = | 4 + 4 = | 5 - 0 = | 8 - 3= |
| 0 + 3 ≈ | 4 + 6 = | 7 - 4 = | 6 - 3= |
| 7 + 3 = | 3 + 5 = | 6 - 4 = | 9 - 4= |

## «Күбрәк» һәм «кимрәк» чагыштырмалары кергән мәсьәләләрне чишү темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты булып укучыларның «зуррак» һәм «кимрәк» сүзләренең мәгънәсен аңлауларын һәм мәсьәлә чишү өчен арифметик гамәлне (кушу яки алу) сайлый белүләрен тикшерү тора.

### Вариант 1

1. Пакетта 5 груша, ә сумкада пакеттагыга караганда 3 грушага күбрәк. Сумкада ничә груша?
2. Без 3 төрле газета, ә журналларны газеталарга караганда 2 гә кимрәк алабыз. Без ничә журнал алабыз?
3. Яшелчә бакчасыннан 5 шалкан, ә кишерләрне шалканга караганда 1 гә артыграк алып кергәннәр. Бакчадан ничә кишер алып кергәннәр?
4. Букетта 6 кыңгырау чәчәге, ә ромашкалар кыңгырау чәчәгенә караганда 1 гә кимрәк. Букетта ничә ромашка?

### Вариант 2

1. Кибеттә бер көн эчендә 8 үтүк, өстәл лампалары үтүкләргә караганда 2 гә кимрәк сатылган. Ничә өстәл лампасы сатканнар?
2. Өстәл өстендә китаплар һәм дәфтәрләр ята. Китаплар 6, ә дәфтәрләр китапларга караганда 2 гә артыграк. Дәфтәрләр ничә?
3. Балалар мәйданчыгында балалар уйныйлар. 5 кыз, ә малайлар кызларга караганда 1 гә артыграк. Малайлар ничә?
4. 9 әфлисун, әфлисуннарга караганда 3 кә кимрәк лимоннар сатып алалар. Ничә лимон сатып алганнар?

### Вариант 3

1. Алиягә 6 яшь, ә Сания Алиядән 2 яшькә зуррак. Саниягә ничә яшь?
2. Сул кесәдә 6 сум, ә уң кесәдә сул кесәдәгегә караганда 1 сумга кимрәк. Уң кесәдә ничә сум акча булган?
3. Әни 7 банка җир җиләге вареньесы, ә 3 банкага артыграк чия вареньесы кайнаткан. Әни ничә банка чия вареньесы кайнаткан?

4. Безнең бүлмәдә 6 урындык, креслолар урындыкларга караганда 4 кә кимрәк. Креслолар ничә?

**Вариант 4**

1. Вәлинең 8 сум, ә Камиләнең акчасы Вәлинекеннән 2 сумга артыграк. Камиләнең акчасы күпме?
2. Аидага 5 яшь, Азат Аидадан 2 яшькә кечерәк. Азатка ничә яшь?
3. Доктор Айболит Бармалейга валерьянка һәм витамин эчәргә кушкан: һәр көнне 3 таблетка валерьянка, ә витаминнарны 2 таблеткага артыграк. Бармалей ничә таблетка витамин кабул итәргә тиеш?
4. Мин китапханәдән 5 китап һәм китаплардан 1 гә кимрәк журналлар алдым. Китапханәдән мин ничә журнал алдым?

**Вариант 5**

1. Кадрия Вәлидән 3 яшькә зуррак. Вәлигә 7 яшь. Кадриягә ничә яшь?
2. Банкага сөт бидонга караганда 2 стаканга кимрәк керә. Бидонга 6 стакан сөт керә. Банкага күпме сөт керә?
3. Минем кесәдә ун сумлык акчалар биш сумлыклардан 3 кә артык. Биш сумлык акчалар 4 әү. Ун сумлык акчалар ничә?
4. Сукмак буйлап үрдәкләр һәм үрдәк бәбкәләре елгага баралар: бәбкәләр — 8, ә үрдәкләр 2 гә кимрәк. Үрдәкләр ничә?

**Вариант 6**

1. Дамирга 7 яшь, Вәли Дамирдан 3 яшькә кечерәк. Вәлигә ничә яшь?
2. Галия мәсьәләне 2 сәгать чишкән. Шигырьне 1 сәгатькә артыграк ятлаган. Галия шигырь ятлауга күпме вакыт сарыф иткән?
3. Әби үзенә свитер бәйләү өчен 6 йомгак җеп җитәр дип уйлаган, ләкин моның өчен 2 йомгакка артыграк җеп киткән. Свитер бәйләү өчен әбигә ничә йомгак җеп кирәк булган?
4. Банкага 6 стакан су салыйм дип уйлаган идем, ләкин банкага 2 стаканга кимрәк су керде. Банкага ничә стакан су керә?

## III чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның, кирәк булганда кушуның урын алыштыру законын кулланып, 0, 1, 2, 3, 4 саннарын куша белүләрен, шулай ук 0, 1, 2, 3, 4 саннарын ала һәм, мәсьәләләр чишкәндә, тиешле арифметик гамәл сайлый белүләрен тикшерү.

Вариант 1

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4+1= | 3+3= | 5-3= | 4-0= |
| 2 + 7= | 6 + 4= | 10-2= | 6-1 = |

2. Шакмак эченә тиешле санны языгыз (рәс. 40).
3. Инешнең сул ягында 4 тал агачы үсә, ә уң ярында 3 кә күбрәк. Инешнең уң ярында ничә тал агачы үсә?

4*. Иртән роза куагында 8 бөре булган. Көн уртасында, барлык бөреләр ачылып, матур розалар хасил була. Бу куакта ачылмыйча ничә бөре калган?

5*. Пакетта кызыл һәм сары алмалар булган. Пакеттан 5 кызыл һәм 4 сары алма алалар, шуннан соң пакет бушап калган. Пакетта барысы ничә алма булган?

Искәрмәләр:

4*. Мәсьәләнең җавабында 0 санын язарга тиешләр.

5*. Чишелеше: 4 + 5 = 9. Җавап: 9.

Вариант 2

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 2= | 3 + 6= | 10-1= | 8-2 = |
| 4 + 4 = | 4+3= | 9-3= | 6-4= |

2. Шакмак эченә тиешле санны языгыз (рәс. 41).
3. Әнисәнең 8 дәфтәре бар, ә Раилнең дәфтәрләре 3 кә кимрәк. Раилнең ничә дәфтәре бар?

4*. Муса урманга җиләк җыярга барган. Аның белән Кадрия һәм Галия дә барганнар. Урманга җиләк җыярга ничә бала барган?

5*. Дамир Азатны 2 партия шахмат уенында ота, ә Азат Дамирны 3 партиядә ота, 1 партияне ничьяга уйныйлар. Малайлар ничә партия шахмат уйнаганнар?

Искәрмә:

4*. Укучының җавабында 3 яки тигезлек рәвешендә (мәсәлән, 1 + 1 + 1 = 3 яки 1 + 2 = 3) язылган булса, мәсьәләне дөрес чишелгән дип санарга.

**Вариант 3**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6+3= | 4+5= | 7-0= | 10-3 = |
| 2+7= | 8+2= | 4-4= | 9-2= |

2. Рамка эченә язма дөрес булырдай сан языгыз:

4+□=6 ○ +3 = 7.

3. Камилгә 9 яшь. Алия Камилдән 4 яшькә кечерәк. Алиягә ничә яшь?

4*. Әти командировкага 4 февральдә кич китте, 10 февральдә иртән кайтты. Әти ничә көн өйдә булмады?

5*. Пакетта 4 алма, ә кәрзиндә шуның кадәрле 2 тапкыр алма бар. Кәрзиндә ничә алма? Мәсьәләнең чишелеше булган язуның астына сыз.

4 + 2 = 6; 4 + 4 = 8;
4-2 = 2; 2 + 2 + 2 + 2 = 8.

**Вариант 4**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 + 4= | 6 + 0= | 10-4= | 8-8 = |
| 3+3= | 4+5= | 7-3= | 7-2= |

2. Рамка эченә язма дөрес булырдай сан языгыз:

0+2=8; 1 +□ = 9.

3. Сарага 3 яшь, Муса Сарадан 3 яшькә зуррак. Мусага ничә яшь?

4*. Китап киштәсендә 10 томнан торган китап комплекты тора, китаплар рәттән тезелгән. Бишенче һәм унынчы томнар арасында ничә китап бар?

5*. Өч олы кешенең һәрберсе ике баланы кулыннан тотып бара. Барлык олы кешеләр белән бергә ничә бала бара? Мәсьәләнең чишелеше булган язуның астына сызыгыз.

3 + 2 = 5; 2 + 3 = 5;
3 + 3 = 6; 2 + 2 + 2 = 6.

**Вариант 5**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 + 4 = | 10 - 2 = | 9 - 4 = | 8 - 4 = |
| 3 + 5 = | 4 + 0 = | 2 + 8 = | 10 - 3 = |

2. Рамка эченә язма дөрес булырдай сан языгыз:

9 = 3+ ⌂;    7 = □ + 2.

3. Безнең өй 5 этажлы. Безнең өйгә каршы торган йорт 4 этажга биегрәк. Каршы йорт ничә этажлы?

4*. Алты ярты икмәктән ничә бөтен икмәк төзеп булыр?

5*. Юл буйлап бер-бер артлы 5 бала бара. Һәр малай артыннан, соңгысыннан башка, кыз бара. Юл буйлап ничә кыз бара?

Искәрмәләр:

4*. Кайбер укучылар җавапта 2 + 2 + 2 = 6 дип язулары һәм моннан тыш башка берни дә язмаулары мөмкин. Алар дөрес фикер йөрткәннәр, ләкин бу мәсьәлә соравына төгәл җавап түгел әле. Җавап та 3 булырга тиеш. Әгәр «6 = 2 + 2 + 2. Җавап: 3» дигән язма очраса, бу җавап дөрес, моны язган укучы мәсьәләне аңлап чишкән дип санарга була.

5*. Укучылар түбәндәгечә, фикер йөртергә тиешләр: соңгы булып килүче малай, малай алдында кыз, кыз алдында малай тора. Балалар саны 5 булгач, беренчесе дә малай булырга тиеш. Кызлар 2 була. Җавап: 2.

## Вариант 6

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 + 5= | 8 + 2= | 7-4= | 10-2 = |
| 8-3= | 3 + 4= | 6 + 0= | 1 + 9 = |

2. Рамка эченә язма дөрес булырдай сан языгыз:

10 = ○+ 6;    8 = 5+ □.

3. Әни бакчага иртәнге сәгать 9 да, ә без эти белән әнидән 2 сәгатькә алданрак киттек. Без эти белән бакчага сәгать ничәдә чыгып киттек?

4*. Кибет киштәсендә берничә карбыз бар. Әгәр өч сатып алучының һәркайсы 2 карбыз алса, карбызлар сатылып бетәчәк. Киштәдә ничә карбыз булган?

5*. Мин ике сан уйладым. Ул саннарны кушкач, 6 була. Аларның берсеннән икенчесен алгач та 6 була. Болар нинди саннар?

Искәрмә:

5*. Җавап: 6 һәм 0.

IV ЧИРЕК

## «Кушу таблицасы» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның 10 эчендә кушу таблицасын үзләштерүен тикшерү.

### Вариант 1

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 + 3= | 5 + 5 = | 6 - 5 = | 10 - 1 = |
| 1 + 8= | 2 + 2 = | 7 - 4 = | 9 - 6 = |
| 6 + 2= | 7 + 1 = | 8 - 6 = | 7 -7 = |
| 9 + 1= | 6 + 4 = | 9 - 7 = | 8 - 5 = |

### Вариант 2

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 + 0 = | 3 + 5 = | 7 - 6 = | 9 - 6= |
| 4 + 2 = | 6 + 3 = | 10 - 4 = | 7 - 5= |
| 9 + 1 = | 8 + 1 = | 8 - 5 = | 10 - 2= |
| 3 + 3 = | 6 + 4 = | 9 - 8 = | 8 - 7= |

### Вариант 3

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 3 = | 7 + 1 = | 9 - 6 = | 10 - 9= |
| 4 + 4 = | 8 + 2 = | 8 - 7 = | 8 - 5= |
| 1 + 0 = | 6 + 4 = | 7 - 5 = | 10 - 3= |
| 2 + 6 = | 2 + 3 = | 9 - 5 = | 7 - 6= |

### Вариант 4

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 + 1 = | 5 + 5 = | 7 - 6 = | 10 - 8= |
| 3 + 3 = | 7 + 2 = | 10 - 5 = | 9 - 8= |
| 6 + 4 ≡ | 0 + 4 = | 9 - 7 ≡ | 8 - 7= |
| 2 + 7 = | 2 + 8 = | 10 - 9 = | 7 - 5= |

### Вариант 5

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 + 8 = | 4 + 4 = | 10 - 8 = | 10 - 10 = |
| 6 + 2 = | 1 + 9 = | 9 - 6 = | 9 - 4 = |
| 4 + 5 = | 5 + 4 = | 7 - 5 = | 10 - 7 = |
| 3 + 7 = | 0 + 0 = | 8 - 7 = | 8 - 6 = |

**Вариант 6**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 + 2 = | 6 + 3 = | 8 - 5 = | 8 - 4= |
| 3 + 4 = | 5 + 4 = | 10 - 7= | 9 - 5= |
| 3 + 7 = | 9 + 1 = | 10 - 3 = | 7 - 6= |
| 8 + 0 = | 2 + 7 = | 8 - 6 = | 10 - 5= |

IV чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты — беренче сыйныф укучыларының уку елы ахырында белем дәрәҗәләрен ачыклау. Контроль эшкә бирелгән биремнәр ярдәмендә түбәндәгеләр тикшерелә: икенче дистә эчендә кушу һәм алу гамәлләрен эшли белү, кушу һәм алуга арифметик мәсьәләләр чишү һәм сантиметрларда кисемтә озынлыгын яза белү.

Вариант 1

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 10 + 6 = | 16 - 10 = | 14 - 10 = |
| 16-6= | 10 + 4= | 14-4 = |

2. Талия бер нарат агачы астыннан 3 гөмбә, икенчесе яныннан 7 гөмбә таба. Талия барысы ничә гөмбә тапкан?
3. Кисемтә озынлыгын сантиметрларда языгыз (рәс. 42).

4*. Тартмада 8 уенчык бар. Тартмада 5 уенчык калсын өчен, аннан ничә уенчык алып куярга кирәк?

5*. Дания бер сан уйлый, аңа 5 не кушкач, 15 саны килеп чыга. Дания нинди сан уйлаган?

Вариант 2

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 10 + 3 = | 13 - 10 = | 17 - 10 = |
| 13-3= | 10 + 7= | 17-7 = |

2. Бер тәлинкәдә 4 алма, ә икенчесендә 6 алма. Ике тәлинкәдә ничә алма?
3. Кисемтә озынлыгын сантиметрларда языгыз (рәс. 43).

4*. Гаиләдә ике бала. Самат — Йолдызның абыйсы, ә Йолдыз Саматның ир туганы түгел. Болай булуы мөмкинме? Йолдыз кем була соң?

5*. Алмагачта 10 алма булган. Бакчачы балаларга берәр алма өзеп биргәч, алмагачта 6 алма калган. Балалар ничә?

Искәрмә: 4*. Кыз туган.

Вариант 3

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 16 - 6 = | 13 - 10 = | 10 + 6 = |
| 12 - 2 = | 18 - 10 = | 10 + 1 = |

2. Ана куян балаларына 6 кишер бирә: зурысына — 4 не, калганнарын — төпчегенә. Төпчек баласына ана куян ничә кишер биргән?
3. Кисемтә озынлыгын сантиметрларда языгыз (рәс. 44).
4*. Зур квадратны яклары 1 см озынлыктагы бердәй кечкенә квадратларга кискәләгәннәр (рәс. 45). Бу Квадратларны яклары белән бер-берсенә терәп, лента ясалырлык итеп тезәләр. Лентаның озынлыгын сантиметрларда языгыз.
5*. Поезд ун вагоннан тора. Самат поезд башыннан исәпләгәндә — бишенче вагонга, ә Фәрит арттан бишенче вагонга утыра. Алар бер вагонда баралармы? Дөрес җавапның астына сызыгыз. 1) Әйе. 2) Юк.

Вариант 4

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 14 - 4 = | 19 - 10 = | 10 + 9 = |
| 17-7 = | 15 - 10 = | 10 + 8 = |

2. Фәрит 5 хат язган: икесен дусларына җибәргән, ә калганнарын әтисе белән әнисенә Кырымга җибәргән. Фәрит Кырымга ничә хат җибәргән?
3. Кисемтә озынлыгын сантиметрларда языгыз (рәс. 46).
4*. Шоколад плиткасы 6 квадрат өлештән тора (рәс. 47). Аерым өлешләргә бүлү өчен, бу плитканы ничә тапкыр сындырырга кирәк?
5*. Нияз — Наилнең улы, Наил — Мәхмүтнең улы. Нияз Мәхмүтнең кеме була?

Искәрмә:

5*. Җавап: Оныгы.

Вариант 5

I. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 7 + 10 = | 10 + 9 = | 14 - 10 = |
| 20 - 10 = | 15 - 5 = | 19 + 1 = |

2. Ювелир 10 балдак ясаган. Аларның 7 се — көмеш, калганнары — алтын. Ювелир йичә алтын балдак ясаган?
3. Кисемтә озынлыгын сантиметрларда языгыз (рәс. 48).
1*. Бакчада алмагачлар груша агачларыннан 3 кә артыграк. Алмагачлар — 7. Груша агачлары ничә?

5*. Китапның берничә бите төшкән. Беренче биттә — 5, соңгысында 10 номеры тора. Китаптан ничә бит төшкән?

Искәрмә:

5*. Кайбер укучылар ялгыш: 10 - 5 = 5 дип язарлар. Дөрес җавап: 3 бит.

**Вариант 6**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 8 + 10 = | 10 + 10 = | 16 + 1 — |
| 19 - 10 = | 11 - 10 = | 18 - 1 = |

2. Вагонда 10 офицер бара: аларның дүртесе — майор, калганнары — капитан. Вагонда капитаннар ничә?
3. Кисемтә озынлыгын сантиметрларда языгыз (рәс. 49).
4. Зәкиянең открыткалары Галиянекеннән 4 кә кимрәк. Зәкиянең открыткалары 6. Галиянең открыткасы ничә?

5*. Мине Наил Вәлиевич дип, ә бабайны (әтинең әтисен) Закир Кәримович дип йөртсәләр, әтине кем дип атыйк?

Искәрмә:

5*. Җавап: Вәли Закирович.

## ИКЕНЧЕ СЫЙНЫФ

### I ЧИРЕК

### Кереш контроль эше

Эшнең максаты булып 1 нче сыйныф математика курсының бик мөһим мәсьәләләренең укучылар тарафыннан үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү тора. Түбәндәгеләр тикшерелә: нульне дә кертеп 10 эчендә кушу һәм алу таблицаларын белү, кушу һәм алуга гади арифметик мәсьәләләр (арифметик гамәлләрнең мәгънәсен аңлауга мәсьәләләр, шулай ук санны берничә берәмлеккә арттыру һәм кимүгә мәсьәләләр) чишә белү.

**Вариант 1**

1. Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 5 + 2 = | 9 + 1 = | 1 - 1= |
| 4 + 3 = | 3 + 4 = | 5 - 0= |
| 6 + 0 = | 6 - 1 = | 7 - 4= |
| 2 + 7 = | 8 - 2 = | 6 - 3= |

2. 5 күлмәк һәм 4 кофта теккәннәр. Ничә әйбер теккәннәр?
3. Кибет киштәсендә 7 кавын бар. 2 кавынны без сатып алдык. Киштәдә ничә кавын калган?
4*. Кушу нәтиҗәсендә 1 чыгарлык ике сан уйлагыз һәм языгыз.
5*. Тәнәфестә безнең сыйныфның барлык 8 малае да ишегалдына чыктылар. Ишегалдында барлыгы 10 малай булды. Алар арасында башка сыйныфтан һич югында бер малай булганмы? Өч җавап арасыннан берне, дөресен сайлап алыгыз һәм аны язып куегыз: 1) Юк. 2) Әйе. 3) Билгесез.

## Вариант 2

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 + 1 = | 7 + 2 = | 9 - 3 = | 5 - 4= |
| 9 + 0 = | 6 + 3 = | 8 - 2 = | 10 - 1= |
| 4 + 4 = | 5 + 4 = | 6 - 0 = | 7 - 3= |

2. Бакчадан 7 стакан кура җиләге һәм 3 стакан кара карлыган җыеп кергәннәр. Ничә стакан җиләк җыеп кергәннәр?
3. Базга 7 басмалы баскычтан төшәргә кирәк. Мин 4 басмасын үттем инде. Тагын ничә басмасын төшәсе калган?
4*. Аждаһа тимерчегә үзенең сарае өчен 3 йозак, һәр йозак өчен 3 ачкыч эшләргә куша: бакыр, көмеш һәм алтынны. Тимерче ничә ачкыч ясарга тиеш булган?
б*. Кәгазь битен урталай бөкләгәннәр, шуннан соң тагын урталай бөкләгәннәр һәм бөкләү сызыклары буенча кәгазьне кискәннәр. Ничә кисәк барлыкка килгән?

Искәрмәләр:
4*. Чишү: 3 + 3 + 3 = 9. Җавап: 9.
5*. Җавап: 4.

## Вариант 3

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 4 = | 7 + 0 = | 10 - 7 = | 9 - 8= |
| 8 + 2 = | 2 + 6 = | 6 - 4 = | 7 - 4= |
| 3 + 7 = | 3 + 4 = | 8 - 6 = | 1 - 0= |

2. 4 пачка һинд чәе, шулкадәр үк Краснодар чәе сатып алганнар. Ничә пачка чәй сатып алганнар?

3. Әни 8 бөккән пешергән: 3 се кәбестә белән, ә калганнарын повидло белән. Әни повидло белән ничә бөккән пешергән?
4*. Бауның очларын бәйләмичә калдырып, бауда 3 төен бәйләделәр. Бу төеннәр бауны ничә кисәккә бүлгән?
5*. Бүлмәдә, 8 баланы утыртып бетерү өчен, ике урындык җитми. Бүлмәдә ничә урындык бар?

**Вариант 4**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 + 9 = | 7 + 3 = | 9 - 3 = | 8 - 5= |
| 0 + 1 = | 8 + 2 = | 9 - 2 = | 7 - 3= |
| 4 + 5 = | 0 + 8 = | 10 - 1 = | 10 - 4= |

2. Сәвиянең 5 курчагы бар, Саниянең курчагы да шулкадәр. Ике кызның ничә курчагы бар?
3. 7 йомырканың 3 сен пешердем. Ничә йомырка калды?
4*. Тактаны 4 кисәккә бүлү өчен, карандаш белән ничә тамга салырга кирәклеген табыгыз.
5*. Акча тартмасына берничә сум акча салсам, 10 сум акчам кала. Әгәр минем бер 10 сумлык һәм бер 5 сумлык акчам булса, акча тартмасына күпме акча салырмын?

И с к ә р м ә:

5*. Мәсьәләне чишү өчен, бернинди арифметик гамәл башкарырга кирәк түгел. Тартмага 5 сум акча салынганын укучылар җиңел аңларга тиеш. Кайбер укучылар нindидер исәпләүләр ярдәмендә чишәргә тырышып карарлар.

**Вариант 5**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 + 0 = | 5 + 4 = | 9 - 7 = | 6 - 3= |
| 4 + 6 = | 3 + 7 = | 8 - 5 = | 10 - 8= |
| 7 + 2 = | 4 + 5 = | 4 - 4 = | 9 - 5= |

2. Яшел тасманың озынлыгы 8 см, сары тасма аннан 2 см га озынрак. Сары тасманың озынлыгын табыгыз.
3. Маркалары булмаган 10 конверт сатып алганнар, 4 сенә марка ябыштырганнар. Марка ябыштырылмаган ничә конверт калган?
4*. Тартмага 10 кызыл мәрҗән яки 6 яшел мәрҗән сыя. Кайсы мәрҗәннәр ваграк: кызылларымы яки яшелләреме?

5*. 9 * 0 = 9 язмасы дөрес булсын өчен, йолдызчык урынына нинди тамга (+ яки -) язарга мөмкин? Дөрес язмалар языгыз.

Искәрмә:

5*. Бу очракта ике тамга язарга мөмкин: 9 + 0 = 9 һәм 9 - 0 = 9.

**Вариант 6**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 + 2= | 7 + 3= | 10-6= | 9-6 = |
| 3 + 6 = | 2 + 6 = | 7- 7 = | 8 - 5 = |
| 4 + 5= | 0 + 0= | 8-4= | 10-7 = |

Кунакта без тулы бер атна һәм тагын 3 көн тордык
Кунакта без ничә көн булганбыз?

3. Алиянең акча янчыгында 10 сум акчасы булган. Аннан ул 3 сум акчасын алып, калганнарын кесәсенә салган. Алия кесәсенә күпме акча салган?

4*. Паркта яшел һәм зәңгәр 4 эскәмия бар. Яшел эскәмияләр зәңгәрләреннән күбрәк. Һәр төстәге эскәмияләр ничә?

5*. Ящикта яшел һәм сары грушалар ята. Карамыйча гына ящиктан 2 груша алганнар. Алган грушалар бер генә төстә булыр дип уйлау дөресме? Өч җавапның дөрес дип саналганын сайлап алыгыз һәм язып куегыз: 1) Әйе. 2) Юк. 3) Билгесез.

Искәрмә:

4*. Беренче карашка мәсьәлә аныксыз булып күренүе мөмкин. Ләкин аның бер генә чишелеше бар: яшел эскәмияләр — 3, зәңгәрләре — 1. Җавап: 3 һәм 1.

## «Берурынлы саннарны кушу таблицасы» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның кушу таблицасын, шулай ук таблицалы алу нәтиҗәләрен үзләштерүне тикшерү.

**Вариант 1**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 + 2 = | 3 + 8 = | 11 - 2 = | 13 - 9 = |
| 8 + 4= | 4 + 7= | 12-6= | 11-8 = |
| 7 + 5 = | 6 + 5 = | 14 - 7 = | 11 - 5 = |

**Вариант 2**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 + 4 = | 8 + 5 = | 11 - 3 = | 12 - 5 = |
| 6 + 6= | 6 + 9= | 13-8=' | 14-7= |
| 9 + 3= | 7+7= | 14-9=' | 11-9 = |

**Вариант 3**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 + 4 = | 3 + 8 = | 11 - 4 = | 12 - 4 = |
| 8 + 3 = | 9 + 4 = | 15 - 6 = | 13 - 7 = |
| 9 + 3 = | 5 + 6 = | 12 - 7 = | 14 - 8 = |

**Вариант 4**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 + 8= | 6 + 8= | 11-5= | 12-3 = |
| 9 + 9 = | 7 + 5 = | 15 - 7 = | 13 - 6 = |
| 9 + 5 = | 6 + 9 = | 12 - 8 = | 17 - 9 = |

**Вариант 5**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 + 8 = | 7 + 6 = | 11 - 6 = | 12 - 9 = |
| 8 + 5= | 5 + 9= | 13-5= | 16-7 = |
| 4 + 9 = | 9 + 7 = | 15 - 8 = | 18 - 9 = |

**Вариант 6**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 + 7 = | 5 + 8 = | 11 - 4 = | 13 - 7 = |
| 9 + 7= | 9 + 4= | 16-9= | 17-8 = |
| 6 + 8 = | 7 + 6 = | 11 - 7 = | 15 - 9 = |

## I чирек өчен контроль эш

Контроль эш максаты булып укучыларның исәпләү күнекмәләрен тикшерү, яңа төрдәге бер гамәлле арифметик мәсьәләләр чишү осталыгын, линейка ярдәмендә бирелгән озынлыктагы кисемтә төзи белүләрен тикшерү тора.

**Вариант 1**

1. 6 һәм 4 саннарының суммасын һәм аермасын языгыз һәм исәпләгез.
2. Гамәлләрне эшләгез: 4 + 5 + 3.
3. Аш пешерү өчен 2 суган һәм 6 бәрәңге алганнар. Бәрәңгене суганга караганда ничәгә артыграк алганнар?

4. 4 см озынлыгындагы кисемтә сызыгыз.

5*. Доктор Айболитка күренү өчен 6 авыручы чират көтеп торалар икән. Доктор башта тешләре бик каты сызлаганнарын кабинетка чакырган. Өченче һәм бишенче авыручылар кабинетка кергәннәр. Чиратларын көтеп, тагын ничә авыручы калган?

6*. Нияз һәм Сания тугыз этажлы йортта яшиләр. Нияз Саниягә караганда югарырак этажда яши. Сания җиденче этаждагы бүлмәдә яшәсә, Нияз яшәгән бүлмә ничәнче этажда булуы мөмкин?

Искәрмәләр:

4. Әгәр кисемтә пөхтә, линейка белән төгәл, бирелгән озынлыкта (теге яки бу якка тайпылыш тик 1—2 мм булуы мөмкин) төзелсә, очлары ноткалар яки кечкенә штрихлар ярдәмендә билгеләнсә, бирем дөрес башкарылган дип санала.

6*. Әгәр укучы җавапны «8 нче этажда яки 9 нчы этажда» дип язса, җавап дөрес була. Әгәр укучы бер генә этажны, мәсәлән, «8 нче этажда» яки «9 нчы этажда дип язса, җавап тулы булмый.

**Вариант 2**

1. 8 һәм 3 саннарының суммасын һәм аермасын языгыз һәм исәпләгез.
2. Гамәлләрне эшләгез: 7-3 + 8.
3. Киләсе атнада кинотеатрда олылар өчен 4 кинофильм һәм балалар өчен 7 мультфильм күрсәтеләчәк. Олылар өчен фильм балаларныкына караганда ничәгә кимрәк күрсәтеләчәк?
4. 8 см озынлыгындагы кисемтә сызыгыз.
5. Вәли урманда 17 гөмбә (ал гөмбәләр һәм каен гөмбәләре) тапкан. Ул, миндә каен гөмбәләре ал гөмбәләр кадәр, дип әйткән. Вәли ялгышмаганмы? Өч җавап арасыннан дөресен сайланмалыгыз һәм шул сүзнең астына сызыгыз: 1) Ялгышкан. 2) Ялгышмаган. 3) Белмим.

6*. Винни-Пух белән Мыркылдык Куянкайда кунакта булалар. Куянкайның шкафында 5 чүлмәк бал һәм 2 банка вареньесы була. Башта барлык вареньены, ә соңыннан 3 чүлмәк балны ашап бетерәләр. Куянның бер генә чүлмәк балы булса да калганмы?

Искәрмә:

6*. Кайбер укучылар 5-3 = 2 дип язып алу гамәлен эшләрләр һәм җавап дип 2 санын язарлар. Ләкин бу чын җавап түгел. Мәсьәләдә «күпме...» дип соралмый, «калганмы...» дип сорала. Бу сорауга җавап: «Әйе» яки «Калган» дигән җавап дөрес булыр.

Вариант 3

1. 7 һәм 0 саннарының суммасын һәм аермасын табыгыз.
2. Гамәлләрне эшләгез: 9-5 + 6.
3. Безнең гаиләдә дүрт олы кеше һәм. алты бала бар. Балалар олыларга караганда ничәгә артык?
4. 5 см озынлыгындагы кисемтә сызыгыз.

5*. Язма дөрес булсын өчен, өчпочмаклы шакмакларга нинди цифр язарга кирәк (рәс. 50)?

6*. Велосипед тәгәрмәченең 8 тырнагы бар. Тырнаклар арасында аралыклар күпме?

Искәрмә:

5*. Җавап: 1.

Вариант 4

1. 9 һәм 9 саннарының суммасын һәм аермасын табыгыз.
2. Гамәлләрне эшләгез: 14-7-5.
3. Букетта 5 сары һәм 8 ак<роза бар. Сары розалар акларыннан ничәгә кимрәк?
4. 10 см озынлыгындагы кисемтә сызыгыз.

5*. Чуртан, корбан һәм алабуга балыкларын сатып алганнар. Чуртан корбаннан авыррак, корбан алабугадан авыррак. Балыкларның кайсысы иң җиңел?

6*. 51 нче рәсемдәге барлык кисемтәләрне санап чыгыгыз. Алар ничә?

Искәрмә:

6*. Рәсемдә барысы 6 кисемтә. Кисемтә очлары номерланган, шуңа күрә кисемтәләрне санавы җиңел. Сул очлары 1 цифры белән билгеләнгәннәрен саныйбыз (алар өчәү). Шуннан соң 2 цифры белән билгеләнгәннәрен саныйбыз (алар икәү). Олы 3 ноктасында булган кисемтә берәү. Барысы: 3 + 2 + 1 —- 6, ягъни 6 кисемтә.

Вариант 5

1. 10 һәм 3 саннарының суммасын һәм аермасын языгыз. Сумма аермадан күпмегә зуррак?
2. Гамәлләрне эшләгез: 10 + 5-6.
3. Банкадан 5 стакан чия компотын агызып алганнар Шуннан соң банкада 7 стакан компот калган. Банкада барысы ничә стакан компот булган?
4. 7 см озынлыгындагы кисемтә сызыгыз.
5. Зур читлектә 6 попугай, кечкенәсендә 5 попугай булган. Зур читлектән кечерәгенә 1 попугайны күчергәннәр Читлекләрдә попугайлар саны тигез булдымы?

6*. Бу атнада әбисендә Галия — чәршәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә, ә Ләбибә пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе көннәрендә кунакта булган. Оныкларның берсе генә булса да әбиләрендә ничә көн кунакта була?

Искәрмәләр:

5*. Җавап: Юк (Тигез түгел).

6*. «Берсе генә булса да» дигән сүзләр әбисендә кунакта я Галия, я Ләбибә, яки кызларның икесе дә дигәнне аңлата. Шуңа күрә, җавап 5 саны булыр (чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе).

Вариант 6

1. 8 һәм 4 саннарының суммасын һәм аермасын языгыз. Аерма суммадан күпмегә кимрәк?
2. Гамәлләрне эшләгез: 15-8 — 7.
3. Шугалактан 4 малай өйләренә кайтып киткән, калган 6 малай шууларын дәвам иткәннәр. Шугалакта башта ничә малай булган?
4. 6 см озынлыгындагы кисемтә сызыгыз.

5*. Кәрзиндә һәм пакетта 6 шар әфлисун булган иде. 1 әфлисунны, кәрзиннән алып, пакетка салганнар. Кәрзиндә пакетка караганда әфлисуннар ничәгә кимрәк калган?

6*. Миндә өч фотография бар. Ике фотографиядә — минем әни, икесендә мин үзем төшкәнмен. Болай булуы мөмкинме?

Искәрмәләр:

5*. Күп укучылар кәрзиндә 1 әфлисунга кимрәк дип уйларга мөмкин, чөнки 1 әфлисунны алып салганнар. Ләкин бу алай түгел. Кәрзиндә 2 әфлисунга кимрәк булыр.

6*. Җавап: Әйе, мөмкин. Бер фотографиядә ике кеше (мин һәм минем әни) сурәте бар.

## II ЧИРЕК

### «Кушу һәм алу» темасы буенча контроль эш

Контроль эштә укучыларның 100 эчендә дистә аша чыкмыйча 30 ± 20, 25 ± 3, 43 ± 20, 76 - 70, 67 — 7, 30 + 6 һ.б. очракларда саннарны кушу һәм алу гамәлләрен башкара белүләре тикшерелә.

Вариант 1

Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 + 5 | 26 + 2 | 76 - 70 | 60 - 40 |
| 30 + 20 | 70 + 13 | 28 - 8 | 37 -6 |

**Вариант 2**

Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 50 + 5 | 46 + 3 | 36 - 20 | 80 - 40 |
| 70 + 20 | 80 + 17 | 39 - 9 | 56 - 4 |

**Вариант 3**

Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 60 + 2 | 75 + 4 | 29 - 20 | 32 - 20 |
| 48 + 30 | 67 + 3 | 55 - 5 | 45 - 3 |

**Вариант 4**

Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 70 + 4 | 81 + 7 | 49 - 30 | 29 - 10 |
| 30 + 35 | 24 + 5 | 68 - 4 | 56 - 3 |

**Вариант 5**

Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 45 + 3 | 35 + 5 | 47 - 5 | 40 - 4 |
| 62 + 20 | 30 + 70 | 51 - 30 | 100 - 7 |

**Вариант 6**

Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 54 + 2 | 42 + 8 | 29 - 7 | 50 - 5 |
| 76 + 10 | 60 + 40 | 92 - 60 | 100 - 9 |

## II чирек өчен контроль эш

Контроль эшкә җәяле аңлатмаларның кыйммәтен исәпләгәнд тәртип кагыйдәләрен куллана белүне, текстлы арифметик мәсь әләләр (билгесез кушылучыны һәм билгесез киметүчене табу) һәм шулай ук ике гамәлле төзмә мәсьәләләр чишә белүне тикшерергә ярдәм итүче биремнәр кертелгән.

**Вариант 1**

1. Исәпләгез: 6 - (2 + 3).
2. Кисәктә 10 м ситсы булган. Сарафан теккәннән со кисәктә 6 м ситсы калган. Сарафан тегү өчен күп ситсы киткән?
3. Безнең бакчада 9 алмагач бар. Төшкә кадәр без 3 алмагачтан, төштән соң 5 алмагачтан алма җыйдык. Ничә алмагачтан алма җыясы калган?

4*. Иң зур һәм иң кечкенә икеурынлы сан языгыз.

5*. Мин 15 кг нан артмаган йөкне күтәрә алам. 15 кг ны (әйе, юк), 20 кг ны (әйе, юк), 13 кг ны (әйе, юк) күтәрә алырмынмы? Дөрес җавапның астына сызыгыз.

Вариант 2

1. Исәпләгез: 10-(5 + 2).
2. Бидонда 5 л квас булган. Квасның бер өлешен эчкәч, бидонда 2 л квас калган. Ничә литр квас эчкәннәр?
3. Залда 8 кресло булган. 2 иске креслоны залдан чыгарганнар һәм яңа 4 кресло керткәннәр. Залда ничә кресло булды?

1*. Өч икеурынлы сан уйлагыз һәм языгыз.

5*. Фигуралы шуу мәктәбенә 7 яшьтән зур булмаган балаларны кабул итәләр. Әгәр миңа хәзер 5 яшь булса, киләсе елга мине бу мәктәпкә алырлармы?

Вариант 3

I. Исәпләгез: 15 + (9 - 4).
2. Сумкага мин 3 кг яшелчә, берничә килограмм җиләк-җимеш салдым, барысы 10 кг булды. Сумкага мин ничә килограмм җиләк-җимеш салдым?
3. Гаражда 9 машина булган. Башта гараждан 2 машина, соңыннан тагын 4 машина чыгып китә. Гаражда ничә машина калган?

4*. Язылышы нуль белән тәмамланучы ничә икеурынлы сан бар? Шундый барлык саннарны языгыз.

5*. Динәгә үзендә ничә китап булса, шуның кадәрле китап бүләк иткәннәр. Моннан соң китаплары 10 булган. Динәнең башта ничә китабы булган?

Искәрмә:

I*. Андый саннар тугыз: 10, 20, 30, 40, 50, 60, 70, 80, 90.

Вариант 4

1. Исәпләгез: 7 + (8 - 2).
2. Тукталышта трамвайга 3 кыз һәм берничә малай — барысы 8 бала кергән. Трамвайга ничә малай кергән?
3. Китапта 25 бит. Ирек кичә китапны укый башлап 8 битен, бүген 7 битен укыган. Ирекка китапның ничә битен укыйсы калган?

4*.5 цифры белән башланучы икеурынлы саннар ничә? Шундый саннарның барысын да языгыз.

Бертөрле ике бәлешнең массасы бер торт массасы кадәр.

Бәлешнең массасы 1 кг. Тортның массасы нинди?

Искәрмә:
4*. Җавап: 10 сан: 50, 51, 52, 53, 54, 55, 56, 57, 58, 59.

Вариант 5

1. Исәпләгез: 80 - (60 + 20).
2. Әни салкын суга 3 йомырка салып пешерергә куйган. 5 минуттан соң кастрюльдәге су кайнап чыккан, ә тагын берничә минуттан соң йомырка пешеп өлгергән. Йомыркаларны пешерү өчен барысы 7 минут вакыт киткән. Кастрюльдә су ничә минут кайнаган?
3. Ике тасма сатып алганнар. Ак тасманың озынлыгы 8 м, зәңгәре агыннан 1 м га кыскарак. Ике төстәге тасмаларның озынлыгы ничә метр?

4*. Язылышында ике бертөрле цифрлар булган ничә икеурынлы сан бар? Шундый барлык саннарны языгыз.

5*. Буратино үзенең барлык алтын тәңкәләренең яртысын төшке аш өчен түләгән, ә калган 3 тәңкәсен җиргә күмеп куйган. Буратиноның ничә тәңкәсе булган?

Искәрмә:
4*. Җавап: Тугыз сан: 11, 22, 33, 44, 55, 66, 77, 88, 99.

Вариант 6

1. Исәпләгез: 90 - (80 - 10).
2. Урман буенда 6 куян уйнап йөргән. Алар янына, урманнан чыгып, тагын берничә куян килеп кушылган һәм алар барлыгы 11 булганнар. Урманнан ничә куян чыккан?
3. Универмагта 10 кул машинасы һәм 10 аяк тегү машинасы булган. 8 машинаны сатканнар. Ничә машина калган?

4*. 90 нан зуррак һәм 100 дән кечерәк булган ничә икеурынлы сан бар? Шундый барлык саннарны языгыз.

5*. Абыйсының 5 чикләвеге булган. Сеңлесенең берничә чикләвеге булгач, абыйсы аңа бер чикләвек биргән. Шуннан соң абыйсының да, сеңлесенең дә чикләвекләре тигезләшкән. Сеңлесенең башта ничә чикләвеге булган?

Искәрмәләр:
4*. 9 сан: 91, 92, 93, 94, 95, 96, 97, 98, 99.
5*. 3 чикләвек.

## III ЧИРЕК

### III чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты, исәпләүнең язмача ысулларын кулланып, 2 гамәлле аңлатмаларның кыйммәтләрен исәпләү, укучыларның 100 эчендә кушу һәм алу гамәлләрен һәм арифметик мәсьәләләр чишә белүләрен тикшерү.

Вариант 1

1. Саннарны «баганалап» языгыз һәм исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 35 + 13 | 56 + 7 | 64 - 31 | 40 -5 |
| 42 + 8 | 23 + 49 | 23 - 4 | 31 - 12 |

2. 74 + 10 + 6 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Буфетның өске шүрлегендә 4 чынаяк, урта шүрлегендә 6 чынаяк, ә аскы шүрлегендә өске һәм урта шүрлекләрдә икесендә бергә ничә чынаяк булса, шулкадәр чынаяк бар. Аскы шүрлектә ничә чынаяк?

4*. Мансур 6 цифрын язган, аның уң ягына 0 санын язып куйган. Барлыкка килгән сан 6 дан күпмегә зуррак?

5*. 9 л сок 5 литрлы, 3 литрлы һәм 2 литрлы банкаларны мөлдерәмә итеп тутырырга җитәрме?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: 54.

5*. Чишү: 5 + 3 = 8 (л), 8 + 2 = 10 (л), 9 < 10. Җавап: Җитмәс.

Вариант 2

1. Саннарны «баганалап» языгыз һәм исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 64 + 21 | 78 + 3 | 89 - 65 | 50 -9 |
| 56 + 4 | 14 + 27 | 21 - 7 | 46 - 27 |

2. 48 + 6 + 2 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Циркта 5 пантера, 7 арыслан һәм, пантералар белән арысланнар бергә ничә булса, шулкадәр юлбарыслар чыгыш ясаган. Циркта ничә юлбарыс чыгыш ясаган?

4*. Марат 25 санын язган һәм 5 цифрын сызып ташлаган. Сан ничәгә кимегән?

5* Папа Карло 13 урындык аягы ясаган. Бу урындык аяклары Буратино, Пьеро һәм Мальвинага бирәр урындык ясар өчен җитәрме?

Искәрмә:

5*. Чишү: 4 + 4 + 4 = 12, 12 < 13. Җавап: Җитәр.

**Вариант 3**

1. Саннарны «баганалап» языгыз һәм исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 52 + 9 | 36 + 48 | 37 - 8 | 50 - 34 |
| 44 + 35 | 47 + 3 | 25 - 19 | 60 -9 |

2. 16 + 9 - 5 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Өйдән мәктәпкә кадәр 100 м. Мин, мәктәптән чыгып, өйгә кайтып киттем. 60 м үткәч, миңа таба этем Акбай чабып килүен күреп, туктап калдым. Минем белән очрашканчы, Акбай ничә метр чабып үткән?

4*. 98 һәм 89 саннарының суммасы нинди цифр белән тәмамлана?

5*. Банкада 2 л сөт бар. Бу банкадагы сөтнең яртысын 3 л сөте булган кастрюльгә бушаталар. Кастрюльдә күпме сөт булды?

Искәрмә:

4*. Куелган сораугa җавап табу өчен, 98 һәм 89 саннарын кушу кирәкми. Соңгы цифрны табу өчен, берәмлекләр суммасын 8 + 9 = 17 табу җитә. Сумма 7 цифры белән тәмамлана.

**Вариант 4**

1. Саннарны «баганалап» языгыз һәм исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 76 + 8 | 45 + 45 | 96 - 7 | 60 - 15 |
| 86 + 13 | 61 + 9 | 31 - 16 | 80 -7 |

2. 12 + 6-4 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Бассейнда йөзү юлының озынлыгы 50 м. Юлның ике башыннан ике йөзүче бер-берсенә каршы йөзеп чыккан. Очрашканчы берсе 20 м йөзеп үткән. Икенчесе очрашканчы ничә метр йөзеп үткән?

4*. 100 һәм 54 саннарының аермасы нинди цифр белән тәмамлана?

5*. Алсуның 9 конфеты бар, ә Айсылуның 4 конфетка азрак. Ике кызның да конфетлары тигез булсын өчен, Алсу Айсылуга ничә конфет бирергә тиеш?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: 6 цифры.

5*. Җавап: 2 конфет.

**Вариант 5**

1. Саннарны «баганалап» языгыз һәм исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 + 48 | 46 + 39 | 51 - 4 | 60 -7 |
| 93 + 7 | 70 + 28 | 38 - 19 | 50 - 34 |

2. 20 - 8 - 4 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Ике урам себерүче, тротуарның ике башыннан бер-берсенә каршы килеп, кар чистарта башлаганнар. Очрашканчы берсе 45 м, икенчесе 5 м га кимрәк юл чистарткан. Тротуарның озынлыгын табыгыз.
4*. 46 > *8 язмасы дөрес булсын өчен, йолдызчык урынына нинди цифрлар язарга мөмкин?

Искәрмә:

4*. Җавап: 1, 2 яки 3.

## Вариант 6

1. Саннарны «баганалап» языгыз һәм исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 + 89 | 53 + 16 | 43 - 4 | 40 -8 |
| 62 + 8 | 37 + 50 | 56 - 17 | 90 - 66 |

2. 25 - 4 + 5 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Ике чаңгычы бер-берсенә кара-каршы йөгерәләр. Очрашканга кадәр беренчесе 50 м, икенчесе 5 м га кимрәк юл үткән. Чаңгычылар үткән юлның озынлыгын табыгыз.
4*. 56 < 5 □ язмасы дөрес булсын өчен, шакмак эченә нинди цифрлар язарга мөмкин?
5*. Үлчәүнең бер тәлинкәсендә карбыз һәм 2 кг лы гер, икенчесендә кавын һәм 1 кг лы гер тора. Үлчәүләр тигезләнеш торышында. Кайсы авыррак: карбызмы яки кавынмы һәм ничә килограммга?

IV ЧИРЕК

## IV чирек өчен контроль эш

Контроль эштә укучыларның берурынлы саннарны 2 гә һәм 3 кә тапкырлау таблицаларын һәм тиңдәшле бүлү очракларының нәтиҗәләрен белүләре; тапкырчыгышны һәм өлешне табуга мәсьәләләр чишә белүләре тикшерелә.

## Вариант 1

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 • 2 = | 9•3 = | 8:2 = | 27:3= |
| 6 • 2 = | 5•3 = | 10 : 2 = | 18:3= |
| 4 • 3 = | 3•3 = | 12 : 3 = | 12:2 = |

2. 3 люстраның һәркайсында 6 лампочка. Барлык люстраларда ничә лампочка?
3. 12 алманы тигез итеп 3 пакетка салганнар. Һәр пакетка ничә алма салганнар?
4*. Кыйммәте 8 гә тигез булган аңлатма уйлап табыгыз һәм языгыз.
5*. Абыйсы сеңлесеннән 2 яшькә зуррак. Абыйсына 91 яшь булса, сеңлесенә ничә яшь?

**Вариант 2**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 • 2 = | 6 • 3 = | 6 : 2 = | 24 : 3= |
| 8 • 2 = | 2 • 2 = | 6 : 3 = | 15 : 3= |
| 9 • 3 = | 5 • 3 = | 16 : 2 = | 18 : 2= |

2. Һәр күлмәкне тегү өчен 3 м ефәк киткән. 4 күлмәк тегү өчен күпме ефәк кирәк?
3. 10 л виноград согын тигез итеп 2 шешәгә салганнар. Һәр шешәгә ничә литр сок салганнар?
4*. Ике кырмыска оясы арасында 12 м. Кырмыска бер оядан чыгып, икенчесенә юнәлгән. Юлның яртысын үткәч, салам кисәге тапкан да үз оясына кире кайткан. Оядан нинди ераклыкта кырмыска салам кисәген тапкан? Кырмыска ничә метр юл үткән?
5*. 2 гә һәм 3 кә бүленүче сан уйлап табыгыз һәм язып куегыз.

**Вариант 3**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 • 4 = | 2 • 6 = | 24 : 3 = | 18 : 3= |
| 2 • 8 = | 4 • 2 = | 16 : 2 = | 27 : 3= |
| 7 • 3 = | 8 • 3 = | 10 : 2 = | 21 : 3= |

2. Җәмилнең 4 әр сумлык өч тәңкә акчасы булган. Җәмилнең акчасы күпме?
3. 8 кеше көймәләргә 2 шәрләп бүленеп утырганнар. Көймәләр ничә?
4*. Әниләре бәйрәмгә кызлары Гөлназ, Гөлнар, Гөлнурга аю, курчак, һәм эт бүләк иткән. Гөлназ үзенә курчакны һәм этне, ә Гөлнар курчакны сайламаса, һәр кыз нинди бүләк алган?
5*. 10 китапны өч киштәгә тигез итеп урнаштырып буламы?

Искәрмә:

4*. Чишү: Гөлназның аюны сайлавын җиңел белергә була. Курчак һәм эт кала. Гөлнар курчакны алмый, ул этне ала. Гөлнурга курчак кала. Җавап: Гөлназ аюны ала, Гөлнар — этне, Гөлнур — курчакны.

## Вариант 4

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 • 2 = | 3 • 3 = | 18 : 2 = | 14 : 2= |
| 4 • 3 = | 5 • 3 = | 9 : 3 = | 21 : 3= |
| 8 • 2 = | 2 • 7 = | 27 : 3 = | 15 : 3= |

2. Урындыкларны рәтләргә урнаштырганнар. 8 әр урындыклы 3 рәт килеп чыккан. Барлыгы ничә урындык булган?
3. Кыярларга сибү өчен 12 чиләк су тотканнар. Һәр түтәлгә 2 шәр чиләк су сипкәннәр. Түтәлләр ничә булган?

4*. Тигезлек дөрес булырлык итеп, җәяләр куй: 5 + 3 • 2 = 16.

5*. Өч дистә йомырка сатып алганнар һәм тигез итеп 2 тартмага салганнар. Һәр тартмада ничә йомырка?

## Вариант 5

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 • 5 = | 4 • 3 = | 12 : 3 = | 21 : 7= |
| 9 • 3 = | 6 • 2 = | 12 : 4 = | 24 : 8= |
| 3 • 8 = | 2 • 9 = | 15 : 5 = | 18 : 6= |

2. Тәлинкәгә 3 абрикос, ә вазага 4 тапкырга күбрәк абрикос куйганнар. Вазада ничә абрикос?
3. 24 м челтәр кисәген 8 тигез өлешкә кискәннәр. Һәр кисәкнең озынлыгын табыгыз.

4* □+□ = □• □ тигезлеге дөрес булсын өчен, шакмаклар эченә нинди цифрлар язарга мөмкин?

5*. Өч сарайның һәркайсында 3 тылсымчы яши, һәр тылсымчының 3 кызы бар. Барлык тыЛсымчыларның кызлары ничә?

Искәрмә:

4*. Җавап: 2 яки 0, чөнки 2 + 2 = 2 • 2 һәм 0 + 0 = 0 • 0.

## Вариант 6

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 • 3 = | 3 • 4 = | 27 : 9 = | 18 : 9= |
| 3 • 7 = | 8 • 2 = | 16 : 8 = | 21 : 7= |
| 9 • 3 = | 2 • 7 = | 15 : 3 = | 24 : 8= |

2. Гали абый 2 атнага отпускка кайткан. Ул ничә көнгә кайткан?
3. 8 кг эремчекне, тигез итеп бүлеп, 8 пакетка салганнар. Һәр пакетка ничә килограмм эремчек салганнар?
4*. 12 см озынлыгындагы чыбыкны квадрат формасына китереп бөккәннәр. Квадратның һәр ягының озынлыгын табыгыз.
5*. Төлке өеннән бүре өенә 3 юл, ә бүре'өеннән аю өенә 2 юл илтә. Төлке аюга кунакка ничә төрле юл белән килә ала (рәс. 52)?

Искәрмә:

5*. Җавап: 6 төрле (3 • *2* = 6).

# ӨЧЕНЧЕ СЫЙНЫФ

## I ЧИРЕК

## Кереш контроль эше

Эшнең максаты булып 2 нче сыйныф программа материалын укучылар ничек үзләштерүен тикшерү тора. Укучыларның берурынлы саннарны 0 не дә кертеп кушу һәм тиндәшле алу таблицасын белүләре; 100 эчендә кушу һәм алу гамәлләрен башкара белүләре, ике арифметик гамәлдән торган җәяле һәм җәясез аңлатма кыйммәтен исәпли белүләре, гади һәм 2 гамәлле арифметик мәсьәләләр чишә белүләре тикшерелә.

### Вариант 1

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 2= | 10-7= | 13-6= | 18-9 = |
| 9 - 5 = | 0 + 3 = | 9 + 5 = | 7 - 0 = |
| 3 + 8 = | 12 - 3 = | 4 + 6 = | 7 + 5 = |

2. 21 + 32 + 8 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. 4 тәрәзәнең һәркайсына 2 шәр пәрдә элгәннәр. Тәрәзәләргә ничә пәрдә элгәннәр?
4. Чигүче зәңгәр яулыкка 3 роза, ак яулыкка 2 розага артыграк чиккән. Чигүче барысы ничә роза чиккән?
5*. Өч дус дачага, поездга утырып, 6 сәгать барганнар. Аларның һәркайсы юлда ничә сәгать булган?
6*. □ • 1 = □ • 1 тигезлеге дөрес булсын өчен, шакмак эченә нинди сан язарга кирәк?

Искәрмә:

6*. Җавап булып теләсә нинди сан тора. Әгәр укучы, җавап итеп, берничә конкрет сан яки нинди дә булса бер генә сан язса да, мәсьәлә дөрес чишелгән дип исәпләргә.

## Вариант 2

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 + 3 = | 10 - 9 = | 12 - 4 = | 3 + 9 = |
| 8 + 8 = | 6 + 0 = | 7 + 5 = | 8 - 0 = |
| 11 - 2 = | 10 - 6 = | 9 - 8 = | 7 + 7 = |

2. 95 - 21 - 3 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. 9 гладиолусны 3 вазага тигез итеп бүлеп куйганнар. Бәр вазада ничә гладиолус?
4. Әни 8 банка абрикос вареньесы, аннан 2 банкага артыграк кура җиләге вареньесы, җир җиләге вареньесын абрикос һәм кура җиләге вареньелары кадәр кайнаткан. Әни ничә банка җир җиләге вареньесы кайнаткан?

5*. Бер йортта өч бүлмәле фатирлар 4, икенче йортта бүлмәләр саны шул ук кадәр, ләкин барлык фатирлар ике бүлмәлеләр. Икенче йортта ничә фатир бар?

6*. Агачта 3 чәүкә һәм 2 карга утырган. 2 кош очып киткән. Ничә һәм нинди кошлар калырга мөмкин?

Искәрмә:

6*. Әгәр укучы барлык мөмкин очракларны язса гына, мәсьәлә чишелгән дип санала: а) 3 чәүкә; б) 1 карга һәм 2 чәүкә; в) 2 карга һәм 1 чәүкә.

## Вариант 3

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 + 7 = | 0 + 1 = | 16 - 9 = | 15 - 7 = |
| 13 - 8 = | 8 + 5 = | 5 + 8 = | 2 + 9 = |
| 12-9= | 11-4= | 6-6= | 6 + 8 = |

2. 56 - (35 + 8) аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. 6 пакетның һәркайсында 3 кг бәрәңге. Бу пакетларда ничә килограмм бәрәңге?

4*. Кырмыска оясы каршында агач үсә. Кырмыска агач астыннан салам кисәге таба да үз оясына алып китә. 25 м шуышып үткәннән соң, үтәсе юл үткәненнән Юмга кимрәк калган. Агач оядан күпме ераклыкта үсә?

5*. Маратның акчасы 24 сум, Ленарның — 46 сум, ә Талиянең акчасы Марат белән Ленарныкы кадәр. Талиянең акчасы малайларның һәркайсыннан күпмегә артыграк?

6*. Залда берничә урындык булган. Башта залдан 8 урындыкны чыгарганнар, ә соңыннан 12 урындыкны керткәннәр. Шуннан соң залда 20 урындык булган. Залда башта ничә урындык булган?

Искәрмә:

5*. Бертөрле исәпләүләрсез җавапны язарга мөмкин. Талиянең акчасы Маратныкыннан 46 сумга, ә Ленарныкыннан 24 сумга артыграк.

## Вариант 4

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14 - 7 = | 7 + 9 = | 11 - 8 = | 16 - 9= |
| 0 + 1 = | 5 - 0 = | 7 + 4 = | 5 + 6= |
| 16 - 8 = | 8 + 5 = | 9 + 6 = | 14 - 8= |

2. 78 - (24 + 7) аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. 9 пар күзлек ясау өчен, ничә күзлек пыяласы кирәк?
4. Кәбестә салынган капчыкның массасы 35 кг, бәрәңге салынган капчык 15 кг га җиңелрәк. Машинага 2 капчык бәрәңге төягәннәр. Бу капчыкларда ничә килограмм бәрәңге бар?

5*. Иртән сәгать 8 дә ике авылдан бер-берсенә кара-каршы бер үк юлдан Ирек белән Азат велосипедларда чыгып киткәннәр. Очрашканга кадәр Ирек 2 сәгать барган. Азат очрашканга кадәр ничә сәгать барган?

6*. Безнең йортта Кадрия, Мәрьям һәм Асия яшиләр. Кичә мин Кадрия белән Мәрьямне күрдем, аларның берсенә 9 яшь, икенчесенә 8 яшь. Бүген Мәрьям белән Асияне күрдем. Аларның берсенә 10 яшь, икенчесенә 9 яшь. Кемгә ничә яшь?

Искәрмәләр:

5*. Җавап: 2 сәгать (8 сәгать — артык бирелгән).

6*. «Кадрия белән Мәрьямне күрдем» һәм «Мәрьям белән Асияне күрдем» шартларын чагыштырсак, Мәрьям исеме кабатлана. Димәк, Мәрьямга 9 яшь, Кадриягә 8 яшь, ә Асиягә 10 яшь.

## Вариант 5

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10-10= | 7+7= | 13-4= | 8-6 = |
| 6 + 7 = | 0 + 0 = | 9 + 9 = | 16 - 7 = |
| 12-8= | 11-5= | 4 + 5= | 8 + 7 = |

2. 100 - (28 + 16) аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3.Һәр стакан чәйгә 2 шакмак шикәр салганнар. Шикәр савытындагы 8 кисәк шикәр 6 стакан чәйгә җитәрме?
4. Матч вакытында баскетболчы тупны кәрзингә берничә тапкыр ыргыта. Уен барышында туп 8 тапкыр кәрзингә төшә, ә кәрзингә төшмәү 3 кә кимрәк. Тупны баскетболчы кәрзингә ничә тапкыр ыргыткан?
5*. Өч дус очрашкач, бер-берсенең кулын кысканнар. Барлык кул кысуларның санын исәпләп табыгыз.
6*. Авылдан шәһәргә шофер 3 сәгать барган. Шәһәргә ул көндезге сәгать 2 дә килеп җиткән. Шофер авылдан сәгать ничәдә чыгып киткән?

Искәрмә:

5*. Җавап: 3 кул кысу.

## Вариант 6

1. Җавапларын язызыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15-9= | 9-9= | 5 + 9= | 13-7 = |
| 3 + 8 | 7+ 6 = | 4 + 8= | 5 + 8 = |
| 0-0= | 18-9= | 11-9= | 7 + 9 = |

2. 90 - (61 - 37) аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Күлмәкне бизәү өчен 3 төрле төстәге челтәр кисәкләре кирәк. Бер кисәк челтәрнең озынлыгы 9 м. Күлмәкне бизәү өчен барысы күпме челтәр кирәк?
4. Тартмадан бала 5 шакмак алып манара төзи. Тартмада моннан соң да 2 тапкырга артыграк шакмак калган. Тартмада ничә шакмак булган?
5*. Миңа яртышар килограмм сыр һәм казылык алырга куштылар. Мин сатып алган ашамлыкның массасын билгели аласызмы?
6*. Паркта аллея буйлап һәр 4 м саен миләш утыртылган. Моннан тыш аллеяның башында һәм ахырында берәр миләш утыртылган. Аллеяның озынлыгы 32 м. Бу аллеяда ничә миләш үсә?

### «3 кә һәм 4 кә тапкырлау һәм бүлү» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты булып укучыларның берурынлы саннарны 3 кә һәм 4 кә тапкырлау таблицасын һәм тиңдәшле бүлү очракларының нәтиҗәләрен үзләштерүләрен тикшерү тора.

**Вариант 1**

Җавапларын языгыз: -

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 • 4 = | 5 • 3 = | 12 : 4 = | 20 : 5= |
| 6 • 3 = | 5 • 4 = | 9 : 3 = | 12 : 3= |
| 4 • 4 = | 3 • 7 = | 15 : 3 = | 24 : 4= |
| 8 • 3 = | 9 • 4 = | 16 : 4 = | 32 : 4= |

**Вариант 2**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 • 4= | 2 · 3 = | 12 : 3 = | 15 : 5= |
| 4 • 3= | 5 · 4 = | 32 : 4 = | 9 : 3= |
| 9 • 3= | 3 · 8 = | 12 : 4 = | 24 : 6= |
| 4 • 5= | 7 · 3 = | 21 : 7 = | 28 : 7= |

**Вариант 3**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3• 7 = | 4 • 6 = | 12 : 4 = | 32 : 8= |
| 4 • 4 = | 7 • 3 = | 27 : 9 = | 27 : 3= |
| 4 • 8 = | 9 • 3 = | 20 : 4 = | 36 : 9= |
| 8 • 3 = | 4 • 5 = | 28 : 7 = | 24 : 6= |

**Вариант 4**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 • 4 = | 3 • 3 = | 20 : 5 = | 20 : 4= |
| 4.9 = | 8 • 4 = | 12 : 4 = | 27 : 9= |
| 8 · з = | з • 7 = | 32 : 8 = | 36 : 4= |
| 6 • 3 = | 5 • 4 = | 28 : 7 = | 9 : 3= |

**Вариант 5**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 · 3 = | 9 • 4 = | 16 : 4 = | 21 : 7= |
| 4 · 7= | 4 - 8 = | 32 : 8 = | 27 : 9= |
| 3 · 9 = | 4 - 6 = | 36 : 9 = | 20 : 4= |
| 5 · 4 = | 4 - 4 = | 20 : 5 = | 36 : 4= |

**Вариант 6**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 • 4 = | 4 · 8 = | 32 : 4 = | 36 : 9= |
| 3 • 7 = | 6 · 4 = | 20 : 5 = | 27 : 3= |
| 4 • 5 = | 7 · 3 = | 12 : 6 = | 24 : 4= |
| 3 • 9 = | 8 · 3 = | 32 : 8 = | 24 : 6= |

## I чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты булып укучыларның «тапкырга зуррак», «тапкырга кечерәк» төшенчәләренең мәгънәләрен үзләштерүләрен, җәяләр һәм җәяләрсез язылган арифметик гамәлле аңлатмаларның кыйммәтләрен таба белүләрен, тәкъдим ителгән фигуралар арасыннан кирәкле күппочмакны таба белүләрен, кәгазьдә күппочмакны сурәтли белүләрен тикшерү тора. Эш индивидуаль карточкаларда башкарыла.

### Вариант 1

1. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

   25 - 20 : 5; 6 • (3 + 4).

2. а) Вазада 3 ромашка, ә кыңгырау чәчәкләре 4 тапкырга артыграк. Кыңгырау чәчәкләре күпме?
   Чишү Җавап

б) 3 тюбик теш пастасы һәм 6 кисәк сабын сатып алалар. Теш пастасын сабынга караганда ничә тапкырга кимрәк сатып алганнар?
   Чишү______ Җавап_______

в) Өстәлдә 8 тәлинкә, ә чынаяклар тәлинкәләрдән 4 тапкырга кимрәк. Чынаяклар ничә?
   Чишү______ Җавап_______

3. Дүрт күппочмакның кайсысы өчпочмак (рәс. 53)? Өчпочмакны буягыз.

4*. Марат перекладинада 12 тапкыр, ә Алмаз 3 тапкырга кимрәк күтәрелә ала. Азат перекладинада ничә тапкыр күтәрелгән?

5*. Спорт залындагы канатның озынлыгы 50 дм. Түшәмгә кадәр күтәрелеп җитү өчен 2 м 3 дм ара калган булса, Гүзәл бу канат буйлап нинди биеклеккә менгән?

Искәрмә:

4*. Үзенең эчтәлеге буенча мәсьәлә авыр типтагы мәсьәләләр рәтенә керми. Мәсьәлә чишүдә кыенлыклар бу мәсьәлә текстының үзенчәлекләре белән бәйләнгән. «3 тапкырга кимрәк» дигән сүзләрне күреп, укучылар арифметик гамәлне ялгыш сайлап, бүлү гамәлен эшләүләре мөмкин. Мәсьәлә алу гамәле белән эшләнә: 12-3 = 9.

### Вариант 2

1. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

   4 + 5-3; 12 : (4 + 2).

2. а) Универмагның аяк киемнәре бүлегендә 36 пар туфли, ә итекләр 4 тапкырга кимрәк сатылган. Ничә пар итек сатылган?
Чишү____ Җавап____
б) Күлмәк тегү-өчен 3 м тукыма, костюм тегү өчен шундый тукыма 2 тапкырга артыграк кирәк. Костюмга күпме тукыма кирәк?
Чишү____ Җавап____
в) Залда 2 кыз һәм 8 малай. Малайлар кызлардан ничә тапкырга артыграк?
Чишү____ Җавап____
3. Күппочмаклар арасыннан дүртпочмакны табыгыз һәм буяп куегыз (рәс. 54).
4*. Нинди дә булса дөрес тигезлек уйлап табып, язып куегыз.
5*. 45 болт һәм 36 гайка бар. Болардан гайкалы болтларны ничә пар төзеп була?

Искәрмә:

5*. Җавап: 36 пар. Бу очракта бернинди арифметик гамәл эшләү кирәкми.

## Вариант 3

1. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

$24 : 6 : 2$; $5 \cdot (5 + 3)$.

2. Кирәкле гамәлне дөрес сайлап алыгыз, чишүне һәм җавапны языгыз:
12 саны 3 тән ничә тапкырга зуррак?
Чишү____ Җавап____
12 саны 3 тән күпмегә зуррак?
Чишү ____Җавап____
7 саны 21 дән күпмегә кимрәк?
Чишү ____Җавап ____
7 саны 21 дән ничә тапкырга кимрәк?
Чишү ____Җавап ____.
3. Дүрт күппочмакның кайсы дүртпочмак (рәс. 55)? Шунсын буягыз.
4*. 2 атна айның яртысын тәшкил итә. Бу айның исемен языгыз.
5*. Савытларга 18 вафлины болай итеп бүлеп салганнар: 4, 5, 2, 7. Савытлардагы вафлиларны алмыйча гына, бу вафлиларны бер өстәлдә икенчесенә караганда 2 тапкыр артыграк булырлык итеп, ничек урнаштырырга мөмкин?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: Февраль.

5*. Җавап: Бер өстәлгә 4 һәм 2 вафли булган савытларны, икенчесенә 5 һәм 7 вафли булган савытларны куярга кирәк.

## Вариант 4

1. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

   12 : 3 • 2; (8 + 4) : 4.

2. Гамәлне дөрес сайлап алыгыз. Чишүне һәм җавапны языгыз.

   4 саны 8 дән ничә тапкырга кечерәк?
   Чишү________Җавап
   4 саны 8 дән күпмегә кечерәк?
   Чишү Җавап
   20 саны 5 тән ничә тапкырга зуррак?
   Чишү Җавап
   20 саны 5 тән ничәгә зуррак?
   Чишү______ Җавап_______

3. Күппочмаклар арасыннан дүртпочмакны табыгыз (рәс. 56) һәм аны сары карандаш белән буягыз.

4*. Тәлинкәдә сливалар бар. Мәрьям — барлык сливаларның яртысын, ә Азат калган 4 сливаны ала. Тәлинкәдә ничә слива булган?

5*. 5 - $x$ аңлатмасында $x$ урынына нинди саннар куеп була?

Искәрмәләр:

4*. 4 слива барлык сливаларның яртысын тәшкил итә, димәк, барлык сливалар — 8. Укучылар җавапны 4-2 = 8 дип яки телдән генә исәпләп, җавапны язулары мөмкин. Соңгы очракта да мәсьәлә чишелгән дип исәпләнә.

5*. Җавап: 0 дән 5 кә кадәрге барлык саннар. Балалар җавапны башкача: 0, 1, 2, 3, 4, 5 дип язулары да мөмкин.

## Вариант 5

1. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

   15-5-2 + 8; 32 : 4 • (7 - 5).

2. Өч кызыл шакмак һәм алардан 3 тапкырга күбрәк зәңгәр шакмак ясагыз.

   12 чикләвек, алардан 3 тапкырга кимрәк алма ясагыз.

3. Фигурларның кайсы күппочмак була (рәс. 57)? Дөрес җавапны сызыгыз.

4*. 3 - $x$ аңлатмасының ничә кыйммәте бар?
   Җавап

5*. 3 дистә бертөрле сливаларның массасы 1 кг. 6 дистә сливаның массасы күпме?

Искәрмәләр:

*2.* Биремне укучылар аерым битләрдә башкарырга тиешләр.
4*. Дүрт кыйммәт.

## Вариант 6

1. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

   20 - 8 + 4 : 2;                    20 : 4 • (8 - 3).

2. Кәрзиндә яшелчәләр бар: 3 бәрәңге, кишерләр бәрәңгегә караганда 5 кә артыграк, суганнар кишергә караганда 2 тапкырга азрак, шалканнар бәрәңгегә караганда 2 тапкырга артыграк. Һәр яшелчәне түгәрәк белән тамгалап, рәсемне ясагыз.

   Б.____________________________________________

   К._____________________________________

   с.____________________________________________

3. Нинди дә булса күппочмак сызыгыз һәм аның ничек аталуын языгыз.

4*. Динә Илсөярдән 4 тапкырга зуррак. Динәгә 8 яшь, Илсөяргә ничә яшь?
Чишү Җавап

5*. Бер карбыз һәм шундый ук ярты карбызның массасы 9 кг. Бер бөтен карбызның массасы күпме?

Искәрмә:

5*. Түбәндәгечә фикер йөртик. Бөтен карбыз ике ярты карбыздан тора. Димәк, 3 ярты карбызның массасы 9 кг. Ярты карбызның массасы 3 кг (9 : 3 = 3), ә бөтен карбызның 6 кг (3 • 2 = 6). Җавап: 6 кг.

II ЧИРЕК

## «Берурынлы саннарны тапкырлау таблицасы» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты булып укучыларның тапкырлау таблицасын һәм тиңдәшле бүлү очраклары нәтиҗәләрен ничек үзләштерүләрен тикшерү тора.

**Вариант 1**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 • 6 = | 1 • 8 = | 18 : 6 = | 24 : 8= |
| 9 • 3 = | 6 • 0 = | 9 : 9 = | 36 : 6= |
| 7 • 7 = | 8 • 4 = | 9 : 1 = | 10 : 2= |
| 8 • 9 = | 7 • 6 = | 72 : 8 = | 45 : 5= |
| 5 • 6 = | 5 • 9 = | 25 : 5 = | 30 : 6 = |

**Вариант 2**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 • 4 = | 8 • 7 = | 0 : 7 = | 45 : 5= |
| 0 • 2 = | 5 • 9 = | 45 : 9 = | 72 : 9= |
| 9 • 8 = | 1 • 1 = | 12 : 6 = | 9 : 1= |
| 6 • 7 = | 8 • 8 = | 27 : 3 = | 40 :8 = |
| 6 • 6 = | 5 • 7 = | 35 : 7 = | 81 : 9= |

**Вариант 3**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 • 3 = | 7 • 6 = | 14 : 7 = | 12 : 3= |
| 2 • 6 = | 1 • 9 = | 20 : 4 = | 0 : 8= |
| 4 • 5 = | 0 • 6 = | 18 : 9 = | 25 : 5= |
| 6 • 9 = | 6 • 7 = | 56 : 8 = | 56 : 7= |
| 5 • 7 = | 4 • 9 = | 63 : 7 = | 63 : 9= |

**Вариант 4**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 • 5 = | 9 • 9 = | 56 • 8 = | 1 : 1 = |
| 4 • 8 = | 3 • 8 = | 63 : 7 = | 0 : 1= |
| 8 • 6 = | 0 • 0 = | 36 : 4 = | 24 : 4= |
| 7 • 7 = | 8 • 8 = | 15 : 5 = | 36 : 9= |
| 6 • 7 = | 5 • 9 = | 42 : 7 = | 54 : 6= |

**Вариант 5**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 • 9 = | 4 • 8 = | 42 : 7 = | 6 : 6= |
| 5 • 4 = | 7 • 5 = | 35 : 5 = | 7 : 1= |
| 9 • 6 = | 0 • 1 = | 72 : 9 = | 0 : 9= |
| 8 • 8 = | 7 • 6 = | 56 : 7 = | 72 : 8= |
| 5 • 7 = | 8 • 9 = | 64 : 8 = | 36 : 6= |

**Вариант 6**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 0 · 5 = | 9 • 7 = | 8 : 1 = | 42 : 6= |
| 5 • 8 = | 9 • .9 = | 32 : 8 = | 36 : 6= |
| 6 • 6 = | 6 • 1 = | 16 : 4 = | 4 : 4= |
| 6 • 7 = | 8 • 4 = | 48 : 8 = | 49 : 7= |
| 5 • 9 = | 5 • 5 = | 24 : 8 = | 81 : 9= |

## II чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты булып укучыларның, үзгәрешленең кыйммәте бирелгәндә, үзгәрешлене эченә алган аңлатмаларның кыйммәтләрен таба белүләрен, 2 гамәлле (кушу яки алу, тапкырлау яки бүлү гамәлләре белән катнаш) арифметик мәсьәләләр чишә белүләрен, бирелгән күппочмаклар арасыннан турыпочмаклыкны (квадратны таба белүләрен тикшерү тора.

**Вариант 1**

1. Язмаларны тәгалләгез:
   Әгәр $x$ = 24 булса, $x$ : 8 =була.
   Әгәр $a$ = 7 булса, $a$ + 4 =була.
2. 30 лимонны 5 пакетка тигез итеп бүлеп салганнар. 2 пакетта ничә лимон?
3. Дүртпочмаклар арасыннан турыпочмаклыкны табыгыз һәм аның номерын языгыз (рәс. 58).

4*. $x$ • 3 = 12 тигезлеге дөрес булсын өчен, $x$ урынына нинди сан куярга кирәк?

5*. Попугай клоун иңбашында утыра һәм томшыгы белән тартмадан дүрт төстәге карточкаларны алып, балаларга түбәндәге тәртиптә тарата: ак, зәңгәр, яшел, кызыл. Белмәмеш җиденче булып торган. Аңа нинди төстәге карточка эләккән?

Искәрмә:

4*. Сан сайлап алу юлы белән табыла.

**Вариант 2**

1. Язманы тәгалләгез:
   Әгәр $x$ = 7 булса, 12 - $x$ =________ була.
   Әгәр $a$ = 3 булса, 15 : $a$ =_______ була.
2. Бертөрле 4 җәймә тегү өчен, 16 м җитен тукыма кирәк. Шундый 8 җәймә тегү өчен күпме тукыма кирәк?
3. Дүртпочмаклар арасыннан квадратны табыгыз (рәс. 59) һәм аның номерын языгыз.

4*. Пешәр-пешмәс итеп йомырка пешерү өчен 3 минут вакыт житә. Шундый итеп 2 йомырка пешерү өчен ике тапкыр артык вакыт, ягъни 6 минут кирәк дип уйлау дөресме?

5*. Болт гайкадан 2 тапкыр авыррак. Шундый 6 болт гайкадан ничә тапкырга авыррак?

Искәрмә:

5*. Җавап: 12 тапкыр.

**Вариант 3**

1. Әгәр $x = 7$ булса, 14 + x; $a = 27$ булса, $a : 9$ аңлатмаларының кыйммәтләрен табыгыз.
2. 32 кг балны 4 бидонга салганнар. 3 бидонга 7 шәр кг бал салганнар. Дүртенче бидонда ничә килограмм бал?
3. Дүртпочмаклар арасыннан турыпочмаклыкны табыгыз (рәс. 60) һәм аның номерын языгыз.

4*. Җөмләләрне укыгыз һәм дөресенең астына сызыгыз: «Нуль 2 гә бүленә», «Нуль 2 гә бүленми».

5*. 12 санының өчтән беренең яртысы күпмегә тигез?

**Вариант 4**

1. $x = 15$ булса, 15 - x; $y = 9$ булса, $5 \cdot y$ аңлатмаларының кыйммәтләрен табыгыз.
2. Бер чыбыктан 6 виноград тәлгәше, икенче чыбыктан 2 тапкырга кимрәк, ә өченчесеннән икенчесенә караганда 4 тәлгәшкә артыграк җыеп алганнар. Өченче чыбыктан ничә тәлгәш виноград алганнар?
3. Дүртпочмаклар арасыннан квадратны табыгыз (рәс. 61) һәм аның номерын языгыз.

4*. $0 \cdot 1 \cdot 2 \cdot 3 \cdot 4 \cdot 5$ тапкырчыгышы күпмегә тигез?

5*. Бәрәңге чәчәкләре — иртәнге 6 сәгатьтән 14 сәгатькә, җитен чәчәкләре — 6 сәгатьтән 16 сәгатькә, ә тырнак гөл чәчәкләре 9 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр ачылалар. Бу чәчәкләр нинди сәгатьләрдә барысы да ачылган булалар?

**Вариант 5**

1. x = 8 булса, x • 6; $a = 9$ булса, $9 + a$ аңлатмаларының кыйммәтләрен табыгыз.
2. Зефир һәм печеньены аерым пакетларга салганнар. Бер пакетка 9 зефир, ә печеньены 4 тапкырга артыграк салганнар. 2 пакетта ничә печенье?
3. Дүртпочмаклар арасында турыпочмаклык бармы (рәс. 62)? Дөрес җавапны сайлагыз: 1) Әйе. 2) Юк. 3) Белмим.

4*. Базада 36 тегү машинасы булган. Бу машиналарны кибетләргә 6 дан күбрәк, 10 нан кимрәк булырлык итеп, тигез бүлеп биргәннәр. Кибетләр ничә булган?

5*. Безнең бакчада 12 алмагач һәм груша агачы бар. Груша агачлары 4.' Җиләк-җимеш агачларының нинди өлешен груша агачлары тәшкил итә?

Искәрмәләр:

4*. 6 дан зур, 10 нан кечкенә саннар өчәү: 7, 8, 9. Шулар арасыннан 36 га калдыксыз бүленә торган санны алырга кирәк. Ул — 9 саны (36 : 9 = 4). Җавап: 4 кибет.

5*. Җавап бирү өчен, 12 эчендә 4 саны ничә тапкыр булуын белергә кирәк. Моның өчен бүләргә кирәк: 12 : 4 = 3. Груша агачлары барлык агачларның өченче өлешен тәшкил итәләр.

**Вариант 6**

1. х = 8 булса, 72 : х; *а* = 10 булса, 16 - *а* аңлатмаларының кыйммәтләрен табыгыз.
2. Әни кичә сыердан барлыгы 24 л сөт савып алган. Барлык сөтнең өченче өлешен бозауга эчергән, калганыннан каймак ясаган. Каймак ясау өчен күпме сөт киткән?
3. 63 нче рәсемдә сез ничә турыпочмаклык күрәсез?

4*. Вазада 6 алма һәм 2 груша бар.

Грушалар алмаларның нинди өлешен тәшкил итә? Җавап

Грушалар барлык җиләк-җимешнең нинди өлешен тәшкил итә?

Җавап

5*. Белмәмеш 50 борчак орлыгы утырткан. Һәр дистәдән 2 орлык тишелмичә калган. Барысы ничә орлык тишелмәгән?

III ЧИРЕК

### «Сумманы санга тапкырлау һәм бүлү» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты булып сумманы санга тапкырлау һәм бүлү кагыйдәләрен кулланып, укучыларның тапкырчыгыш һәм өлешне таба белүләрен тикшерү тора. (23 • 4, 46 : 2, 57 : 3), шулай ук 87 : 29 рәвешендәге мисалларны чишеп, берурынлы өлешне таба белүләрен тикшерү.

**Вариант 1**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13 · 2 = | 12 • 4 = | 96 : 3 = | 88 : 44= |
| 24 · 3 = | 60 : 5 = | 84 : 6 = | 64 : 16= |
| 16 · 5 = | 24 : 2 = | 42 : 21 = | 96 : 32= |

**Вариант 2**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| $45 \cdot 2 =$ | $31 \cdot 3 =$ | $84 : 4 =$ | $55 : 11 =$ |
| $16 \cdot 4 =$ | $96:3 =$ | $68:2 =$ | $90:15 =$ |
| $21 \bullet 3 =$ | $60 : 4 =$ | $24 : 12 =$ | $87 : 29 =$ |

**Вариант 3**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| $35 \cdot 2 =$ | $15 \bullet 5 =$ | $90 : 5 =$ | $99 : 11 =$ |
| $17 \cdot 5 =$ | $84 : 7 =$ | $63 : 3 =$ | $85 : 17 =$ |
| $27 \bullet 3 =$ | $38 : 2 =$ | $32 : 16 =$ | $48 : 24 =$ |

**Вариант 4**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| $12 \cdot 6=$ | $11 \cdot 7 =$ | $75 : 5 =$ | $36 : 18 =$ |
| $25 \cdot 4 =$ | $84:6 =$ | $65:5 =$ | $75:25=$ |
| $48 \cdot 2 =$ | $64:4 =$ | $30:15 =$ | $66:11=$ |

**Вариант 5**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| $24 \cdot 4=$ | $18 \bullet 4 =$ | $91 : 7 =$ | $96 : 12=$ |
| $29 \cdot 3 =$ | $76 : 4 =$ | $51 : 3 =$ | $58 : 29=$ |
| $16 \cdot 5 =$ | $84 : 7 =$ | $10 : 25 =$ | $96 : 48=$ |

**Вариант 6**

Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| $32 \cdot 3=$ | $12 \bullet 8 =$ | $88 : 4 =$ | $80 : 16 =$ |
| $16 \bullet 5 =$ | $91 : 7 =$ | $51 : 3 =$ | $78 : 26 =$ |
| $41 \cdot 2 =$ | $70:2 =$ | $60:15 =$ | $95:19=$ |

## III чирек өчен контроль эш

Контроль эшкә укучыларның телдән 100 эчендә саннарны тапкырлау һәм бүлү гамәлләрен (20 • 3, 60 : 3, 80 : 40 тибындагы) башкара белүләрен, үзгәрешленең кыйммәте бирелгәндә, үзгәрешле аңлатманың кыйммәтен таба белүләрен һәм, төрле арифметик гамәлләр кулланып, мәсьәлә чишә белүләрен тикшерә торган биремнәр кертелгән.

**Вариант 1**

Җавапларны языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| $30 \cdot 2 =$ | $10 \cdot 7 =$ | $60 : 3 =$ | $50 : 5 =$ |
| $4 \cdot 20 =$ | $30 \cdot 3 =$ | $70 : 10 =$ | $80 : 40 =$ |

2. Язып бетерегез:

Әгәр *a* — 0 булса, 15 + *a* =була.

Әгәр *a* = 25 булса, 15 + *a* =була.

3. Бер савытта 24 кг эремчек, ә икенчесендә 6 кг га артыграк. Барлык эремчекнең алтынчы өлешен балалар бакчасына җибәрәләр. Балалар бакчасына ничә килограмм эремчек җибәргәннәр?

4*. Ике санның өлеше бүленүчегә тигез булуы мөмкинме? Җавап:
   1) Әйе. Мәсәлән,
   2) Юк.
   3) Белмим.

5*. Дистәләр саны берәмлекләр санынннан 3 тапкыр кечерәк булган икеурынлы саннарны языгыз.

Искәрмә:

5*. Җавап: 13, 26, 39.

## Вариант 2

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 40 • 2 = | 10 • 8 = | 60 : 20 = | 100 : 50 = |
| 5 • 20 = | 90 • 1 = | 40 : 2 = | 90 : 10 = |

2. Язып бетерегез:

Әгәр *x* = 30 булса, 60 - x =була.

Әгәр x = 6 булса, 50 - x = __була.

3. Террариумда 56 елан бар. Барлык елланнарның сигезенче өлешен кобралар тәшкил итә. Кара еланнар кобралардан 3 тапкырга артыграк. Кара еланнар күпме?

4*. Ике санның тапкырчыгышы тапкырлатучыларның бер сенә тигез булуы мөмкинме?
   Җавап:
   1) Әйе. Мәсәлән,
   2) Юк.
   3) Белмим.

5*. Дистәләр саны берәмлекләр санынннан 3 тапкырга зуррак булган барлык икеурынлы саннарны языгыз.

Искәрмә:

5*. Җавап: 31, 62, 93.

## Вариант 3

| | | | |
|---|---|---|---|
| 50-2 = | 20 • 3 = | 60 : 30 = | 80 : 4 = |
| 8 • 10 = | 92 • 1 = | 100 : 20 = | 70 : 7 = |

2. Язып бетерегез:
Әгәр $y = 1$ булса, $y \cdot 30 =$була.
Әгәр $y = 2$ булса, $y \cdot 30 =$була.
3. Җыентыкта 96 әкият бар. Барлык әкиятләрнең өченче өлеше — ханнар турында. Калган әкиятләрнең ярты-сы — хайваннар турында. Бу җыентыкта хайваннар турында ничә әкият бар?
4*. Нинди очракта ике санның аермасы нульгә тигез була?
5*. «Синең ничә маркаң бар?»— дип сораганнар Алмаздан. «Ә менә сез уйлап табыгыз: миндә 6 марка һәм тагын барлык маркаларымның яртысы бар»,— дигән Алмаз. Алмазның ничә маркасы булган?

Искәрмә:
5*. Әгәр укучылар 6 марканың барлык маркаларның яртысы икәненә төшенсәләр, мәсьәләне җиңел чишәрләр: $6 \cdot 2 = 12$. Алмазның 12 маркасы булган.

## Вариант 4

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| $10 \cdot 10 =$ | $2 \cdot 40 =$ | $100 : 50 =$ | $40 : 40 =$ |
| $10 \cdot 2 =$ | $80 \cdot 1 =$ | $60 : 3 =$ | $70 : 10 =$ |

2. Язып бетерегез:
Әгәр $a = 60$ булса, $a : 20 =$була.
Әгәр $a = 100$ булса, $a : 20 =$була.
3. Кибеткә һәркайсында 6 шар стакан булган 15 тартма һәм зур хрусталь вазалар китергәннәр. Вазалар стаканнарга караганда 5 тапкырга азрак. Кибеткә ничә ваза китергәннәр?
4*. Нинди очракта аерма кимүчегә тигез була?
5*. Бер каптырма ясау өчен 20 см озынлыгындагы тасма кирәк. Ике шундый каптырма ясау өчен, күпме тасма кирәк булыр?

## Вариант 5

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| $9 \cdot 10 =$ | $20 - 5 =$ | $100:2 =$ | $50:10 =$ |
| $30 \cdot 3 =$ | $100 \cdot 1 =$ | $60 : 3 =$ | $80 : 8 =$ |

2. $a = 30$ булса, $a + 60 : a$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Мичкәгә 60 л су сыя, ә чиләккә 6 тапкырга кимрәк. Түтәлләргә сибү өчен, 3 чиләк су тоталар. Түтәлләргә ничә литр су сипкәннәр?
4*. Нинди очракта ике санның тапкырчыгышы нуль була?

5*. Мүк җиләгеннән варенье кайнату өчен, һәр 2 стакан җиләккә 3 стакан шикәр комы алалар. Әгәр 12 стакан шикәр комы тотылган булса, варенье кайнату өчен, ничә стакан җиләк алганнар?

## Вариант 6

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 • 20 = | 20 • 4 = | 60 : 30 = | 90 : 9 = |
| 80·1= | 10-10 = | 90:10 = | 100:100 = |

2. Әгәр $x$ = 5 булса, 8 • $x$ - 5 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Мәктәп бакчасына 50 лалә суганчасы китергәннәр. Аларның бер өлешен аллея буйлап утыртканнар, ә калганнарын, һәркайсында 9 ар суганча булырлык итеп, 3 клумбага утыртканнар. Аллеялар буенча ничә лалә чәчәге утыртканнар?

4*. Нинди очракта ике санның суммасы кушылучыларның берсенә тигез?

5*. Әниләре пәрәмәчләр пешергән. Илшатка барлык пәрәмәчләрнең дүртенче өлешен һәм тагын бер пәрәмәч биргән. Илшатка барысы 5 пәрәмәч тигән. Әниләре ничә пәрәмәч пешергән?

Искәрмә:

5*. Барлык пәрәмәчләрнең дүртенче өлеше: 5-1 = 4. Барлык пәрәмәчләр 16 (4-4 = 16). Җавап: 16.

IV ЧИРЕК

### «1000 эчендә телдән исәпләүләр» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның төрле биремнәрне үтәгәндә (гади аңлатмаларның кыйммәтләрен табу, зурлыкның берәмлекләре арасындагы бәйләнешне белеп куллану, тигезләмәләр чишү) 1000 эчендә натураль саннар өстендә телдән исәпләү алымнарын куллана белүләрен тикшерү.

## Вариант 1

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 400 + 300 | 70 + 60 | 230 • 2 |
| 800 - 600 | 130 - 20 | 480 : 4 |

2. 3 м 4 дм = дм

   450 см =м см
3. x + 15 = 40 тигезләмәсен чишегез.

**Вариант 2**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 300 + 300 | 90 + 80 | 210 • 4 |
| 900 - 400 | 160 - 50 | 680 : 2 |

2. 405 см = м см
   6 м 07 см = м см
3. *x* - 15 = 50 тигезләмәсен чишегез.

**Вариант 3**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 340 + 50 | 570 + 300 | 60 • 5 |
| 580 - 60 | 890 - 500 | 200 : 5 |

2. 70 мин = сәг мин
   1 сәг 20 мин = мин
3. *x* • 4 = 160 тигезләмәсен чишегез.

**Вариант 4**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 460 + 20 | 370 + 30 | 80 • 7 |
| 870 - 40 | 648 - 48 | 600 : 4 |

2. 4 дм 5 см = см
   450 см = м см
3. *x* : 8 = 120 тигезләмәсен чишегез.

**Вариант 5**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 530 + 80 | 710 + 90 | 200 •5 |
| 547 - 30 | 687 - 7 | 810 : 3 |

2. 37 дм = м дм
   68 см дм см
3. 900 - *x* = 600 тигезләмәсен чишегез.

**Вариант 6**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 470 + 60 | 60 + 90 | 500·2 |
| 735 - 70О | 248 - 30 | 560 : 4 |

2. 800 см = дм
   3 сәг = мин
3. 420 : *x* = 6 тигезләмәсен чишегез.

## IV чирек өчен контроль эш

Контроль эштә укучыларның 1000 эчендә (дистә аша күчеп һәм күчмичә) исәпләүләрнең язма ысулларын кулланып, кушу һәм алу гамәлләрен эшли белүләре (900—124 рәвешендәгеләрне кертмичә), ике һәм өчурынлы саннарны берурынлы санга тапкырлый һәм өчурынлы санны берурынлы санга бүлә белүләре, турыпочмаклык төзи һәм аның периметрын таба белүләре тикшерелә.

### Вариант 1

1. Исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 316 | 124 | _653 | _422 |
| ±253 | ±469 | 120 | 105 |

2. Тапкырлау һәм бүлүне башкарыгыз:

234-2 215-3 936 : 3 496 : 4

3. Ягының озынлыгы 5 см булган квадрат сызыгыз һәм аның барлык яклары суммасын табыгыз.

4*. Алтыпочмак ике дүртпочмакка бүленерлек итеп, кисемтә үткәрегез (рәс. 64).

5*. 40 дистә һәм 4 берәмлеге булган санны языгыз.

### Вариант 2

1. Исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 624 | 463 | _984 | _526 |
| ±351 | ±154 | 763 | 234 |

2. Тапкырлау һәм бүлүне башкарыгыз:

123-3 462-2 864 : 4 396 : 3

3. Ягының озынлыгы 4 см булган квадрат сызыгыз һәм аның барлык яклары суммасын табыгыз.

4*. Бишпочмак ике дүртпочмакка бүленерлек итеп, кисемтә үткәрегез (рәс. 65).

5*. Шкафта 3 итәк һәм 4 кофта бар. Бу әйберләрдән ничә төрле костюм ясап була?

Искәрмә:

5*. Чишү: 3 • 4 == 12. Җавап: 12 костюм.

### Вариант 3

1. Исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 476 | 514 | _804 | _563 |
| +283 | +296 | 62 | 427 |

2. Тапкырлау һәм бүлүне башкарыгыз:

231-3 32 -5 126 : 6 528:4

3. Якларының озынлыклары 3 см һәм 5 см булган турыпочмаклык сызыгыз һәм барлык якларының озынлыклары суммасын исәпләгез.

4*. Заводта өч көпчәкле балалар велосипедлары ясыйлар. Бер велосипед өчен 2 кечкенә, бер зур көпчәк кирәк. 25 кечкенә, 30 зур көпчәктән ничә велосипед җыярга була?

5*. Түгәрәкне 2 кисәккә бүләләр һәм төрле төстәге карандашлар белән буярга булалар. Әгәр кызыл, яшел һәм зәңгәр карандашлар булса, моны ничә ысул белән башкарырга мөмкин?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: 12 велосипед.
5*. Җавап: 3 ысул: кызыл, яшел; кызыл, зәңгәр; яшел, зәңгәр.

## Вариант 4

1. Исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| $\begin{array}{r} 238 \\ +\underline{456} \end{array}$ | $\begin{array}{r} 389 \\ +\underline{465} \end{array}$ | $\begin{array}{r} _152 \\ \underline{47} \end{array}$ | $\begin{array}{r} _405 \\ \underline{293} \end{array}$ |

2. Тапкырлау һәм бүлүне башкарыгыз:

104-2 63-7 736 : 8 625 : 5

3. Якларының озынлыклары 4 см һәм 3 см булган турыпочмаклык сызыгыз һәм барлык якларының озынлыклары суммасын табыгыз.

4*. Дистәләр саны берәмлекләр саныннан 2 тапкыр кечерәк булган барлык икеурынлы саннарны языгыз.

5*. Турыпочмаклыкның барлык якларының суммасы 10 см. Әгәр якларының озынлыклары сантиметрлар белән күрсәтелсә, ничә төрле турыпочмаклык төзеп булыр? Бу турыпочмаклыкларның якларының озынлыклары нинди булуы мөмкин, языгыз.

Искәрмәләр:

4*. Җавап: 12; 24; 36; 48.
5*. Ике турыпочмаклык. Берсенең яклары 1 см һәм 4 см, икенчесенеке — 2 см һәм 3 см.

**Вариант 5**

1. Исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 79 | 367 | _624 | _530 |
| +98 | +483 | 96 | 384 |

2. Тапкырлау һәм бүлүне башкарыгыз:

76-8 265-3 459 : 9 469 : 7

3. Квадратның барлык якларының суммасы 20 см. Бу квадратны төзегез.

4*. Букетта ак канәфер чәчәкләре кызылларыннан 2 тапкырга артыграк, ә кызыл канәфер чәчәкләре ал чәчәкләрдән 2 тапкырга артыграк. Ак чәчәкләр алларыннан ничә тапкырга артыграк?

5*. һәр цифры үзеннән алда килгәненнән 1 гә зуррак булган барлык өчурынлы саннарны языгыз.

Искәрмәләр:
4*. Җавап: 4 тапкыр.
5*. Җавап: 123, 234, 345, 456, 567, 678, 789.

**Вариант 6**

1. Исәпләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 67 | 269 | _152 | _803 |
| +84 | +731 | 96 | 794 |

2. Тапкырлау һәм бүлүне башкарыгыз:

89-5 168-2 576 : 8 822 : 3

3. Турыпочмаклыкның ике капма-каршы якларының озынлыклары суммасы 12 см, ә калган ике ягының озынлыклары суммасы 8 см. Бу турыпочмаклыкны сызыгыз.

4*. 12 пычак һәм 6 чәнечке сатып алганнар. Кунаклар килгәнче өстәл әзерләгәндә 8 предметны алып куйганнар. Алган предметлар арасында пычак бармы? Җавапларның берсен сайлагыз:

1) Әйе. 2) Юк. 3) Белмим.

5*. Ике клумбада 18 кашкарый үсә. Бер клумбадагы кашкарыйлар икенчесендә үсүче кашкарыйларның яртысы кадәр. Һәр клумбада ничә кашкарый үсә?

Искәрмәләр:
4*. Җавап: Әйе.
5*. Түбәндәгечә фикер йөртик. Икенче клумбадагы кашкарыйларны урталай бүлик. Ул чакта 3 «ярты» кашкарыйлар 18 була. Кашкарыйларның яртысы (беренче клумбадагы кашкарыйлар саны) 6 (18 : 3 = 6). Икенче клумбада 12 кашкарый (6 • 2 = 12). Җавап: 6 кашкарый, 12 кашкарый.

# ДҮРТЕНЧЕ СЫЙНЫФ

## I ЧИРЕК

## Кереш контроль эше

Эшнең максаты — укучыларның 3 нче сыйныф программасын үзләштерүләренең ныклыгын тикшерү. Бу эшкә укучыларның, нульне дә кертеп, берурынлы саннарны тапкырлый һәм бүлә белүләрен, таблицаны кулланмыйча тапкырлый һәм бүлә, язма ысуллар кулланып, 1000 эчендә исәпләүләр, арифметик мәсьәләләр чишә белүләрен тикшерергә мөмкинлек биргән биремнәр кертелгән.

### Вариант 1

1. Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 5 • 3 = | 0 • 5 = | 14 • 2 = |
| 12 : 4 = | 8 • 3 = | 11 • 8 = |
| 28 : 7 = | 9:9 = | 23 • 3 = |
| 3 • 9 = | 27 : 9 = | 96 : 3 = |
| 5 • 6 = | 35:5 = | 80 : 4 = |

2. Гамәлләрне эшләгез:

$$\begin{array}{r}365\\+137\\\hline\end{array}\qquad\begin{array}{r}536\\-284\\\hline\end{array}\qquad\begin{array}{r}38\\\times\ \ 6\\\hline\end{array}\qquad 207\,\underline{|\ 3}$$

3. 56 кг мандаринны тигез итеп 7 ящикка салганнар. Мәктәпкә 3 ящик мандарин җибәргәннәр. Мәктәпкә ничә килограмм мандарин җибәргәннәр?

4*. Беренче баскетболчы боҗрага туп ыргытканда 50 ыргытудан 20 сен боҗрага керткән, ә икенчесе 50 ыргытудан 40 ын керткән. Кайсы баскетболчының нәтиҗәсе яхшырак һәм ничә тапкырга?

5*. Кинозалда 600 тамашачы булган. Тамаша башланганчы тамашачылар саны өчтән бергә арткан. Моннан соң кинозалда күпме тамашачы булган?

Искәрмә:

4*. Икенче баскетболчы тупны ешрак кертә, шуңа күрә аның нәтиҗәсе дә яхшырак (2 тапкырга): 40 : 20 = 2.

### Вариант 2

1. Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 5 • 5 = | 48 : 6 = | 13 • 3 = |
| 12 : 3 = | 14 : 7 = | 42 • 2 = |
| 21 : 7 = | 0:3 = | 14 • 5 = |
| 6 • 4 = | 9 ■ 1 = | 48 : 4 = |
| 8 • 8 = | 7 • 4 = | 60 : 3 = |

2. Гамәлләрне эшләгез:

$$\begin{array}{r} +\,129 \\ \underline{65} \end{array} \qquad \begin{array}{r} -\,412 \\ \underline{153} \end{array} \qquad \begin{array}{r} 52 \\ \times\,\underline{8} \end{array} \qquad 638\,\underline{|\,2\ }$$

3. Алсуга 15 яшь. Алмаз Алсудан 3 тапкырга кечерәк, ә Айдар Алмаздан 3 яшькә зуррак. Айдарга ничә яшь?

4*. 9 га бүленерлек сан килеп чыксын өчен, 2 санының уң ягына нинди цифр язарга кирәк?

5*. Сәгать көн уртасын күрсәтә. Циферблат түгәрәгенең дүртенче өлешен
сәгать теле
минут теле күпме вакытта үтәр?

Искәрмә:

5*. Җавап: Сәгать теле 3 сәгатьтә, минутныкы 15 минутта.

## Вариант 3

1. Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 45:9= | 7·8= | 15·2 = |
| 4 • 8 = | 30 : 5 = | 40 • 4 = |
| 63:7 = | 72:9 = | 18·5 = |
| 9 • 8 = | 7 • 6 = | 48 : 3 = |
| 0·0= | 1·8= | 24:12 = |

2. Гамәлләрне эшләгез:

$$\begin{array}{r} 523 \\ \underline{+186} \end{array} \qquad \begin{array}{r} -\,231 \\ \underline{97} \end{array} \qquad \begin{array}{r} 242 \\ \times\,\underline{4} \end{array} \qquad 912\,\underline{|\,4\ }$$

3. Һәр капчыкта 15 кг бәрәңге бар. Бер машинага 4 капчык, икенчесенә 3 капчык төягәннәр. Икенче машинага беренчесенә караганда ничә килограммга кимрәк бәрәңге төягәннәр?

4*. Яклары озынлыгы 4 см булган ике квадратны берсе өстенә икенчесен салып ябыштыралар, ябыштыру киңлеге 1 см. Барлыкка килгән турыпочмаклыкның үлчәмнәрен табыгыз.

5*. Баскетбол тубын боҗрага ыргытканда, Вәлиев 45 ыргытудан 15 ен кертә, ә Шәрипов 60 ыргытуда 15 ен кертә. Кайсының нәтиҗәсе яхшырак: Вәлиевныкымы яки Шәриповныкымы?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: 4 см, 7 см.
5*. Җавап: Вәлиевныкы.

**Вариант 4**

1. Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 15 : 5 = | 40 : 8= | 17 • 3 = |
| 27 : 3 = | 5 • 7 = | 80• 5 = |
| 8 • 6 = | 63 : 9 = | 42• 4 = |
| 4 • 9 = | 9 • 8 = | 51 : 3 = |
| 0 : 6 = | 4 • 7 = | 96 : 24 = |

2. Гамәлләрне эшләгез:

$$\begin{array}{r} 309 \\ +\underline{495} \end{array} \qquad \begin{array}{r} _560 \\ \underline{469} \end{array} \qquad \begin{array}{r} 118 \\ \times\underline{\quad 8} \end{array} \qquad 954 \,\underline{|\,3}$$

3. Клуб өчен 24 туп сатып алганнар. Барлык тупларның өченче өлеше — футбол туплары. Волейбол туплары футболныкыннан 2 тапкырга азрак. Клуб өчен ничә волейбол тубы алганнар?

4*. Торттан бишпочмак формасындагы кисәкне ничек кисеп алырга (рәс. 66)?

5*. Фанер кисәгеннән 5 тигез квадрат кисеп алып була. 48 шундый квадрат кисү өчен ничә табак фанер кирәк булыр?

Искәрмә:

5*. Чишү: 48 не 5 кә калдыклы бүлик 48 : 5 = 9 (кал. 3) Җавап: 10 табак.

**Вариант 5**

1. Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 6 • 6 = | 30 : 6 = | 47 • 8 = |
| 8 • 4 = | 5 • 4 = | 36 • 5 = |
| 40 : 5 = | 48 : 8 = | 92 • 7 = |
| 7 • 9 = | 0 • 1 = | 640 : 4 = |
| 64 : 8 = | 7 • 7 = | 98 : 14 = |

2. Гамәлләрне эшләгез:

$$\begin{array}{r} 624 \\ \pm\underline{376} \end{array} \qquad \begin{array}{r} _821 \\ \underline{699} \end{array} \qquad \begin{array}{r} 134 \\ \times\underline{\quad 6} \end{array} \qquad 800 \,\underline{|\,5}$$

3. Кибеткә кура җиләге, чия һәм кара карлыган китергәннәр. Барысы 500 кг. Барлык җиләкләрнең яртысы — кура җиләге, ә җиләкләрнең дүртенче өлеше — чия. Кура җиләген чиягә караганда ничә тапкырга артыграк китергәннәр?

4*. 21 м тукымадан 5 бертөрле күлмәк тегеп була. 42 м шундый тукымадан ничә күлмәк тегеп булыр?

5*. Мин бер сан уйладым, аңа 5 не куштым, нәтиҗәне 10 тапкырга зурайттым һәм 90 саны килеп чыкты. Уйлаган санны табыгыз.

Искәрмәләр:

4*. Укучылар түбәндәгечә фикер йөртергә тиешләр: тукыма 2 тапкырга артыграк булгач, күлмәкләр саны да 2 тапкырга артыграк булыр. Чишү: 42 : 21 = 2; 5 • 2 = 10.

5*. Мәсьәлә чишүне «азагыннан» башлыйк. Санны 10 тапкыр зурайткач, 90 килеп чыккан, димәк, зурайтканчы 9 (90 :10 = 9) булган. Уйлаган сан 4 (9 - 5 = 4) кә тигез.

**Вариант 6**

1. Җавапларын языгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 7 • 7 = | 9 • 6 = | 53 • 9= |
| 9·4 = | 36 : 9 = | 45 • 7= |
| 32 : 8 = | 0 • 7 = | 103 • 4= |
| 63:9 = | 5:8 = | 120:15 = |
| 9 • 8 = | 56 : 7 = | 850 : 5= |

2. Гамәлләрне эшләгез:

$$\begin{array}{r} 167 \\ +385 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 608 \\ -299 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 263 \\ \times \quad 4 \\ \hline \end{array} \qquad 954 \,\underline{|\,6}$$

3. Мәктәпнең өченче сыйныфында 200 укучы укый. Аларның дүртенче өлеше бишлегә генә укыйлар. Дүртенче сыйныфларда 150 укучы. Аларның бишенче өлеше бишлегә генә укучылар. Кайсы сыйныфларда бишлегә генә укучылар күбрәк һәм күпмегә?

4*. Суммасы 15 кә тигез булган эзлекле килүче өч сан языгыз.

5*. Спорт түгәрәгендә кызлар малайлардан 2 тапкырга азрак. Түгәрәккә тагын 5 кызны алгач, кызлар саны малайлар белән тигезләшкән. Түгәрәктә ничә кыз булды?

Искәрмәләр:

4*. Мәсьәлә сайлап алу юлы белән чишелә. Җавап: 4, 5, 6.
5*. Җавап: 10 кыз.

## I чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның санның унарлы составын белүләрен, күбурынлы саннарны разрядлы кушылучылар рәвешендә яза белүләрен, күбурынлы саннарны куша һәм ала белүләрен, нурлыкларның берәмлекләре арасындагы бәйләнешне белүләрен, күппочмакның периметрын исәпли белүләрен тикшерү.

### Вариант 1

1. 1297 санын разряд кушылучылары суммасы рәвешендә күрсәтегез.
2. Гамәлләрне эшләгез:

$$\begin{array}{r} -2136 \\ \underline{864} \end{array} \qquad \begin{array}{r} -3150 \\ \underline{1635} \end{array} \qquad \begin{array}{r} -800 \\ \underline{154} \end{array}$$

3. 15 мм = ___см ___ мм
   1250 кг =____т ___кг
   24 км =____м
   30 см = ____ мм
   2 мин =____ с
   1 сәг 30 мин =____мин
4. Кирәкле үлчәүләрне башкарыгыз, өчпочмак периметрын табыгыз һәм нәтиҗәне сантиметрларда языгыз (рәс. 67).

5*. Иң зур алтыурынлы санны языгыз.

6*. Язылышларында кайбер цифрлары урынына нокталар куелган ике санны чагыштырып буламы? < яки > тамгаларын язмалар дөрес булырлык итеп куегыз:

2 ....     9 ....
.... 3     ....5

Искәрмәләр:

5*. Җавап: 999 999.

6*. Беренче очракта ике сан да бишурынлы. Беренче санда дистә меңнәр саны азрак, димәк, ул икенчесенә караганда кечерәк. Икенче очракта беренче сан дүртурынлы, ә икенчесе өчурынлы. Соңгы цифрларның нинди булуына карамастан, беренче сан икенчесеннән зуррак.

### Вариант 2

1. 4158 санын разряд кушылучылары суммасы рәвешендә күрсәтегез.

2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 5308 | _4863 | _300 |
| ±497 | 872 | 97 |

3. 3 сәг = ____мин
25 км =____м
8 т =____кг
1 мин 25 с =____с
16 дм = ____м____ дм
2500 г = ____кг____ г
4. Кирәкле үлчәүләрне башкарыгыз (рәс. 68), дүртпочмакның периметрын табыгыз һәм нәтиҗәне сантиметрларда языгыз.
5*. Иң зур бишурынлы сан языгыз.
6*. Шакмакларга нинди гамәл тамгалары язгач һәм кая җәяләр куйгач, түбәндәге тигезлек дөрес була:

5 □ 5 □ 5 = 2 ?

**Вариант 3**

1. 3105 санын разряд кушылучылары суммасы рәвешендә күрсәтегез.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 78564 | _43872 | _1000 |
| ±17827 | 6384 | 298 |

3. 300 см = ____ м
25 000 мм = ____м
3600 с =____сәг
5 т 200 кг =____кг
2 сәг 15 мин =____мин
1350 см = ____м____ см
4. Кирәкле үлчәүләр башкарыгыз, өчпочмак периметрын табыгыз (рәс. 69) һәм нәтиҗәне сантиметрларда һәм миллиметрларда языгыз.
5*. Барлык цифрлары да төрле булган иң зур алтыурынлы сан языгыз.
6*. Белмәмеш су коенырга уйлаган. Чишенгән, киемнәрен яр буенда калдырып, суга кергән һәм йөзеп киткән. «Мин хәзер елганы өч тапкыр йөзеп чыгам да, киенеп, өйгә кайтып киләм»,— дип уйлаган. Сез ничек уйлыйсыз: судан чыккач, яр буенда ул үз киемнәрен табармы? Җавапны аңлатыгыз.

Искәрмәләр:

5*. Җавап: 987 654.
6*. Җавап: Таба алмас. Елганы 3 тапкыр йөзеп чыгып, ул елганың икенче ягында булыр.

## Вариант 4

1. 5024 санын разряд кушылучылары суммасы рәвешендә күрсәтегез.
2. Гамәлләрне эшләгез:

$$\begin{array}{r} 50768 \\ +\underline{39327} \end{array} \qquad \begin{array}{r} 61923 \\ +\underline{8165} \end{array} \qquad \begin{array}{r} 2000 \\ -\underline{1074} \end{array}$$

3. 200 мм = ____дм
   600 с =____мин
   15 000 кг = ____т
   2530 м = ____км ____ м
   180 дм = ____м____ дм
   76 мин = ____сәг ____мин
4. Кирәкле үлчәүләрне башкарыгыз, дүртпочмакның периметрын табыгыз (рәс. 70) һәм нәтиҗәне сантиметрларда һәм миллиметрларда языгыз.

5*. Сыйныфта 40 укучы укый. Бүген 2 укучы мәктәпкә килмәгән. Сыйныф укучыларының ничәнче өлеше мәктәпкә килмәгән?

6*. Барлык цифрлары төрле булган алтыурынлы иң кечкенә сан языгыз.

Искәр мәләр :

5*. Җавап: Егерменче.
6*. 102 345.

## Вариант 5

1. 47015 санында а) дистәләр; б) йөзләр; в) меңнәр ничә булуын языгыз.
2. Саннарны баганалап языып, гамәлләрне эшләгез:

   72368 + 1935 2000 - 79 40100 - 2607

3. 4600 мм =____ м ____см
   3 сәг 15 мин =____мин
   6 т =____г
   3 кг 5 г =____ г
   80 мин = ____с
   5060 м = ____км ____ м

4. Турыпочмаклык булмаган нинди дә булса дүртпочмак төзегез. Кирәкле үлчәүләрне башкарыгыз, аның периметрын табыгыз һәм нәтиҗәне сантиметрларда һәм миллиметрларда языгыз.
5*. 21 гасыр нинди елдан башланыр?
6*. 1 м 20 см озынлыгында тасма сатып алалар. Аның өчтән икесен костюм бизәү өчен тоталар. Күпме тасма тотылган?

Искәрмә:

5*. Җавап: 2001 елдан.

**Вариант 6**

1. 50138 санында а) меңнәр; б) йөзләр; в) дистәләр ничә булуын языгыз.
2. Саннарны баганалап язып, гамәлләрне эшләгез:

3297 + 14995        5000 - 126        30101 - 6917

3. 96 сәг =_____мин
5 км =_____мм
305 дм = _____м _______ дм
2070 кг =___т _____кг
4 м 3 мм = _______ мм
90 мин = сәг мин
4. Нинди дә булса өчпочмак төзегез, кирәкле үлчәүләр башкарыгыз, аның периметрын табыгыз һәм нәтиҗәне сантиметрларда һәм миллиметрларда языгыз.
5*. Җәйге балалар лагерена 2400 кг кәбестә китергәннәр. Берничә көннән соң кәбестә запасы дүрттән бер өлешкә кимегән. Күпме кәбестә калган?
6*.Шахта лифты җир өстендә тора. Башта ул 115м шахтага төшә, аннан соң 30 м өскә менә, шуннан соң тагын 10 м аска төшә һәм, ниһаять, 30 м өскә күтәрелә. Лифт кайда була: җир астындамы яки аның өстендәме?

Искәрмә:

6*. Җир астында.

II ЧИРЕК

## «Күбурынлы санны берурынлы санга тапкырлау һәм бүлү» темасы бунча контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның күбурынлы саннар белән эшли белүләрен (берурынлы санга тапкырлау һәм бүлү) тикшерү.

**Вариант 1**

1. Тапкырлагыз:

4123 • 2 603 • 8 1200 • 4 653 • 7

2. Бүлегез:

948 : 4 1263 : 3 1635 : 5 5910 : 3

**Вариант 2**

1. Тапкырлагыз:

1312·3 302 4 4300·2 267·5

2. Бүлегез:

7528 : 2 678 : 3 9100 : 5 2856 : 4

**Вариант 3**

1. Тапкырлагыз:

2106·9 1236·4 150·7 3600·5

2. Бүлегез:

2448 : 3 10377 : 9 8700 : 5 8910 : 9

**Вариант 4**

1. Тапкырлагыз:

5207·8 2654·3 7500·4 250·8

2. Бүлегез:

15 846 : 3 6170 : 5 9100 : 7 7040 : 8

**Вариант 5**

1. Тапкырлагыз:

1309 • 8 3681 • 7 460 • 5 12 500 • 6

2. Бүлегез:

4085 : 5 18 768 : 6 872 : 8 2163 : 7

**Вариант 6**

1. Тапкырлагыз:

7008·5 3864·6 1560·4 38 000·5

2. Бүлегез:

2575 : 5 7516 : 4 4320 : 4 3256 : 8

## «Тизлек, вакыт, юл» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның турысызыклы тигез хәрәкәтенең тизлеге, юлы һәм вакыты арасындагы бәйләнешләрне аңлауларын тикшерү.

### Вариант 1

1. Поезд 6 сәгатьтә бер дә туктамыйча 480 км юл үткән. Поезд нинди тизлек белән барган?
2. Велосипедчы 17 км/сәг тизлек белән бара. Ул 2 сәгатьтә ничә километр юл үтәр?
3. Кеше 5 км/сәг тизлек белән бара. 30 км араны ул ничә сәгатьтә үтәр?

### Вариант 2

1. Илшат минутка 75 сүз укый. Шул тизлек белән ул 10 минутта ничә сүз укыр?
2. Автомашина 4 сәгатьтә 300 км юл үткән. Ул нинди тизлек белән барган?
3. Бөҗәк 5 м/сәг тизлек белән үрмәли. 100 метрны ул күпме вакытта үтәр?

### Вариант 3

1. Космик корабль 8 км/с тизлек белән оча. 1 минутта ул ничә километр очып үтәр?
2. Ракета 3 с та 18 км очып үтә. Бер секундтан соң аның тизлеге 2 км/с ка арткан. Ракетаның дүртенче секунд ахырындагы хәрәкәт итү тизлеген табыгыз.
3. Поезд 2 сәг тә 190 км юл үтә, ә аннары тизлеген 10 км/сәг кә киметә. Поездның яңа тизлеген табыгыз.

### Вариант 4

1. 1 минутта Марат 60 м юл үтә. 1 секундта Марат ничә метр юл үтәр?
2. Турист 4 сәгатьтә 24 км юл үткән. Әгәр турист тизлеген 2 км/сәг кә арттырса, бу араны ул күпме вакытта үтәр иде?
3. Кылычбалык 100 км/сәг тизлек белән йөзә. 30 минутта ул нинди ара йөзеп үтәр?

### Вариант 5

1. Ике аэродром арасы 3000 км. 850 км/сәг тизлек белән очучы самолет бу араны 3 сәгатьтә үтә алырмы?

2. Спортчы 30 секундта 300 м йөгереп үтә. Һәр минут саен ул ничә метр йөгереп үтәр?
3. Ракета тизлеге 8 км/с. 480 км ны ул ничә минутта очып үтәр?

**Вариант 6**

1. Җилкәнле көймә 4 сәгатьтә 28 км, ә сал 5 сәгатьтә 20 км йөзеп үткән. Көймәнең тизлеге салныкыннан күпмегә зуррак?
2. Наил күктә 1000 м/мин тизлек белән хәрәкәтләнүче нокта күрә. Бу тизлекне км/сәг тә күрсәтегез.
3. Умарта оясыннан 5 м/с тизлек белән очып чыга. Оядан 300 м ераклыктагы чәчәкле бакчага ул ничә минуттан соң очып җитәр?

## II чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты булып укучыларның күбурынлы саннар белән берничә арифметик гамәлне эченә алган аңлатмаларның кыйм-мәтләрен таба белүләрен, мәсьәләдәге зурлыкларны куша һәм ала, мәсьәләләр чишә белүләрен тикшерү тора.

**Вариант 1**

1. (1300 - 500) : 4 - 196 аңлатмасының кыйммәтен табы-гыз.
2. Базада 35 т кәбестә булган. 20 т 450 кг кәбестәне кибетләргә җибәргәннәр. Базада күпме кәбестә калган?
3. Поезд 3 сәгать 85 км/сәг тизлек белән барган, шуннан соң тагын 125 км юл үткән. Поезд туктаганчы ничә километр юл үткән?

4*. 5 санының уң һәм сул якларына 5 цифрын язып куя-лар. Сан ничә тапкырга зурайган?

5*. Алия — Сәкинә кызы, ә Сәкинә — Асия кызы. Алия Асиянең кеме була?

**Вариант 2**

1. 150·9 + 3618 : 9 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
2. Түгәрәк утырышы 9 сәг 20 мин та башлана һәм 45 мин дәвам итә. Утырыш сәгать ничәдә тәмамлана?
3. Металл шар пыяла шардан 2 тапкырга авыррак. 6 пыя-ла шарның массасы 480 г. 2 металл шарның массасын табыгыз. .

4*. Үлчәү тәлинкәләре тигезләнештә торалар. Үлчәүнең сул тәлинкәсенә 1 кг мамык, уң тәлинкәсенә 1 кг кадак куялар. Тигезләнеш бозылырмы? Җавапны аңлатыгыз.

5*. Ике көймәгә 12 кеше утыра, берсендә кешеләр саны икенчесенә караганда 2 тапкырга артыграк. Һәр көймәдә ничә кеше булуын табыгыз.

Искәрмә:

5*. Җавап: 8 кеше, 4 кеше. Мәсьәлә сайлап алу юлы белән чишелә.

## Вариант 3

1. 5 • (125 + 75): 20 + 80 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
2. Кызыл тасманың озынлыгы 9 дм 8 см, зәңгәр тасма кызылдан 12 см га кыскарак. Зәңгәр тасманың озынлыгын табыгыз.
3. Универмагка 50 төсле һәм 70 кара-ак телевизор китергәннәр. Телевизорларның алтынчы өлешен шул ук көнне сатканнар, ә калганнарын тигез итеп киләсе 4 көндә сатканнар. Бу көннәрнең һәркайсында ничәшәр телевизор сатканнар?

4*. *x* ның нинди кыйммәте өчен 200 : *x* өлеше иң кечкенә кыйммәт алыр?

5*. Кызларның һәркайсы — Гөлнар һәм Гөлназ — үз әнисе белән киногa барган. Кинога ничә кеше барган?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: *x* ның кыйммәте 200 булганда (x ның бу кыйммәтендә 200 : *x* аңлатмасының кыйммәте иң кечкенә кыйммәткә, 1 гә тигез була).
5*. Җавап: Өч яки дүрт.

## Вариант 4

1. 1250 - 250 • 4 + 250 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
2. Шторалар тегү өчен фабрика 1200 м, ә юка пәрдәләр тегү өчен 250 м 50 см га кимрәк ефәк тоткан. Юка пәрдәләр тегү өчен күпме ефәк тотылган?
3. Ательеда 150 күлмәк теккәннәр. Барлык күлмәкләрнең өчтән икесе балалар күлмәкләре, калганнары зурларныкы. Ательеда зурлар өчен күпме күлмәк теккәннәр?

4*. *a* ның нинди кыйммәтендә 500 : *a* аңлатмасы (өлеш) иң зур кыйммәткә ия булыр?

5*. Алия һәм Гөлиянең икесенең бергә алмалары, Шамил белән Камилнеке кадәр. Гөлиянең 5 алмасы, ә Шамил-

нең 8 алмасы бар. Кемнең алмасы күбрәк: Алиянекеме, әллә Камилнекеме?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: *а* ның кыйммәте 1 булганда.

5*. Җавап: Алиянеке.

## Вариант 5

1. 360 • 9 - (4000 - 2998) аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
2. Карбызның массасы 4 кг 350 г. Кавын карбыздан 1 кг 720 г га җиңелрәк. Кавынның массасын табыгыз.
3. Шәһәрдән авылга йөк машинасында 60 км/сәг тизлек белән 4 сәгатьтә барып җитәргә мөмкин. Бу араны тизлеге 2 тапкырга артыграк булган җиңел машина белән ничә сәгатьтә үтәргә мөмкин булыр?

4*. Сыйныфта 27 укучы. Малайлар кызларга караганда 7 гә артыграк. Бу сыйныфта ничә малай һәм ничә кыз?

5*. 15 зәңгәр һәм 10 маркалы конверт сатып алалар. 5 зәңгәр конвертта маркалар булган. Барысы ничә конверт сатып алганнар?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: 10 кыз, 17 малай. Мәсьәлә сайлап алу юлы белән чишелә.

5*. Җавап: 20 конверт.

## Вариант 6

1. 4187 + 713 • 4 - 1200 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
2. Минем сәгать 10 сәг 1 мин күрсәтә. Ул 3 мин ка алдарак. Чынлыкта вакыт күпме?
3. 1620 пачка чәйне ике киоскка бүлеп бирәләр. Беренче киоскка 4 ящик, икенчесенә шундый 5 ящик чәй җибәрәләр. Һәр ящикта ничә пачка чәй булган?

4*. Төрле сорттагы 5 конфет һәм төрле эчле 4 вафли бар.
1 конфет һәм 1 вафли алырга рөхсәт ителә. Ничә мөмкинлек булуы мөмкин?

5*. Кичен урамда + 1° температура булган. Иртәнгә ул 2° ка төшкән. Иртән температура күпме булган? Сез аны яза аласызмы?

Искәрмәләр:

4*.Җавап: 20 мөмкинлек (5 • 4 = 20).

5*. Җавап: - 1°. Укучылар ничек булдыра алалар, шулай язсыннар: «Минус 1 градус» яки «минус 1» һ. б.

## «Фигура мәйданы» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның «мәйдан» термины төшенчәсен аңлауларын, фигураның (шул исәптән, турыпочмаклыкның) мәйданын исәпли белүләрен, мәйдан берәмлекләрен һәм алар арасындагы бәйләнешләрне белүләрен тикшерү.

### Вариант 1

1. Мәйданнары тигез булган фигураларның номерларын языгыз (рәс. 71).
2. Һәр тигезлек дөрес булырлык итеп, шакмаклар эченә саннар языгыз:

   1 $м^2$ = ○ $дм^2$ 1 $м^2$ = □ $см^2$ 1 $дм^2$ — □ $см^2$
3. Турыпочмаклы участокның буе 5 м, иңе 3 м. Бу участокның мәйданын табыгыз.
4. Ягының озынлыгы 3 см булган квадрат сызыгыз. Аның мәйданын исәпләгез һәм нәтиҗәне квадрат сантиметрларда күрсәтегез.

### Вариант 2

1. Мәйданнары тигез булган фигураларның номерларын языгыз (рәс. 72).
2. Һәр тигезлек дөрес булырлык итеп, шакмаклар эченә саннар языгыз:

   1 $дм^2$ = □ $см^2$ 1 $м^2$ = □ $дм^2$ 1 $м^2$ = □ $см^2$
3. Түтәлгә җир җиләге утыртканнар. Түтәлнең иңе 2 м, буе 4 м. Түтәлнең мәйданын табыгыз.
4. Ягы 4 см булган квадрат сызыгыз. Аның мәйданын исәпләгез һәм нәтиҗәне квадрат сантиметрларда языгыз.

### Вариант 3

1. 1 һәм 2 фигураларының мәйданнарын чагыштырыгыз (рәс. 73). Кайсы фигураның мәйданы зуррак? Кирәкле җавапны сайлап алыгыз: 1) 1. 2) 2. 3) Белмим.
2. Квадрат метрларда күрсәтегез:

   600 $дм^2$;      10 000 $см^2$.
3. Турыпочмаклыкның буе 10 см, иңе 2 тапкырга кечерәк. Турыпочмаклыкның мәйданын табыгыз.
4. Турыпочмаклык формасындагы идәннең мәйданы 20 $м^2$. Бүлмәнең буе 5 м. Бүлмәнең иңен метрларда языгыз.

**Вариант 4**

1. А һәм В фигураларының мәйданнарын чагыштырыгыз (рәс. 74). Нәтиҗәне языгыз.
2. Квадрат сантиметрларда күрсәтегез:
   2м$^2$;          500 см$^2$.
3. Турыпочмаклыкның иңе 4 дм, буе иңеннән 5 тапкырга зуррак. Турыпочмаклыкның мәйданын табыгыз.
4. Турыпочмаклыкның мәйданы 36 см$^2$, буе 9 м. Аның иңе күпмегә тигез?

**Вариант 5**

1. Өчпочмакны турыпочмаклыкка тутырып төзеп бетерегез (рәс. 75) һәм төзелгән турыпочмаклыКның мәйданын табыгыз.
2. Квадрат дециметрларда күрсәтегез:
   2 м$^2$;          50 дм$^2$.
3. Яклары озынлыклары 2 см һәм 4 см булган турыпочмаклык төзегез.
4. Квадрат мәйданы 25 м$^2$, аның ягын уйлап табыгыз.

**Вариант 6**

1. 76 нчы рәсемдәге турыпочмаклык мәйданы буенча ике тигез өчпочмакка бүленгән. Кирәкле үлчәүләрне башкарыгыз һәм һәр өчпочмакның мәйданын исәпләгез.
2. Квадрат сантиметрлар белән күрсәтегез:
   3 м$^2$;          50 000 дм$^2$.
3. Ягының озынлыгы 4 см булган квадрат сызыгыз. Мәйданы квадрат мәйданы кадәр булган турыпочмаклык сызыгыз, ләкин аның иңе 2 см га тигез булсын. Турыпочмаклыкның буен язып куегыз.
4. Квадрат ягының озынлыгы 2 см. Аның мәйданын һәм периметрын исәпләгез.

## III чирек өчен контроль эш

Контроль эштәукучыларның күбурынлы саннарны ике һәм өчурынлы санга тапкырлый белүләре, күбурынлы саннарны ике һәм өчурынлы санга (берурынлы һәм икеурынлы санга бүленүгә китерелә торган очраклары) бүлә белүләре, арифметик мәсьәләләр (ике предметның бер юнәлештә яки капма-каршы юнәлешләрдә хәрәкәт итүгә мәсьәләләрне кертеп) чишә белүләре тикшерелә.

**Вариант 1**

1. Тапкырлауны башкарыгыз:
   1613          23614          127·362          150·60

2. Бүлүне башкарыгыз:

782 : 17 920 : 230 456 000 : 200

3. 6 бертөрле көмеш чәнечкенең массасы 540 г. Чәй кашыгы чәнечкедән 2 тапкырга авыррак. Шундый 4 кашыкның массасын табыгыз.
4*. Һәр тәүлек саен сәгать 4 минутка алга китә. 3 көннән соң сәгать төгәл вакытны күрсәтсен өчен, сәгатьнең минутлык телен алгамы яки арткамы һәм ничә минутка күчерергә кирәк?
5*. 77 нче рәсемдә сурәтләнгән фигураның мәйданын табыгыз. Үлчәмнәр сантиметрларда бирелгән.

**Вариант 2**

1. Тапкырлауны башкарыгыз:

24·15 18412 216·123 250·40

2. Бүлүне башкарыгыз:

322 : 14 4250 : 17 258 000 : 300

3. Бер кисәктә 5 м тукыма, икенчесендә шундый 7 м тукыма бар. Ике кисәк өчен 36000 сум акча түләгәннәр. Тукыманың 1 м ның бәясен табыгыз.
4*. Иртәнге сәгать 8 дә сәгатьне дөресләп куйганнар. Бу сәгать һәр сәгать саен 15 секундка артка кала. Шул көнне 12 сәгатьтә бу сәгать күпме вакытны күрсәтер?
5*. Кәрзиндә алмалар саны 10 нан кимрәк. Бу алмаларны ике яки өч кызга тигез итеп бүлеп бирергә мөмкин. Кәрзиндә ничә алма булуын табыгыз.

Искәрмә:
5*. Җавап: 6 алма.

**Вариант 3**

1. Тапкырлауны башкарыгыз:

49·84 507·96 351·634 7 300·28

2. Бүлүне башкарыгыз:

8 357 : 61 9 540 : 60 1 728 : 48

3. Һәр көнне 30 бит укып, китапны 4 көндә укып бетердем. Апам көнгә 10 биткә артыграк укыган. Бу китапны апам ничә көндә укып бетерер?
4*. ТУ—154 самолетының тизлеге 900 км/сәг. 15 минутта бу самолет күпме ара очып үтәр?

5*. Күппочмакның янәшә булмаган ике түбәсен тоташтыручы кисемтә күппочмакның диагонале дип атала. Бишпочмакның барлык диагональләрен үткәрегез. Сез ничә диагональ үткәрдегез (рәс. 78)?

Искәрмә:

4*. Чишү. 15 мин — чирек сәгать ул. 900 : 4 =225.
Җавап: 225 км.

**Вариант 4**

1. Тапкырлауны башкарыгыз:

96·69 406·38 267·459 614·180

2. Бүлүне башкарыгыз:

. 780 : 60 3 640 : 56 26 080 : 84

3. Велосипедчы һәм мотоциклчы бер үк вакытта авылдан шәһәргә барырга чыгалар. Велосипедчының тизлеге 14 км/сәг, ә мотоциклчыныкы 60 км/сәг. Бер сәгатьтән соң велосипедчы мотоциклчыдан ничә километрга артка кала?
4*. 10 литрлы банкага мөлдерәмә итеп бал салганнар. Банканың массасы 15 кг. Биш литрлы банкага ничә килограмм бал сыяр?
5*. Ике яшел һәм өч кызыл нокта билгеләгәннәр. Бер очы яшел, икенчесе кызыл булган ничә кисемтә төзеп булыр?

Искәрмәләр:

4*. Биш литрлы банкага ун литрлыга караганда 2 тапкырга кимрәк бал сыяр. Шуңа күрә анда 7 кг 500 г бал булыр.
5*. Укучылар рәсемен асыйй алалар. Чишү: 2 • 3 = 6.
Җавап: 6.

**Вариант 5**

1. Тапкырлауны башкарыгыз:

609·800 160·380 752·391 238·406

2. Бүлүне башкарыгыз:

7110 : 30 560 700 : 700 19 536 : 48

3. Ике тепловоз бер-берсенә каршы 75 км/сәг һәм 85 км/сәг тизлекләр белән киләләр. Очрашканга кадәр 1 сәгать элек алар нинди ераклыкта булырлар?

4*. Турыпочмаклыкның мәйданы 12 $см^2$. Бу турыпочмаклыктан мәйданы 4 $см^2$ булган ничә квадрат кисеп алып булыр?

5*. Мин бер сан уйладым һәм аңа икенче санны куштым. Нәтиҗәдә һәрчак мин уйлаган саннан зуррак сан чыгармы? Бирелгән җаваплардан сайлап берсен языгыз: 1) Әйе. 2) Юк. 3) Белмим.

Искәрмәләр:

4*. Күп укучылар турыпочмаклыктан 3 квадрат кисәргә мөмкин дип уйларлар (12:4 = 3). Ләкин бу алай түгел. Мәсьәләдә турыпочмаклыкның яклары озынлыгы турында бернәрсә дә әйтелмәгән. Әгәр якларының озынлыклары 1 см һәм 12 см булса, мондый турыпочмаклыктан бер квадрат та кисәргә мөмкин түгел. Әгәр якларының озынлыклары 2 см һәм 6 см булса, 3 квадрат кисәргә мөмкин, әгәр 3 см һәм 4 см булса, ул чакта 2 квадрат булыр. Укучылар мондый рәвештәрәк җавап язарга тиешләр. Җавап: 0,2 яки 3.

5*. Җавап: Юк. Әгәр икенче сан 0 булса, нәтиҗә уйлаган санга тигез булыр, ә аннан зур түгел.

## Вариант 6

1. Тапкырлауны башкарыгыз:

77•77 920•380 761•183 256•304

2. Бүлүне башкарыгыз:

1900 : 50 51 600 : 43 27 090 : 45

3. Идән паласының иңе 2 м, ә буе 4 тапкырга зуррак. Бу паласның 1 $м^2$ы 12 000 сум тора.Палас ничә сум тора?

4*. Тизлеге 8 км/с булган ракетаның тизлеге самолетныкыннан 32 тапкырга зуррак. Самолетның тизлеген исәпләп табыгыз.

5*. Санны нинди дә булса икенче санга тапкырлагач, ул сан зурая дип уйлау дөресме? Бирелгән җаваплардан сайлап, берсен языгыз: 1) Әйе. 2) Юк. 3) Белмим.
Мисаллар китерегез.

Искәрмәләр:

4*. 8000 : 32 = 250. Җавап: 250 м/с.

5*. Җавап: Юк. Әгәр санны 0 гә тапкырласаң, нәтиҗә 0 була (нәтиҗә саннан кечерәк). Әгәр санны 1 гә тапкырласаң, сан зураймас (шул ук калыр).

## IV ЧИРЕК

Эшнең максаты — укучыларның күбурынлы саннар өстендә арифметик гамәлләр эшли белүләрен, җәяләр һәм җәяләрсез язылган һәм гамәлләр үтәү тәртибе нигезендә санлы аңлатмаларның кыйммәтләрен таба белүләрен, укучылар өйрәнгән зурлыклар арасындагы бәйләнешләрне эченә алган арифметик мәсьәләләр чишә белүләрен, турыпочмаклыкның (квадратның) периметрын һәм мәйданын таба белүләрен тикшерү.

### Вариант 1

1. Гамәлләрне эшләгез:

   615 + 357 1280 - 693 427·6 11 664:108

2. 60 + 30 : (45 - 30) аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Кибеттә 85 кг лимон, лимоннарга караганда 3 тапкырга артыграк апельсин, ә мандариннарны лимоннарга караганда 20 кг га артыграк сатканнар. Барысы ничә килограмм цитруслар сатканнар?
4. Ягының озынлыгы 4 см булган квадрат сызыгыз. Аның периметрын һәм мәйданын табыгыз.

5*. Доктор Пилюлькин Белмәмешкә һәр 20 минут саен берәр кашык дару эчәргә дип рецепт язып бирә. Әгәр Белмәмешнең алган даруы өч тапкыр эчәрлек булса, бу дару күпме вакытка җитәр?

6*. 10 тәлинкәдә абрикослар ята. Беренче тәлинкәдән 1 абрикос алалар, ә калган тәлинкәләрнең һәркайсыннан алдагысына караганда 1 абрикоска артыграк алганнар. Соңгы тәлинкәдән ничә абрикос алганнар?

Искәрмә:

5*. Җавап: 40 минут.

### Вариант 2

1. Гамәлләрне эшләгез:

   6804 + 2169 1516-927 86·39 7080:3

2. 140 - 40 : 5 + 3 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Бер кисәктә 45 м, ә икенчесендә 30 м ситсы бар. Барлык ситсыдан 25 бертөрле күлмәк теккәннәр. Һәр кисәк ситсыдан ничә күлмәк теккәннәр?
4. Якларының озынлыклары 3 см һәм 4 см булган турыпочмаклык сызыгыз. Аның периметрын һәм мәйданын табыгыз.

5*. Гастроном иртән сәгать 8 дән кичке сәгать 21 гә кадәр эшли; көндезге тәнәфес 14 сәгатьтән 15 сәгатькә кадәр. Сатып алучылар өчен гастроном ничә сәгать ачык була?

6*. 3 әр кашык шикәр һәм какао порошогы алалар. Әгәр бер кашык щикәр какаога караганда 5 г га авыррак булса, шикәрне ничә граммга артык алганнар?

## Вариант 3

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | |
|---|---|
| 5106 + 4952 | 186 • 4 |
| 30 506 - 9135 | 4158 : 27 |

2. 1500 : (50 + 25 • 2) аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. 3 бертөрле тартмада 15 кг печенье бар. Конфетлар салынган тартма печенье салынган тартмадан 3 кг га авыррак. 6 шундый тартмада ничә килограмм конфет булыр?
4. Буеның озынлыгы 5 см, иңе 1 см га кимрәк булган турыпочмаклык сызыгыз. Аның периметрын һәм мәйданын табыгыз.

5*. 1 кг алмадан 120 г кипкән алма чыга. 120 кг кипкән алма әзерләү өчен, күпме алма алырга кирәк?

6*. 1 км озынлыгындагы чыбыкның массасы 5 кг. 800 м озынлыгындагы чыбык кисәгенең массасы күпме?

Искәрмә:

6*. 100 м чыбыкның массасын тапсак, мәсьәлә җиңел чишелә: 5000 : 10 = 500 (г), 500 • 8 = 4000 (г) = 4 кг. Җавап: 4 кг.

## Вариант 4

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | |
|---|---|
| 7038 + 2947 | 44 • 75 |
| 10 305 - 9268 | 15 616 : 64 |

2. 320 - 80 + 20 : 5 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Кәрзиндә 20, ә сумкада 12 бертөрле баклажан бар. Сумкадагы баклажаннар кәрзиндәгеләргә караганда 3 кг 200 г га җиңелрәк. Барлык баклажаннарның массасын исәпләгез.
4. Бер ягының озынлыгы 3 см, ә икенчесенең озынлыгы 2 тапкыр зуррак булган турыпочмаклыкның мәйданын табыгыз. Бу турыпочмаклыкның периметры күпмегә тигез?

5*. Әниләре бер кирпеч ипине урталай бүлгән, ә соңыннан яртысын тагын 5 тигез кисәккә бүлгән. Шу биш кисәкнең һәркайсы бөтен ипинең нинди өлешен тәшкил итә?

6*. Өч бертуган кыз — Гөлназ, Гөлнар һәм Гөлнур фо тога төшеп, армиядәге абыйларына җибәрергә бул ганнар. Алар фотога өйләре каршындагы эскәмиягә утырып төшкәннәр. Нинди тәртиптә (сулдан уңга) алар утыра алырлар? Мөмкин булган барлык очракларны карагыз.

Искәрмә:

6*. 1) Гөлназ, Гөлнар, Гөлнур; 2) Гөлназ, Гөлнур, Гөлнар; 3) Гөлнар, Гөлназ, Гөлнур; 4) Гөлнар, Гөлнур, Гөлназ; 5) Гөлнур, Гөлназ, Гөлнар; 6) Гөлнур, Гөлнар, Гөлназ. Барысы 6 мөмкинлек.

## Вариант 5

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | |
|---|---|
| 528 + 9834 | 567 • 204 |
| 90 000 - 5093 | 11 664 : 108 |

2. 560 : 7 • 10 : 5 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Һәркайсына 6 м ситсы сарыф итеп, 40 юрган тышы теккәннәр. Шуның кадәр үк ситсыдан мендәр тышлары теккәннәр. Һәр мендәр тышын тегү өчен 1 м 20 см ситсы кирәк булса, ничә мендәр тышы теккәннәр?
4. Квадратның периметры 16 см. Аның мәйданын табыгыз.

5*. Фасоны һәм үлчәме бер үк төрле булган 2 күлмәк тегү өчен, 7 м ефәк кирәк. Шундый 10 м ефәктән ничә күлмәк тегеп булыр?

6*. Бүлмәнең буе 5 м, ә иңе 3 м. Бу бүлмәнең идәненә җәю өчен, иңе 20 см булган биш метрлы такталар китергәннәр. Идәнгә җәю өчен ничә такта тотылган?

Искәрмәләр:

5*. Бер күлмәк өчен өч ярым метр ефәк кирәк: 700 : 2 = 350 (см) = = 3 м 50 см. 3 күлмәк тегү өчен, 10 м дан күбрәк ефәк кирәк. Димәк, 10 м дан 2 генә күлмәк тегеп була. Җавап: 2 күлмәк.
6*. Мәсьәләне чишү өчен, бүлмә идәненең һәм тактаның мәйданын табу мәҗбүри түгел. Түбәндәгечә фикер йөртәбез: биш метрлы такталарны берсе янына икенчесен тыгыз итеп, бүлмә идәнен каплап бетерерлек итеп тезәбез. Бүлмә иңенә ничә такта салынса, такталар шуның кадәр кирәк булачак: 300 : 20 = 15. Җавап: 15 такта.

**Вариант 6**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | |
|---|---|
| 627 + 14 981 | 236 • 405 |
| 8 000 - 1 267 | 25 544 : 124 |

2. (270 + 30) • 20 : 4 аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.
3. Аралары 320км булган ике вокзалдан бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике электропоезд чыга һәм алар 2 сәгатьтән соң станциядә очрашалар. Аларның берсенең тизлеге 85 км/сәг. Икенче электропоездның тизлеген табыгыз.
4. Квадратның периметры 200 см. Аның мәйданын исәпләгез.

5*. Баклажаннар салынган ящикның массасы 25 кг. Баклажаннарның яртысын саткач, калган баклажаннар белән ящикның массасы 15 кг булган. Буш ящикның массасын белеп буламы?

6*. Бертигез 4 алманың массасы бер грейпфрут массасы кадәр. Бер алма һәм грейпфрутның массасы 750 г. Алманың массасын табыгыз.

И с кәрм ә:

5*. Болай фикер йөртәбез: Масса 10 кг га кимегән, чөнки алмаларның яртысын сатканнар. Димәк, барлык баклажаннарның яртысының массасы 10 кг. Ящигы белән бергә 15 кг. Моннан, буш ящик массасы 5 кг икәнлеге ачыклана. Җавап: 5 кг.
6*. Үлчәүгә 1 грейпфрут урынына 4 алма салсак, 1 алма белән бергә 5 алма була, аларның массасы 750 г. Бер алманың массасы 150 г (750 : 5 = 150). Җавап: 150 г.


1
2
3
4


5
6
7
8




9

10

11

12



13




14



15

5 4

16



17



18

5

19


20
21
4
22
23

24



25



26

3 − 2 = 1

3 + 1 = 4

5 − 2 = 3

27



28



29



3 − 2 = 1

3 + 2 = 5

30

31

32

33

34

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | 4 | | | 7 | | | |

35

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | |

36

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |

37

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

38

 + 2 = 7

| |
|---|
| |

39




40




41




42




43




44



45




46



47




48




49

1△−△0=1

50




51




52



53



54



55



56



1 2 3 4

**Җавап: 1, 2, 3, 4**

57



1 2 3 4

58




59




60




61




62



63



64



65



66



67



68



69



70




71




72




73




74



75



76




77



78

# ӨЧЬЕЛЛЫК МӘКТӘП

## БЕРЕНЧЕ СЫЙНЫФ

I ЧИРЕК

### Кереш контроль эше

Эшне үткәрү максаты — 1 нче сыйныфка кергән балаларның математик күзаллауларының башлангыч дәрәҗәсен ачыклау.

Эш дүрт биремнән тора, алар ярдәмендә балаларның натураль саннар турында күзаллый белүләре (бирелгән предметлар санын — өч алма, дүрт слива һ.б. сурәтли белү); таныш цифрларны яза белүләре; «шулкадәр, күпме» сүзләренең мәгънәләрен аңлаулары; пространстволы һәм геометрик күзаллаулары (формасын һәм барлык детальләрнең урнашу тәртибен саклап, бирелгән рәсемне төгәл күчереп ясый белүләре) тикшерелә.

4 нче биремгә кирәкле барлык рәсемнәр дә укытучы тарафыннан линейка ярдәмендә (кирәк булган урында) тактада башкарыла; плакатлар хәзерләргә мөмкин. Балалар рәсемнәрне линейкасыз башкаралар. Эш өчен һәр укучыга төсле карандашлар кирәк.

**Вариант 1**

1. Кызыл карандаш алыгыз да өч алма рәсеме ясагыз.
2. а) Укытучы өстәлендә ничә уенчык булса, шулкадәр яшел түгәрәк ясагыз.

б) Песи баласының ничә тәпие булса, шулкадәр таякчык ясагыз.

3. Үзегез белгән барлык цифрларны языгыз.
4. | Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 1).

Искәрмә:

2. а) Өстәл өстендә 5 уенчык.

**Вариант 2**

1. Зәңгәр карандаш алыгыз да дүрт слива рәсеме ясагыз.
2. а) Сул кулда ничә бармак булса, шулкадәр яшел түгәрәк ясагыз.

б) Күгәрченнең ничә канаты булса, шулкадәр кызыл таякчык ясагыз.

3. Үзегез белгән һәм яза алган барлык цифрларны языгыз.
4. Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 2).

## Вариант 3

1. Төрле төстәге дүрт һава шары рәсеме ясагыз.
2. а) Уң кулда ничә бармак булса, шулкадәр зәңгәр түгәрәк ясагыз.

б) Светофорда ничә һәм нинди төсләр барлыгын исегезгә төшерегез һәм шулкадәр төсле түгәрәкләр ясагыз.

3. Үзегез белгән һәм яза алган барлык цифрларны языгыз.
4. Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 3).

## Вариант 4

1. Яшел карандаш белән өч чыршы ясагыз.
2. а) Класста ничә тәрәзә булса, шулкадәр зәңгәр түгәрәк ясагыз.

б) Куянның ничә колагы булса, шулкадәр таякчык ясагыз.

3. Үзегез белгән һәм яза алган барлык цифрларны языгыз.
4. Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 4).

## Вариант 5

1. Төрле төстәге биш туп рәсеме ясагыз.
2. а) Өстәлнең ничә аягы булса, шулкадәр кызыл таякчык ясагыз.

б) Җиңел машинаның ничә көпчәге булса, шулкадәр зәңгәр түгәрәк ясагыз.

3. Үзегез белгән һәм яза алган барлык цифрларны языгыз.
4. Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 5).

## Вариант 6

1. Яшел карандаш белән өч кыяр рәсеме ясагыз.
2. а) Урындыкның ничә аягы булса, шулкадәр зәңгәр таякчык ясагыз.

б) Сезгә ничә яшь булса, шулкадәр кызыл түгәрәк ясагыз.

3. Үзегез белгән һәм яза алган барлык цифрларны языгыз.
4. Рәсемнәрне күчереп ясагыз (рәс. 6).

## I чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты булып укучыларның беренче дистә саннарын цифрлар белән яза белүләрен; 1 һәм 2 саннары белән кушу һәм алуның таблицалы очракларын белүләрен; өйрәнгән исәпләү алымнарыннан файдаланып, бирелгән санга 3 санын куша һәм бирелгән саннан 3 санын ала белүләрен; текстлы арифметик мәсьәләнең чишелешен (сумманы һәм аерманы табуга) санлы

тигезлек рәвешендә язабелүләрен; саннарны чагыштыра < һәм> билгеләрен куллана белүләрен тикшерүдән тора.

Укытучы балаларга һәр биремнең эчтәлеген укып чыга; 2 нче биремнең мисалларын дәрескә кадәр тактага язып куярга яки карточкалар хәзерләргә тәкъдим ителә.

Текстлы мәсьәләләр (3 нче бирем), балаларга тәкъдим ителеп, тәртип буенча чишеләләр, башта а) мәсьәләсе, аннары б). Язуны катлауландырмас өчен, мәсьәләләрнең текстларыннан тактага бирелгән саннар (исемсез) гына языла. Бу вакытта күргәзмә әсбаплар (мәсәлән, рәсемнәр, схемалар, эчтәлекле картинкалар) кулланырга кирәкми. Мәсәлән, вариант 1 дә а) мәсьәләсенең текстыннан ике сан гына язып алына: 9, 1. Текстны укытучы әкрен генә ике тапкыр укып чыга. Аннан соң укытучы мәсьәлә чишелешенең язмасына керешергә рөхсәт бирә.

## Вариант 1

1. 1 дән 6 га кадәрге саннарны, 6 санын да кертеп, тәртип буенча языгыз.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 + 1 = | 5 + 2 = | 7 - 3 = | 9 - 2 = |
| 3 + 2 = | 7 + 3 = | 2 - 1 = | 4 - 2 = |

3. Мәсьәләләрне чишегез:

а) Поезд 9 вагоннан тора. Станциядә поездан 1 вагонны ычкындырып алалар. Ничә вагон калган?

б) Мәктәп янында 4 юкә һәм 2 миләш үсә. Мәктәп янында ничә агач үсә?

4. Саннарны чагыштырыгыз: рамка эченә < яки > тамгасын языгыз:

а) 4 □ 7; б) 3 □ 1.

5*. Әниләре балаларына 3 пар бияләй сатып алган. Барлыгы ничә сул бияләй һәм ничә уң бияләй?

6*. Паркта 7 эскәмия булган. 3 эскәмияне яңага алыштырганнар. Паркта ничә эскәмия булды?

Искәрмәләр:

5*. Җавап: 3, 3.

6*. Мәсьәлә бер карашка алу гамәле белән чишелә торган мәсьәләләргә охшаш. Шуңа күрә кайбер балалар мондый «чишелеш» язып куярлар: 7 - 3 = 4. Ләкин бу очракта бернинди дә гамәл башкарырга кирәкми. Дөрес җавап: 7. Укучылар шушы санны язарга тиешләр дә инде.

**Вариант 2**

1. 3 тән 8 гә кадәрге саннарны, 8 не дә кертеп, тәртип буенча языгыз.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 + 1 = | 5-+ 2 = | 7 - 2 = | 4 - 3 = |
| 7 + 2 = | 6 + 3 = | 3 - 2 = | 9 - 1 = |

3. Мәсьәләләрне чишегез:

а) Циркта 5 юлбарыс белән 3 арыслан чыгыш ясаганнар. Циркта ничә хайван чыгыш ясаган?

б) Алиянең 5 йомгак йоны булган. 3 йомгагыннан ул башлык бәйләгән. Ничә йомгак йон калган?

4. Саннарны чагыштырыгыз, рамка эченә < яки > билгесе куегыз:

а)8□5; б)5□6.

5*. 7 дән кечерәк булган барлык саннарны языгыз.

6*. Квартир 2 бүлмәле. Бер бүлмәсеннән ике бүлмә ясаганнар. Квартирда ничә бүлмә булган?

Искәрмәләр:

5*. Җавап: 0, 1, 2, 3, 4, 5, 6.

6*. Җавап: 3.

**Вариант 3**

1. 2 дән 7 гә кадәрге барлык саннарны, 7 не дә кертеп, тәртип буенча языгыз.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 + 2 = | 5 + 2 = | 8 - 1 = | 10 - 3 = |
| 9 + 1 = | 5 + 3 = | 6 - 2 = | 9 - 3 = |

3. Мәсьәләләрне чишегез:

а) Вәсилгә 8 значок бүләк иткәннәр. Аларның 3 сен ул Дамирга биргән. Вәсилнең ничә значогы калган?

б) Гараждан башта 2 машина, аннары 1 машина чыгып киткән. Гараждан ничә машина чыгып киткән?

4. Рамка эченә язма дөрес булырлык сан яз:

а) 5 >□ ; б) 7 < □ .

5*. Юныс китапханәдән «Салават күпере» журналының икедән алтыга кадәрге номерларын сорап алган. Китапханәче аңа ничә журнал биргән?

6*. 5 тән зуррак һәм 10 нан кечерәк булган барлык саннарны языгыз.

Искәрмәләр:

5*. Кайбер балалар журналларның барлык номерларын язырлар: 2, 3, 4, 5, 6. Ләкин бу язма мәсьәләнең җавабы түгел. Җавап 5 саны була.

6*. Җавап: 6, 7, 8, 9.

**Вариант 4**

1. 4 тән 9 га кадәрге барлык саннарны, 9 ны да кертеп, тәртип буенча яз.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 + 2 = | 8 + 2 = | 7 - 3 = | 4 - 2 = |
| 7 + 1 = | 4 + 3 = | 10 - 1 = | 3 - 1 = |

3. Мәсьәләләрне чишегез:

а) Тәлинкәдә сливалар яткан. Фәрит 4 слива, ә Сәлим 3 слива ашаган. Малайлар ничә слива ашаганнар?

б) Уен беткәндә шахмат тактасында 6 ак һәм 3 кара фигура калган. Тактада ничә фигура калган?

4. Рамка эченә язма дөрес булырлык сан яз:

а)□<9; б)□>3.

5*. Квартирда 4 бүлмә. Ике бүлмәне тоташтырып, алардан бер зур бүлмә ясаганнар. Моннан соң квартирда ничә бүлмә булган?

6*. Физкультура дәресендә укытучы 10 укучыга сулдан уңга тәртип буенча саналырга куша. Марат өченче булган. Укытучы уңнан сулга саналырга кушса, Марат тәртип буенча ничәнче булыр?

Искәрмә:

5*. Җавап 3.

**Вариант 5**

1.10нан 1гә кадәрге барлык саннарны, 1не дә кертеп, тәртип буенча языгыз.

2.Һәр мисалга ике җавап бирелгән: аларның берсе — дөрес, ә икенчесе — дөрес түгел. Дөрес җавапны сайлап алыгыз һәм аны язып куегыз.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7 + 2 = | 1) 8, | 2) 9; | 9 + 1 = | 1) 9, | 2)10; |
| 4 + 2 = | 1) 6, | 2) 7; | 9 - 1 = | 1) 10, | 2) 8; |
| 6 + 3 = | 1) 9, | 2) 10; | 5 - 3 = | 1) 8, | 2) 2. |

3. Мәсьәләләрне чишегез:

а) Тартмада кызыл, зәңгәр, сары, яшел, кара, сары, ал һәм куе кызыл карандашлар ята. Рамил тартмадан зәңгәр һәм яшел карандашлар алган. Тартмада ничә карандаш калган?

б) Фәрит урманда 3 усак гөмбәсе һәм шулкадәр үк каен гөмбәсе тапкан. Фәрит ничә гөмбә тапкан?

4. Ике сан уйлагыз, аларның берсе: а) икенчесеннән зуррак; б) икенчесеннән кечерәк булсын. < һәм > билгеләре ярдәмендә язмалар бирегез.

5*. Ләйсән кәрзиндә утырган чебиләрнең тәпиләрен санаган, барлыгы 10 тәпи булып чыккан. Кәрзиндә ничә чеби булган?

6*. Талиянең курчаклары 4 тән күбрәк һәм 7 дән кимрәк. Талиянең ничә курчагы булырга мөмкин?

Искәрмәләр:

5*. Кайбер балалар болай язарга мөмкин: 2 + 2 + 2 + 2 + 2 = 10. Әлеге язма дөрес җавап була алмый. Җавап: 5.

6*. Җавап «5 яки 6» дип язылырга тиеш. Әгәр дә балалар җавап итеп бер генә санны — яки 5, яки 6 ны гына язсалар, андый җавапны тулы дип исәпләмәскә кирәк һәм алдагы дәрестә, укучыларның контроль эш нәтиҗәләренә анализ ясаганда, бу мәсьәләне бөтен класс белән тикшерергә һәм дөрес җавапны язып куярга кирәк.

## Вариант 6

1. 9 дан 1 гә кадәрге барлык саннарны, 1 не дә кертеп, тәртип буенча языгыз.

2. Белмәмешнең эшен тикшерегез. Ялгышларын кызыл карандаш белән сызыгыз. Янына дөрес җавапны язып куегыз.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5+2=8 | 4+2=6 | 6-1=5 | 8-2=7 |
| 6+1=7 | 3+3=5 | 5-2=7 | 9-3=6 |

3. Мәсьәләләрне чишегез:

а) Ак һәм зәңгәр вазаларга 3 әр роза куйганнар. Ике вазага ничә роза куйганнар?

б) Чүл буйлап 9 дөя килә. Шуларның 3 се бер өркәчле дөя, ә калганнары — ике өркәчле. Ике өркәчле дөяләр ничәү?

4. Ике сан уйлагыз, аның берсе: а) икенчесеннән кечерәк; б) икенчесеннән зуррак булсын. < һәм > билгеләре ярдәмендә язып күрсәтегез.

5*. Камил Дамирдан зуррак, ә Дамир Мараттан зуррак. Барысыннан да кечерәк булган малайның исемен языгыз.
6*. Гади карандаш белән 6 һава шары ясагыз. Кызыл һәм яшел карандашлар алып, кызыл шарлар яшелләрдән күбрәк булырлык итеп, шарларны буягыз.

Искәрмәләр:

3. а) Чишелеше: 3 + 3 = 6. Җавап: 6.
5*. Укучыларга, алар язарга тиешле җавап — малайның исеме булуын әйтергә кирәк.
6*. Мәсьәләнең ике чишелеше булырга мөмкин: 5 һәм 1, 4 һәм 2. Шуңа күрә төрле укучыларның төрле рәсемнәр булуы мөмкин. Һәр укучы һич югында бер генә булса да чишелеш табарга һәм шул чишелешкә тиңдәшле рәвештә рәсемен ясый белергә тиеш. Әгәр кемнең дә булса вакыты калса, укытучы аңа икенче чишелеш турында уйларга һәм тагын бер рәсем ясарга куша ала.

## II ЧИРЕК

### II чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты булып укучыларның 10 эчендәге саннарны куша һәм ала белүләрен; «зуррак» һәм «кечерәк» бәйләнешләрен аңлаткан сүзләрнең мәгънәләрен аңлауларын (берсендә икенчесенә караганда берничә предметка күбрәк яки азрак булган күплекне сурәтли белүләрен; «күбрәк» һәм «азрак» төшенчәләрен эченә алган арифметик мәсьәләләрне чишә белүләрен) тикшерүдән тора.

Беренче бирем өчен укытучы индивидуаль карточкалар әзерләп, дәрес башланганчы аларны таратып чыгарга мөмкин.

2 нче бирем өлешләп үтәлә. Укытучы башта беренче өлешне укый, һәм балалар беренче күплекне сурәтлиләр (күплекне төзегән предметларны бер юлда сурәтлиләр). Аннары акрын гына икенче өлешне укый һәм икенче күплекне сурәтләргә куша (бу күплекнең предметлары беренче күплек предметлары астына сурәтләнә).

Арифметик мәсьәләләр тәртип буенча тәкъдим ителәләр. Күргәзмәлелек (рәсемнәр, схемалар һ.б.) кулланылмый. Тактада бары тик саннар яки зурлыклар гына языла. Мәсәлән, 1 нче вариант мәсьәләсенең текстыннан (3,а биреме) укытучы тактада түбәндә бирелгәннәрне яза:

5,2 гә артыграк;

ә 3 нче вариант мәсьәләсенең текстыннан (3,б биреме) түбәндәге зурлыклар:

7 сум, 10 сум.

## Вариант 1

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 + 4 = | 3 + 5= | 10 - 4 = | 1- 0= |
| 2 + 3 = | 8 + 0= | 3 - 2 = | 8- 5= |
| 9 + 1 = | ‘4 + 5= | 9 - 6 = | 7- 6= |

2. 4 чыршы рәсеме ясагыз. Чыршылар астына кызыл карандаш белән шарлар ясагыз, алар чыршылардан 3 кә артыграк булсын.
3. Мәсьәләләрне чишегез:

а) Өстәл өстендә кашыклар һәм чәнечкеләр тора. Кашыклар 5, ә чәнечкеләр кашыклардан 2 гә артыграк. Чәнечкеләр ничә?

б) 9 күлмәк теккәннәр, ә кофталарны күлмәкләргә караганда 3 кә кимрәк теккәннәр. Ничә кофта теккәннәр?

4*. Тәрәзә төбендә 8 яшел помидор ята. 3 көннән соң алар кызарганнар. Ничә яшел помидор калган?

5*. Йорт куяннары читлектә утыралар, читлектән аларның колаклары гына күренеп тора. Васил 5 пар колак санаган. Читлектә ничә куян булган?

И с к ә р мәләр:

4*. 3 саны әлеге мәсьәләдә артык бирелгән булып тора. Бу сан кайбер укучыларны ялгыштыра, һәм алар «чишелеш»не 8 - 3 дип язып куюлары мөмкин. Мәсьәләне чишү өчен, алу гамәле башкарыла: 8 - 8 = 0. Җавап: 0.

5*. Җавап: 5. Мәсьәләне чишү өчен, бернинди дә арифметик гамәл башкарырга кирәкми.

## Вариант 2

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 + 6 = | 6 + 1 = | 6 - 2 = | 6 - 0= |
| 7 + 2 = | 4 + 4 = | 9 - 7 = | 6 - 3= |
| 2 + 8 = | 1 + 0 = | 10 - 9 = | 9 - 4= |

2. Зәңгәр карандаш белән 5 слива рәсеме ясагыз. Сливалардан 2 гә артыграк булырлык итеп, алар астына чикләвек рәсемнәре ясагыз.
3. Мәсьәләләр чишегез:

а) Алмазга 7 яшь, ә аның сеңлесе 2 яшькә кечерәк. Алмазның сеңлесенә ничә яшь?

б) Күлгә үрдәкләр һәм үрдәк бәбкәләре килә; үрдәкләр 5, ә үрдәк бәбкәләре үрдәкләрдән 4 кә артыграк. Үрдәк бәбкәләре ничә?

4*. Тимерче ике ат дагалаган. Аңа ничә дага кирәк булган?

5*. Азатны конфет белән сыйлаганнар. Ул үзенең сеңлесенә 4 конфет бирергә, ә үзенә калган 3 сен алырга уйлаган. Азатка ничә конфет биргәннәр?

Искәрмәләр:

4*. Чишелеш: 4 + 4 = 8. Җавап: 8. Кайбер балалар мәсьәләне чишкәндә, мәсьәлә текстында бер генә зурлык бирелгән дип кыенсынып калулары бар. Әгәр укучы чишелешне югарыда күрсәтелгәнчә язса, яки җавабын гына язып куйса, мәсьәлә чишелгән дип санарга кирәк (тигезлек язмасыннан башка).

5*. Мәсьәлә катлаулы түгел, ләкин укучылар өчен бик ачык итеп әйтелмәгән. Шуңа күрә төрле төрдәге ялгышлар булуы мөмкин, мәсәлән, 4 - 3 = 1. Чишелеш: 4 + 3 = 7. Җавап: 7.

## Вариант 3

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 5 = | 5 + 3 = | 8 - 4 = | 7 - 0= |
| 3 + 0 = | 2 + 7 = | 5 - 5 = | 10 - 2= |
| 4 + 6 = | 4 + 5 = | 9 - 8 = | 10 - 6= |

2. Сары карандаш белән 8 лимон рәсеме ясагыз. Лимоннарга караганда 3 кә кимрәк булырлык итеп, лимоннар астына кызыл карандаш белән чия рәсемнәре ясагыз.

3. Мәсьәләләрне чишегез:

а) Бидонга, банкага караганда, 2 л га күбрәк куас салганнар. Банкага 3 л куас салганнар. Бидонга ничә литр куас салганнар?

б) Балаларга 7 порция шоколад һәм 10 порция җиләк туңдырмасы сатып алганнар. Шоколад туңдырмасын җиләкнекеннән ничә порциягә кимрәк сатып алганнар?

4*. Мәдинә белән Фәриттә 9 ар конфет бар. Мәдинә 4 конфетын ашаган, Фәрит тә шул кадәрлесен ашаган. Фәритнең ничә конфеты калган?

5*. «Китап» сүзендә 5 хәреф. Бер хәрефкә артыграк булган бер сүз уйлап табыгыз һәм аны язып куегыз.

Искәрмәләр:

4*. Чишелеш: 9 - 4 = 5. Җавап: 5. Мәсьәлә гадәти бирелмәгән, әмма мәсьәләнең шартына карата укучыларга бернинди дә аңлатма бирергә кирәкми.

5*. Әгәр балалар бу биремне үти алсалар һәм дәрестә вакЫтлары да калса, аларга бирелгән «китап» сүзеннән 1-2 хәрефкә кимрәк булган берничә сүз уйларга һәм язып куярга тәкъдим ителәә.

**Вариант 4**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 + 8 = | 3 + 7 = | 9 - 3 = | 8 - 5= |
| 4 + 0 = | 9 + 1 = | 10 - 8 = | 3 - 3= |
| 5 + 4 = | 4 + 4 = | 9 - 0 = | 7 - 6= |

2. 7 алма рәсеме ясагыз. Алмалар астына, алардан 4 кә кимрәк булырлык итеп, зәңгәр карандаш белән сливалар яса.
3. Мәсьәләләрне чишегез:

а) Илдар Фәнистән 3 яшькә кечерәк. Фәнискә 10 яшь. Илдарның яшен языгыз.

б) Варенье кайнату өчен, 8 кг кура җиләге һәм 5 кг чия әзерләгәннәр. Кура җиләген чиягә караганда ничә килограммга артыграк әзерләгәннәр?

4*. Наилә бер сан уйлаган. Ул санны башта 7 гә кушкан, аннары аны 7 дән алган. Җавап бер үк килеп чыккан — 7. Наилә нинди сан уйлаган?

5*. Рамилгә аның үзендә күпме значок булса, шул кадәр значок бүләк иткәннәр. Бөтен значокларын санаганнан соң, Рамилнең 8 значогы булган. Рамилнең башта ничә значогы булган?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: 0.

5*. Мөгаен, балалар Рамилнең 4 значогы барлыгына төшенерләр; алар аның дөреслеген дә тикшерә алалар: 4 + 4 = 8. Җавап: 4.

**Вариант 5**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 + 9 = | 2 + 7 = | 10 - 7 = | 9 - 5= |
| 3 + 7 = | 5 + 4 = | 4 - 4 = | 6 - 0= |
| 8 + 0 = | 3 + 6 = | 8 - 7 = | 7 - 3= |

2. 5 флаг рәсеме ясагыз. Алардан 1 гә кимрәк итеп, флаглар астына шар рәсемнәре ясагыз. Шарлар астына гөмбә рәсемнәре ясагыз; гөмбәләр шарлардан 4 кә артыграк булырга тиеш.
3. Мәсьәләләрне чишегез:

а) Зур боз кисәгендә пингвиннар ярдагыга караганда 3 кә артыграк. Әгәр ярда 7 пингвин булса, боз кисәгендә алар ничә?

4*. 7 баланы бүлмәдә урнаштыру өчен, 2 урындык җитми. Бүлмәдә ничә урындык?

5*. Үрмәкүчнең 4 пар аягы, ә коңгызның 3 пар аягы бар. Үрмәкүчнең коңгызныкыннан аяклары ничәгә артыграк?

Искәрмәләр:

4*. Әгәр укучы мәсьәләнең җавабын 5 урындык дип язып куйса, ул мәсьәләне дөрес чишкән дип исәплләрбез. Кайбер укучыларның бу мәсьәләнең чишелешен 7 - 2 = 5 тигезлеге рәвешендә язулары да мөмкин.

5*. Укучыларның болай фикер йөртүләре мөмкин: 4 пар аяк — ул 8 аяк, ә 3 пар — ул 6 аяк, 8 - 6 = 2. Бу чишелеш дөрес. Мәсьәлә чишүнең тагын да кыскарак башка юлы бар: коңгызның аяклары үрмәкүчнекеннән бер пар аякка кимрәк (4 - 3 = 1); бер пар — ул ике аяк. Җавап: 2 аякка.

## Вариант 6

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 0 = | 4 + 5 = | 7 - 5 = | 10 - 5= |
| 2 + 7 = | 3 + 7 = | 9 - 8 = | 6 - 6= |
| 6 + 4 = | 1 + 6 = | 3 - 0 = | 8 - 5= |

2. 3 төймә рәсеме ясагыз. Алардан 4 кә күбрәк булырлык итеп, төймәләр астына энәләр ясагыз. Энәләр астына кошу тамгаларын куеп чыгыгыз: алар энәләрдән 3 кә кимрәк булсын.

3. Мәсьәләләрне чишегез:

а) Кәрзиндә кызыл һәм сары алмалар бар: кызыллары сарылардан 6 га артыграк. Әгәр сары алма 4 булса, кәрзиндә ничә кызыл алма булган?

б) Шахмат буенча ярышларда Сәлим 4 очко, ә Дамир 7 очко җыйган. Сәлим Дамирдан ничә очкога калышкан?

4*. Тартма 6 өлешкә бүленгән. Һәр өлешкә берәр генә яңа ел уенчыгы сыя. Бу тартмага 4 шар белән 3 чыршы күркәсе салып булырмы?

5*. Апасы энесеннән 1 яшькә зуррак. 5 елдан соң апасы энесеннән ничә яшькә зуррак булыр?

Искәрмәләр:

4*. Мәсьәләнең шартын укытучы тактага мондый рәвештә яза: 6, 4, 3. Чишелеш: 4 + 3 = 7; 6 < 7. Җавап: Юк (ярамый). Кайбер укучылар, җавапны яза белмичә, чишелешне болай дип язалар: 4 + 3 = 7. Икенчеләре җавапта 7 санын язырлар. Ләкин 7 саны җавап түгел. Чишелешнең мөһим этабы булып 7 һәм 6 саннарын чагыштыру тора. 6 һәм 7 саннарын чагыштырып, тартмага 4 шар белән 3 чыршы күркәсе салырга ярамый дип нәтиҗә ясыйбыз.

5*. Апасы, ничә ел үтсә дә, энесеннән 1 яшькә зуррак булып калыр. Әмма кайбер укучыларның 5 - 1 = 4, 5 + 1 = 6 һ.б. төрдәге ялгыш чишелешләр язулары мөмкин, гадәттә мәсьә - ләдәге «1 яшькә зуррак», «ничә яшькә зуррак» сүзләре аларга тиешле арифметик гамәлне сайлап алырга ярдәм итә иде. Җавап: 1 яшькә.

III ЧИРЕК

## «10 эчендә кушу таблицасы» темасы буенча контроль эш

Контроль эш өченче чирек башында үткәрелә. Бу вакытка 10 эчендә берурынлы саннарны кушу таблицасын барлык балалар да яхшы үзләштерергә тиеш.

Бәр вариантта 16 мисал бирелгән; индивидуаль карточкаларны алданрак хәзерләргә кирәк, аларда балалар җавапларын гына язачак.

### Вариант 1

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 + 1 = | 2 + 6 = | 2 + 7 = | 8 + 0= |
| 4 + 3 = | 7 + 1 = . | 1 + 9 = | 2 + 2= |
| 6 + 3 = | 2 + 3 = | 4 + 5 = | 5 + 3= |
| 8 + 2 = | 5 + 4 = | 2 + 4 = | 4 + 4= |

*2**. Нинди сан кара табы белән капланган (рәс. 7)?

3*. Ике санның суммасы кушылучыга тигез булырга мөмкинме? Дөрес җавапны сайлап алып языгыз: 1) Әйе. 2) Юк. 3) Белмим.

И с кә р мәләр:

2*. Укучылардан 9 - 6 = 3 чишелешенең язылышын таләп итү мәҗбүри түгел. Алар җавапны гына — 3 санын язсалар да җитә.

3*. Җавап: Әйе. Әгәр кушылучыларның берсе нульгә тигез булса, ике санның суммасы кушылучыга тигез була. Биремне тизрәк үтәгән укучыларга нинди дә булса мисал уйларга һәм аны язып куярга тәкъдим итәргә мөмкин (мәсәлән, 5 + 0 = 5).

### Вариант 2

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 + 0 = | 5 + 5 = | 9 + 1 = | 2 + 4= |
| 3 + 1 = | 6 + 1 = | 4 + 4 = | 5 + 4= |
| 7 + 2 = | 2 + 8 = | 2 + 3 = | 1 + 1= |
| 3 + 3 = | 2 + 2 = | 1 + 5 = | 2 + 6= |

2*. Нинди сан кара табы белән капланган (рәс. 8)?

3*. Ике санның аермасы кимүчегә тигез булырга мөмкинме? Бирелгән җаваплар арасыннан берсен сайлап алыгыз һәм аны язып куегыз: 1) Әйе. 2) Юк. 3) Белмим.

Искәрмәләр:

2*. Җавап: 9.

3*. Җавап: Әйе. Киметүче нульгә тигез булганда, ике санның аермасы нульгә тигез. Мәсәлән: 7 - 0 = 7.

## Вариант 3

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 + 1= | 2 + 4= | 9 + 1 = | 4 + 4= |
| 8 + 2= | 8 + 1= | 3 + 4 = | 6 + 3= |
| 9 + 0= | 6 + 4.= | 2 + 6 = | 5 + 5= |
| 3 + 5= | 7 + 3= | 7 + 2 = | 6 + 2= |

2*. Берәмлекләр саны дистәләр санынннан 3 кә зуррак булган 20 дән кечерәк сан языгыз.

3*.9нчы рәсемдә сез ничә квадрат күрәсез? Бирелгән җаваплар арасыннан дөрес җавапны сайлап алыгыз һәм аны язып куегыз:

1) 3. 2) 4. 3) 5. 4) 7.

Искәрмәләр:

2*. Җавап: 14.

3*. Җавап: 7.

## Вариант 4

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 + 5 = | 8 + 2 = | 3 + 3 = | 5 + 5= |
| 6 + 0 = | 2 + 5 = | 2 + 7 = | 8 + 1= |
| 7 + 3 = | 9 + 1 = | 5 + 3 = | 1 + 7= |
| 5 + 1 = | 4 + 3 = | 1 + 0 = | 2 + 6= |

2*. Дистәләр саны берәмлекләр санынннан 4 кә кимрәк булган 20 дән кечерәк сан языгыз.

3*. 10, 7, 4 саннары нинди кагыйдә буенча язылганнар? Киләсе санны языгыз.

И с кәрмәләр:

2*. Җавап: 15.

3*. Бәр киләсе сан үзеннән алдагы саннан 3 кә кимрәк. Җавап: 1.

**Вариант 5**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 3 = | 1 + 9 = | 2 + 2 = | 5 + 5 = |
| 2 + 0 = | 6 + 3 = | 4 + 3 = | 3 + 6 = |
| 7+2= | 2+8= | 8+1= | 3+7= |
| 4 + 4= | 3 + 3= | 4 + 6= | 5 + 4 = |

2*. Альбомның һәр битенә мин 4 әр рәсем ябыштырдым. 8 рәсем өчен ничә бит кирәк булган?

3*. Ике санның суммасы 8 гә, ә аларның аермасы 4 кә тигез. Нинди саннар икәнен уйлап табыгыз.

И с к ә р мәлә р:

2*. Мәсьәлә фикер йөртеп чишелә. 8 — ул 4 һәм 4. Укучылар рәсемнәрнең 2 битне алып торуына төшенергә тиешләр.

3*. Җавап: 6 һәм 2. Мәсьәлә куеп карау юлы белән чишелә. 8 — ул 7 һәм 1 (аерма 6; 7 һәм 1 туры килми); 8 — ул 6 һәм 2 (аерма 4).

**Вариант 6**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1+0= | 2 + 7= | 6 + 3= | 5 + 4= |
| 6 + 4= | 9 + 1= | 7 + 1= | 7 + 2= |
| 3 + 6= | 4 + 4= | 2 + 3= | 3 + 3= |
| 5 + 5 = | 3 + 7 = | 4 + 5 = | 1 + 7= |

2*. Мине — Нәкыя Исламовна, ә минем бабайны (минем әтинең әтисен) Ирек Халимович дип йөртәләр. Минем әтием кем исемле? Аның исемен һәм әтисенең исемен языгыз.

3*. Үлчәүнең сул тәлинкәсендә 1 пакет он белән 1 кг лы гер тора. Үлчәүнең уң як тәлинкәсендә 3 кг лы гер. Үлчәү тигезләнеш торышында. Он салынган пакетның массасын табыгыз.

Искәрмәләр:

2*. Җавап: Ислам Ирекович.

3*. Чишелеш: 3 - 1 = 2. Җавап: 2 кг.

## «Төзелмә арифметик мәсьәләләрне чишү» темасы буенча контроль эш

Контроль эш укучыларның төзелмә арифметик мәсьәләләрне чишү осталыгын тикшерү максаты белән үткәрелә. Бу эшне «Кушу һәм алу» (40 + 20, 50 — 30 рәвешендәге) темасын өйрәнер алдыннан үткәрү максатка ярашлы булыр.

Мәҗбүри рәвештә ике мәсьәлә тәкъдим ителә: берсе зурлыклар арасында катлаулы бәйләнешләрне эченә алмый һәм ике гади мосьәләнең комбинациясен тәшкил итә; икенче мәсьәләдә төзелмә мәсьәләнең катлаулылык дәрәҗәсен арттыра торган «кечерәк» һәм «зуррак» чагыштырмалары бар.

Мәсьәләләрнең текстлары тактага яисә индивидуаль карточкаларга языла. Укучылардан бу мәсьәлә шартларының кыскача изылышларын, мәсәлән схема рәвешендә, үтәүне таләп итмәскә кирәк. Һәр мәсьәләнең чишелешен укучы гамәлләр белән яза (сорауларны язмыйча гына).

### Вариант 1

*1. Хуҗабикә 8 кг җиләк-җимеш сатып ала: 3 кг алма, 4 кг груша һәм слива. Ул ничә килограмм слива сатып алган?

2. Күлмәккә 6 төймә, ә костюмга 2 төймәгә артыграк теккәннәр. Күлмәк һәм костюм өчен ничә төймә кирәк булган?

3*. Универмагның аяк киемнәре бүлегендә «37 — 42 үлчәмле аяк киемнәре» дигән күрсәткеч эленеп тора. Бу бүлектә 39 нчы үлчәмле аяк киеме сатып алырга мөмкинме?

4*. 5 һәм 6 цифрларыннан файдаланып, нинди икеурынлы саннар язарга мөмкин? Андый барлык саннарны языгыз.

Искәрмәләр:

3*. Җавап: Әйе.

4*. Әлеге очракта саннарны язган вакытта цифрлар кабатланырга мөмкин: Җавап: 55, 56, 65, 66.

### Вариант 2

1. Мастер ремонтлау өчен заказга 6 үтүк һәм 8 электр плитәсе алган. Ике сәгать эчендә ул 5 үтүкне ремонтлаган. Аның ничә приборны ремонтлыйсы калган?

2. 9 кг мүк җиләге һәм аннан 3 кг га кимрәк нарат җиләге сатып алганнар. Ничә килограмм җиләк сатып алганнар?

3*. Шикәрне пакетларга 1 әр кг, 2 шәр кг һәм 3 әр кг итеп салып саталар. Әни 7 кг шикәр өчен кассага акча түләгән. Сатучы аңа 3 пакет шикәр биргән. Һәр пакетта күпмешәр шикәр булган? Мөмкин булган очракларны карагыз.

4*. Сез *2 һәм 95 саннарын чагыштыра аласызмы? < яки > билгеләренең берсе ярдәмендә язып күрсәтегез.

Искәрмәләр:

3*. Ву очрактаике мөмкинлек бар: 1) 3 кг, 3 кг һәм 1 кг; *2)* 2 кг, 2 кг һәм 3 кг.

4*. Беренче сандагы дистәләр санын белмәгәндә дә, бирелгән саннарны чагыштырып була, йолдызчык урынына нинди генә сан куйсак та, ул сан 95 тән кечкенә була. Җавап: *2 < 95.

## Вариант 3

1. Мичкәдә 15 л су булган. Башта мичкәдән 6 л су, ә аннары тагы 3 л су алганнар. Мичкәдә ничә литр су калган?
2. Салат хәзерләгәннәр: помидорга караганда кыярны 3 кә артыграк алганнар. Әгәр 6 помидор алган булсалар, ничә яшелчәдән салат ясаганнар?

3*. Ләлә белән Мәдинә урманда бер үк кадәр гөмбә тапканнар. Ләләнең 4 гөмбәсе кортлы булып чыккан, һәм өйгә кайтканда ул аларны ташлап калдырган. Ә Мәдинә тагын 5 гөмбә тапкан. Моннан соң Мәдинәнең гөмбәләре Ләләнекенә караганда ничәгә артыграк булган?

4*. Өстәл тартмасында акча бар. Ул акчага бертөрле 2 урындык яки бер кресло алырга була. Кайсы кыйммәтрәк: креслоны яки урындыкмы?

Искәрмәләр:

3*. Фикерләү ысулын күрсәтәбез. Ләлә 4 гөмбәсен ташлаганнан соң, Мәдинәнең гөмбәләре Ләләнекеннән 4 кә артыграк була. Мәдинә тагын 5 гөмбә таба. Димәк, аның гөмбәләре Ләләнекеннән 9 га артыграк булган. Чишелеш: $4 + 5 = 9$. Җавап: 9 га.

4*. Җавап: Кресло.

## Вариант 4

1. Бидонга 12 стакан сөт салганнар. Бидоннан башта 3 стакан сөтне алганнар, ә аннары аңа тагын 4 стакан сөт салганнар. Моннан соң бидонда ничә стакан сөт булган?
2. 8 кг массалы электр приборын аннан 6 кг га җиңелрәк булган ящик эченә куйганнар. Ящикның электр приборы белән массасын табыгыз.

3*. Өске киштәдә китаплар аскы киштәдәге кадәр. Өске киштәгә 3 китап куйганнар, ә аскысыннан 3 китапны алганнар. Моннан соң кайсы киштәдә китаплар күбрәк булган һәм ничәгә?

4*. Тартмада 12 кызыл һәм яшел шарлар бар. Тартмадан 3 кызыл һәм 4 яшел шарны алганнар. Моннан соң тартмада яшел шарлар калмаган. Тартмада ничә кызыл шар калган?

Искәрмәләр:

3*. Әгәр укучы: «Өске киштәдә 6 китапка артыграк» дип язса, андый мәсьәләне дөрес чишелгән дип исәпләргә. Нинди дә булса фикер йөртү (кыскача яки җентекләп бирү) таләп ителми. Укытучы өчен фикер йөртүнең мөмкин булган бер ысулын китерәбез.
Өске киштәгә 3 китап куйганнан соң, анда аскысындагыга караганда 3 китапка артыграк була. Аскы киштәдән 3 китап алгач, өске киштәдә аскысы белән чагыштырганда тагын 3 китапка артыграк була; өске киштәдә, астагы киштәгә караганда, 6 китапка артыграк булып чыккан.
Чишелеш: 3 + 3 = 6. Җавап. Өскесендә 6 китапка күбрәк.
4*. Мәсьәләне ике ысул белән чишәргә мөмкин: 1 нче юл: 12 - 4 = 8, 8 - 3 = 5. 2 нче юл: 3 + 4 = 7, 12 - 7 = 5. Җавап: 5.

**Вариант 5**

1. Ике тартмада 10 шар йомырка булган. Бер тартмадан икенчесенә 4 йомырканы алып куйганнар. Моннан соң һәр тартмада ничә йомырка булган?
2. Күркә үрдәктән 2 кг га авыррак, ә үрдәк әтәчтән 2 кг га авыррак. Әтәчнең массасы 2 кг. Күркәнең массасын табыгыз.

3*. Кәрзиндә алмалар пакеттагыга караганда 5 кә артыграк. Кәрзиннән 7 алма алганнар. Алма кайда күбрәк калган, кәрзиндәме яки пакеттамы, һәм ничәгә?

4*. Өч йозакка тылсымчы өч ачкыч ясаган: бакыр, көмеш һәм алтыннан. Һәр йозакка берәр генә ачкыч туры килә. Бакыр ачкыч беренче йозакка да, икенчесенә дә туры килми. Көмеш ачкыч икенче йозакка туры килми. Ачкычларның һәркайсы кайсы йозакка туры килә?

Искәрмәләр:

3*. Кәрзиннән 5 алма алгач, анда пакеттагыкадәр алма була. Ләкин кәрзиннән 5 не түгел, ә 7 алма алганнар, ягъни тагын 2 алма. Димәк, пакетта кәрзиндәге белән чагыштырганда 2 алмага артыграк була. Җавап: Пакетта алмалар кәрзиндәгегә караганда 2 гә артыграк.
4*. Мәсьәлә логик характерда. Аның шартын, кыскача итеп, тактада таблица рәвешендә язарга була («-» тамгасы «туры килми» дигәнне аңлата).

| Ачкыч | Йозак | | |
|---|---|---|---|
| | I | II | III |
| Бакыр | — | — | |
| Көмеш | | — | |
| Алтын | | | |

Таблицадан күренгәнчә, бакыр ачкыч беренче һәм икенче йозакларга ярамагач, өченче йозакка ярый. Көмеш ачкыч икенче йозакка ярамый, ә өченчесе инде буш түгел. Димәк, көмеш ачкыч беренче йозакка ярый. Алтын ачкыч кала. Ул — икенче йозактан. Җавап: Бакыр ачкыч — III йозактан, көмеш — I дән, алтын — II йозактан. Киләсе дәресләрнең берсендә бу мәсьәләне барлык укучылар белән бергәләп тикшерү һәм чишү файдалы булыр.

## Вариант 6

1· Чиләктән сөтне банкага, бидонга һәм кастрюльгә бушаттылар: банкага — 2 л, бидонга — 3 л, ә кастрюльгә банка белән бидонның икесенә бергә салган кадәр. Чиләктә сөт калмаган. Чиләктә ничә литр сөт булган?

2. Чынаяк стаканнан 3 см га тәбәнәгрәк, ә стакан кофейниктан 8 см га тәбәнәгрәк. Кофейник 16 см биеклектә. Чынаякның биеклеген табыгыз.

3*. Фәритнең конфетлары Сәлимнекенә караганда 4 кә кимрәк. Әнисе Фәриткә тагын 5 конфет биргән. Кемнең конфетлары күбрәк булды һәм ничәгә?

4* . Ящел тасма кызылыннан 3 м га озынрак. Яшел тасмадан 5 м, ә кызылыннан 2 м кисеп алганнар. Кисәкләрдә калган озынлыкларын чагыштырыгыз.

Искәрмәләр:

3*. Болай фикер йөртергә мөмкин. Әнисе Фәриткә 4 конфет биргәннән соң, аның конфетлары Сәлимнеке кадәр була. Ләкин әнисе Фәриткә 4 конфет түгел, ә 5 не биргән. Димәк, Фәритнең конфетлары Сәлимнекеннән 1 гә артыграк булды. Балалар җавапны болай яза алалар: «Фәритнең конфетлары 1 гә артыграк» яки «Фәритнеке, 1 гә артыграк».

4*. Әгәр яшел тасмадан 3 м ын кисеп алсаң, яшел тасма кызыл тасма кадәр кала. Хәзер озынлыклары тигез булган тасмалардан 2 шәр м кисеп алсаң, бертигез тасмалар кала. Җавапны болай язарга була: «Озынлыклар бертигез». Билгеле, балалар бу фикерләрне язмыйлар.

## III чиреккә контроль эш

Эшнең максаты түбәндәгеләрне тикшерүдән тора: укучыларның 10 нан 100 гә кадәрге саннарны яза белүләрен; 10 аша күчеп, берурынлы саннарны кушу һәм алуның нәтиҗәләрен белүләрен; ике арифметик гамәлне эченә алган төзелмә санлы аңлатмаларның (җәяләр белән һәм җәяләрсез) кыйммәтләрен исәпли белүләрен; бер гамәлне эшләп, «зуррак» һәм «кечерәк» төшенчәләрен эченә алган гади арифметик мәсьәләләрне чишә белүләрен.

Һәр вариантның беренче биременең эчтәлеге белән укытучы укучыларны телдән, тактага язмыйча гына таныштыра.

2 нче биремне алдан хәзерләнгән индивидуаль карточкаларда эшләтергә мөмкин. Калган биремнәр дәрескә кадәр тактада язылып куела. 4 нче мәсьәләнең тексты тулысынча языла.

### Вариант 1

1. Саннарны языгыз: егерме сигез, кырык ике, илле, унбиш, кырык дүрт, туксан.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 + 8 = | 2 + 9 = | 11 - 7 = | 13 - 8 = |
| 6 + 6 = | 7 + 4 = | 12 - 3 = | 17 - 9 = |

3. Исәпләгез:

а) 17 - 7 - 7; б) 10 + (9 + 1).

4. Зәңгәр вазага 8 алма, ә агына 3 алмага күбрәк алма куйганнар. Ак вазага ничә алма куйганнар?

5*. Юнысның акчасы төп-төгәл 4 вафли һәм 2 конфет алырлык. Ул шул акчасына 1 конфет һәм 4 вафли ала аламы? Сайлап алып, җавапның берсен языгыз: 1) Әйе. 2) Юк. 3) Белмим.

6*. Мондый кагыйдә буенча 6 сан языгыз: Беренчесе — 1, икенчесе — 2, ә һәр киләсе сан моннан алдагы ике санның суммасына тигез.

Искәрмәләр:

5*. Җавап: Юк.

6*. Беренче ике санны (1 һәм 2) балалар укытучы әйтеп торганда язалар, ә аннары мөстәкыйль рәвештә күрсәтелгән кагыйдә буенча 4 санны язалар. Нәтиҗәдә түбәндәге язылыш килеп чыгарга тиеш: 1, 2, 3, 5, 8, 13.

### Вариант 2

1. Саннарны языгыз: җитмеш сигез, уналты, кырык, сиксән ике, йөз, алтмыш алты.
2. Гамәлләрне эшләгез;

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 + 7= | 9 + 5= | 12-5= | 14-6 = |
| 7 + 7= | 3 + 8= | 16-8= | 11-9 = |

3. Исәпләгез:

а) 9 + 9 - 8; б) (17 -7) + 6.

4. Иртәнге ашка бөккән пешергәннәр: ит белән 6 бөккән, ә кәбестә белән 2 гә кимрәк. Кәбестә белән ничә бөккән пешергәннәр?

5*. Рокыяның акчасы 4 карандаш белән 3 дәфтәр сатып алырлык. Аның акчасы 3 карандаш яки 3 дәфтәр алырга җитәрме? Сайлап алып, җавапны языгыз: 1) Әйе. 2) Юк. 3) Белмим.

6*. Түбәндәге кагыйдә буенча 5 сан языгыз: беренчесе 18, икенчесе 10, ә һәр киләсе сан моннан алдагы ике санның аермасына тигез.

Искәрмәләр:

5*. Җавап. Әйе.

6*. 18 һәм 10 саннарын укучылар укытучы әйтүе буенча язалар; калган өч санны мөстәкыйль рәвештә күрсәтелгән кагыйдә буенча язалар. Җавап: 18, 10, 8, 2, 6.

## Вариант 3

1. 44 не кертеп, 39 дан 44 кә кадәрге барлык икеурынлы саннарны тәртип буенча языгыз.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7+6= | 8 + 3= | 17-8= | 11-4 = |
| 9 + 9 = | 5 + 7 = | 13 - 5 = | 18 - 9 = |

3. Исәпләгез:

а) 8 + 7 - 10; б) 10 + (8 - 4).

4. Чынаякның биеклеге 7 см, стакан чынаяктан 2 см га биегрәк. Стаканның биеклеген табыгыз.

5*. Тәлинкәдә яткан алмаларның яртысын компот ясау өчен алганнар. Әгәр компотны 6 алмадан ясасалар, тәлинкәдә ничә алма калган?

6*. 10 нчы рәсемдә ничә түгәрәк сурәтләнгән? Җавапларның берсен сайлап алыгыз: 1) 4; 2) 5; 3) 6.

И с кәрмәләр:

5*. Җавап: 6.

6*. Җавап: 6.

## Вариант 4

1. 100 не кертеп, 95 тән 100 гә кадәрге барлык икеурынлы саннарны тәртип буенча языгыз.

2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 + 6= | 6 + 5= | 12-4= | 13-9 = |
| 8 + 8 = | 4 + 9 = | 14 - 7 = | 11 - 6 = |

3. Исәпләгез:

а)16-6+ 3; б)17-(4 + 6).

4. Карандашның озынлыгы 14 см, ручка карандаштан 5 см га кыскарак. Ручканың озынлыгы күпмегә тигез?

5*. 11 нче рәсемдә ничә өчпочмак бар? Бирелгән җаваплар арасыннан берсен — дөрес җавапны сайлап алыгыз һәм аны язып куегыз: 1) 4; 2) 7; 3) 9; 4) 5.

6*. Бер пакет кефир сатып алганнар. Пакетта булган кефирның яртысын Мәдинә белән Дания эчкән. Пакетта 2 стакан кефир калган. Пакетта ничә стакан кефир булган?

И с кәрмәлә р:

5*. Җавап: 9.

6*. Җавап: 4.

**Вариант 5**

1 3 дис. 8 бер; 7 дис.; 6 дис. 5 бер.; 5 дис. 6 бер.; 1 дис. 8 бер.; 10 дистәдән торган саннарны языгыз.

2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 + 4 = | 9 + 7 = | 15 - 7 = | 12 - 8 = |
| 6 +6 = | 6 + 8 = | 11 - 3 = | 13 - 6 = |

3. Исәпләгез:

а) 7 + 5 - 2; б) 19 - (2 + 8).

4. Ял йортына киткәндә без чемодан һәм рюкзак алдык. Рюкзак чемоданнан 4 кг га җиңелрәк. Әгәр чемодан белән әйберләрнең массасы 11 кг булса, рюкзакның массасын табыгыз.

5*. Кавын карбыздан авыррак һәм кабактан җиңелрәк. Иң авыры кайсы? Дөрес җавапны сайлап алыгыз: 1) Кавын. 2) Карбыз. 3) Кабак. 4) Белмим.

6*. Өстәлдә яшелчәләр ята: шалканнар кыярга караганда 1 гә кимрәк, ә кыярлар помидорларга караганда 1 гә кимрәк. Шалканнар помидорларга караганда ничәгә кимрәк?

Искәрмәләр:

5*. Җавап: Кабак.

6*. Кайбер балаларга шалкан да помидорларга караганда 1 гә кимрәк кебек тоела. Ләкин бу алай түгел. «1 гә кимрәк» бәйләнеше транзитивлык үзлегенә ия түгел. Конкрет саннар алып, моны тикшерергә була. Җавап: 2 гә.

**Вариант 6**

1. 20 не дә кертеп, 16 дан 20 гә кадәрге барлык икеурынлы . саннарны тәртип буенча языгыз.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 + 3 = | 9 + 5 = | 13 - 6 = | 13 - 7 = |
| 7 + 7 = | 6 + 6 = | 11 - 2 = | 15 - 8 = |

3. Исәпләгез:

а) 5 + 4 + 10; б) 14 - (9 - 5).

4. Вәсил Салихтан 2 кг га авыррак. Салих үлчәүгә баскач, аның массасы 18кг булган. Вәсилнең массасын табыгыз.

5*. Кызыл тасма зәңгәр тасмадан кыскарак, ә яшеленнән озынрак. Кайсы тасма иң кыскасы?

6*. Дамир Наилдән 1 яшькә зуррак, ә Наил Рәшиттән 1 яшькә зуррак. Дамир Рәшиттән ничә яшькә зуррак?

И с кәрмәләр:

5*. Җавап: Яшел тасма.

6*. Җавап: 2 яшькә.

IV ЧИРЕК

## «Кушу таблицасы» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның берурынлы саннарны кушу таблицасын үзләштерүләренең ныклыгын тикшерү.'

Һәр укучы өчен индивидуаль карточка әзерләргә кирәк, анда ул нәтиҗәләрне генә яза.

**Вариант 1**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 + 3= | 1 + 7= | 2 + 2= | 6 + 6 = |
| 4 + 4 = | 9 + 2 = | 9 + 5 = | 4 + 3= |
| 9 + 1 = | 8 + 5 = | 5 + 1 = | 5 + 4= |
| 8 + 8 = | 7 + 4 = | 3 + 8 = | 8 + 6= |
| 6 + 5 = | 4 + 0 = | 6 + 4 = | 7 + 2= |
| 3 + 5 = | 9 + 3 = | 3 + 6 = | 5 + 5= |
| 7 + 7= | 8 + 7= | 8 + 2= | 3 + 3= |
| 9 + 8 = | 9 + 6 = | 5 + 6 = | 4 + 5= |

2*. Һәр минут саен ваннага краннан 10 л су агып тора Шул ук вакыт эчендә ванна төбендәге тишекнең бөкесе тыгыз ябылмау аркасында 2 л су агып чыга. Ваннадагы

су микъдары артамы яки кимиме һәм һәр минут саен ничә литрга?

3*. Бала 3 шакмак ала һәм, манара килеп чыгарлык итеп, аларны берсе өстенә берсен куя. Кызыл шакмак зәңгәрдән астарак, ә зәңгәр шакмак яшелдән астарак булып чыга. Бала кайсы шакмакны барыннан да өстәрәк куйган?

Искәрмәләр:

2*. Җавап: 8 л га арта: 10 - 2 = 8.

3*. Җавап: Яшел шакмакны.

**Вариант 2**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 + 4 = | 2 + 2 = | 6 + 3 = | 1 + 4 = |
| 6 + 5 = | 4 + 8 = | 9 + 9 = | 7 + 6 = |
| 5+2= | 3+6= | 3+3= | 5+0= |
| 9 + 5 = | 7 + 5 = | 7 + 8 = | 4 + 2 = |
| 7+4= | 8+2= | 6+0= | 3+5= |
| 8 + 6= | 9 + 3- | 4 + 4= | 5 + 6 = |
| 6 + 1 = | 2 + 7 = | 9 + 8 = | 2 + 9 = |
| 4 + 5 = | 1 + 2 = | 9 + 1 = | 7 + 7 = |

2*. Өч шакмактан манара төзегәннәр. Сары шакмакны зәңгәрдән өскәрәк һәм кызылдан аскарак куйганнар. Нинди шакмак иң өстә булган?

3*. Тортны бертөрле 4 кисәккә бүлгәннәр, ә аннары һәр кисәкне бертөрле 2 кисәккә бүлгәннәр. Әгәр һәрберсенең тәлинкәсенә берәр кисәк торт куйсаң, торт ничә кешегә җитәр?

Искәрмәләр:

2*. Җавап: Кызыл шакмак.

3*. Җавап: 8 кешегә.

**Вариант 3**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 + 1 = | 5 + 6 = | 9 + 3 = | 0 + 3 = |
| 7 + 5= | 9 + 9= | 4 + 8= | 2 + 3 = |
| 6+7= | 0+1= | 5+9= | 8+8= |
| 5 + 8= | 6 +6= | 8 + 9= | 0+0 = |
| 3+9 = | 8 + 5 = | 3 + 6 = | 7 + 4 = |
| 4 + 2= | 6 + 4= | 7 + 7= | 2 + 9 = |
| 8 + 7 = | 9 + 4 = | 8 + 3 = | 5 + 5 = |
| 9 + 8 = | 4 + 5 = | 2 + 7 = | 8 + 6 = |

2*. Тартмада прэниклэр һәм вафли бар. Прэниклэр вафлига караганда 2 гә кимрәк. Әгәр прэниклэр 6 булса, вафлилар ничә?

3*. Һәр ике ноктаны кисемтә белән тоташтырыгыз (рәс. 12.). Очлары бирелгән нокталарда яткан ничә кисемтә килеп чыкты?

И скәрмәләр:

2*. Әгәр прэниклэр вафлига караганда 2 гә кимрәк икән, ул вакытта вафли прэниктән 2 гә артыграк була. Чишү: 6 + 2 = 8.

3*. Җавап: 6 кисемтә.

**Вариант 4**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 + 5 = | 8 + 7 = | 4 + 7 = | 0 + 9= |
| 8 + 0 = | 1 + 0 = | 8 + 9 = | 8 + 5= |
| 4 + 4= | 6 + 9= | 7 + 6= | 6 + 6 = |
| 7 + 8 = | 9 + 8 = | 8 + 8 = | 2 + 3= |
| 9 + 2 = | 4 + 5 = | 4 + 2 = | 7 + 3= |
| 4 + 6 = | 7 + 7 = | 6 + 5 = | 4 + 9= |
| 6 + 8 = | 8 + 2 = | 8 + 7 = | 5 + 5= |
| 7 + 9 = | 9 + 3 = | 9 + 9 = | 0 + 1= |

'2* Ирек Рифаттан 2 яшькә зуррак. Иреккә 10 яшь. Рифатка ничә яшь?

3*. Һәр ике ноктаны кисемтә белән тоташтырыгыз (рәс. 13). Ничә өчпочмак килеп чыкты?

Искәрмәләр:

2*. Чишү: 10 - 2 = 8. Җавап: 8 яшь.

3*. Җавап: 8 өчпочмак.

**Вариант 5**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 8 = | 4 + 9 = | 9 + 9 = | 6 + 5 = |
| 7 + 2 = | 7 + 8 = | 1 + 9 = | 8 + 4 = |
| 6 + 7 = | 9 + 3= | 0 + 0= | 7 + 7= |
| 6 + 8 = | 9 + 5 = | 6 + 6 = | 3 + 4 = |
| 8 + 5 = | 9 + 7 = | 4 + 8 = | 8 + 3 = |
| 5 + 4 = | 3 + 7= | 8 + 8 = | 5 + 9 = |
| 5 + 5 = | 6 + 9 = | 0 + 7 = | 7 + 6 = |
| 5 + 7 = | 4 + 4 = | 6 + 4 = | 3 + 8 = |

2. Кызыл бау яшеленнән 1 м га һәм зәңгәреннән 2 м га озынрак. Яшел бауның озынлыгы 5 м. Зәңгәр бауның озынлыгын табыгыз.

3*. Ике санның суммасы 9. Сумма беренче кушылучыдан 5 кә зуррак. Икенче кушылучы күпмегә тигез?

Искәрмәләр:

2*. Чишү: 5 + 1 = 6, 6 - 2 = 4. Җавап: 4 ле.

3*. Җавап: 5.

## Вариант 6

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 + 4= | 9 + 6 = | 8 + 8 = | 2 + 9 = |
| 4 + 8= | 7 + 7 = | 8 + 9 = | 0 + 0 = |
| 6 + 6= | 7 + 8 = | 0 + 9 = | 8 + 3 = |
| 4 + 4= | 9 + 5= | 4 + 9= | 3 + 7 = |
| 5 + 6= | 6 + 4 = | 5 + 7 = | 9 + 9 = |
| 6 + 3= | 1 + 1 = | 7 + 9 = | 0 + 1 = |
| 9 + 0= | 8 + 5 = | 7 + 3 = | 4 + 7 = |
| 8+2= | 9+4= | 9+3= | 7+6= |

2*. Элгечтә баш киемнәре эленеп тора: эшләпәләр бүрекләргә караганда 1 гә артыграк, ә бүрекләр беретларга караганда 1 гә артыграк. Эшләпәләр 8. Ничә бүрек һәм ничә берет булган?

3*. Кимүче киметүчедән 2 гә зуррак. Аерма күпмегә тигез?

Искәрмәләр:

2*. Чишү: 8 - 1 = 7, 7 - 1 = 6. Җавап: 7 шапка һәм 6 берет.

3*. Җавап: 2.

## IV чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты булып укучыларның беренче йөз эчендә кушу һәм алуны эшли белүләрен, гади һәм төзелмә арифметик мәсьәләләр чишә белүләрен тикшерү тора.

## Вариант 1

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 42 + 30 | 83 + 9 | 38 -20 | 52 - 8 |
| 64 + 5 | 50 + 26 | 95 - 3 | 60 - 16 |
| 36 + 4 | 35 + 14 | 40 - 7 | 29 - 15 |

2. Зифа 76 сум акча сарыф иткән, ә Равия 9 сумга артыграк. Равия күпме акча сарыф иткән?
3. Әниләре Рәшиткә 15 чия биргән. Ул энесенә 5 чия, ә сеңлесенә 6 чия биргән. Ул үзенә ничә чия калдырган?

4*. Әгәр 15 елдан соң без бабайның житмеш яшьлеген билгеләп үтсәк, минем бабайга ничә яшь икәнен уйлап белегез.

5* Ике санның аермасы киметүчегә тигез. Шундый саннар уйлап табыгыз һәм мисал китерегез.

И с кәрмәлә р:

4*. Чишү: 70 - 15 = 55. Җавап: 55 яшь.

5*. Андый саннар пары бик күп: 6 - 3 = 3, 14 - 7 = һ.б.

## Вариант 2

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 30 + 54 | 6 +89 | 97 +90 | 22 - 9 |
| 5 + 42 | 41 +40 | 26-5 | 50 - 34 |
| 7 + 55 | 24 +35 | 80-7 | 99 - 66 |

2. Өске киштәгә 12 китап, ә аскысына 3 китапка кимрәк куйганнар. Аскы киштәгә ничә китап куйганнар?
3. Автобуста 30 кеше барган. Тукталышта 5 кеше төшкән, ә 12 кеше кергән. Моннан соң автобуста ничә кеше булган?

4*. Ике санның аермасы 0 гә тигез. Мисал уйлагыз һәм язып куегыз.

5*. Әбиләре тәлинкәгә 12 груша куйган. Оныклары тәлинкәдән 1 әр груша алганнан соң, анда 8 груша калган. Әбинең ничә оныгы бар?

Искәрмәләр:

4*. Бу очракта кимүче киметүчегә тигез. Мәсәлән: 8 - 8 = 0.
5*. Чишү: 12 - 8 = 4. Җавап: 4 онык.

## Вариант 3

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 64 + 20 | 57 + 6 | 46 - 30 | 41 - 7 |
| 75 + 3 | 20 + 69 | 87 - 6 | 70 -23 |
| 28 + 2 | 15 + 33 | 30 - 3 | 68 -45 |

2. Кисәктә 45 м марля булган. Ул кисәктән сатучы берничә метр марля кисеп алгач, кисәктә 30 м марля калган. Сатучы кисәктән ничә метр марля кисеп алган?
3. Мичкәдә 50 кг кыяр тозлаганнар. Кыяр тозлангач, мичкәдән 2 тапкыр 6 шар кг кыяр алганнар. Мичкәдә ничә килограмм кыяр калган?

4*. Математика дәресендә укытучы Фәриттән 7 дән кечерәк булган барлык саннарны, ә Сәлимнән 3 тән зуррак һәм 9 дан кечерәк булган барлык саннарны атап чыгарга куша. Малайлар нинди бертөрле саннарны атаганнар? Ул саннарны языгыз.

5*. Бабайлары өч оныкның һәркайсына дүрт куактан берәр роза өзәргә рөхсәт биргән. Барлык оныклар ничә роза өзгәннәр?

Искәрмәләр:

4*. Соралган саннарны тиз генә язып бирү кайбер укучылар өчен катлаулы булырга мөмкин. Шуңа күрә укытучы башта аларга Фәрит әйткән саннарны, ә аннары Сәлим әйткән саннарны атап чыгарга куша. Моннан соң укучылар җавапны җиңел язып куялар. Шулай итеп, Фәрит 0, 1, 2, 3, 4, 5 һәм 6 саннарын, ә Сәлим 4, 5, 6, 7, 8 саннарын әйткән. Җавап: 4, 5, 6.

5*. Чишү: 4 + 4 + 4 = 12. Җавап: 12 роза.

## Вариант 4

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 50 + 17 | 28 +7 | 38 -30 | 25 -6 |
| 2 + 22 | 60 +14 | 47 -5 | 40 -31 |
| 6 + 54 | 74 +25 | 90 -8 | 54 -14 |

•2. Капчыктан 9 кг бәрәңге алгач, анда 7 кг бәрәңге калган. Капчыкта ничә килограмм бәрәңге булган?

3. Залда ике люстра бар. Берсендә 6 лампочка, ә икенчесендә 8 лампочка. Кичә люстралардагы 3 лампочка янып чыккан һәм аларны яңалары белән алыштырганнар. Ничә лампочканы алыштырырга туры килмәгән?

4*. Шугалакта 6 кыз һәм 2 малай тимераякта шуалар. Озакламый өч баланы төшке ашка чакыралар, һәм алар өйләренә кайтып китәләр. Шугалакта бер генә булса да кыз бала каламы?

5*. Бер банка виноград согы сатып алганнар. Дүрт балага берәр стакан сок салып биргәннәр. Моннан соң банкада, балалар күпме сок эчкән булсалар, шул кадәр сок калган. Банкада ничә стакан сок булган?

Искәрмәләр:

4*. Логик характердагы мәсьәлә. Теләсә нинди очракта да шугалакта һич югы бер кыз бала кала, хәтта өйгә чакырылган балалар барысы да кызлар булганда да. Җавап: Әйе (Кала).

5*. Чишү: 4 + 4 = 8. 8 стакан.

## Вариант 5

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 18 +80 | 55 + 9 | 93 - 60 | 52 - 7 |
| 63 + 3 | 70 + 23 | 41 - 8 | 60 - 32 |
| 47 + 3 | 42'+ 42 | 30 - 4 | 48 - 15 |

2. Лимонны кечкенә кисәкләргә кискәләгәннәр. 5 кисәкне стаканнарга салгач, тагын 4 кисәк калган. Лимонны ничә кисәккә кискәннәр?
3. Өч төсле тукыма сатып алганнар. Яшел тукыманың озынлыгы 6 м. Зәңгәр тукыма яшеленнән 9 м га озынрак, ә кызылы зәңгәреннән 4 м га кыскарак. Кызыл тукыманың озынлыгын табыгыз.

4*. Тартмада 12 конфет. Тартмада 4 конфеттан кимрәк калсын өчен, аннан ничә конфет алырга мөмкин?

5*. Марат белән Камил чиратлап баскетбол кәрзиненә туп ыргыталар. 10 ыргытудан Маратның тубы кәрзингә 7 тапкыр эләгә. Камил шулай ук 10 тапкыр ыргыта, тупның 4 есе кәрзингә эләкми. Малайларның кайсысының нәтиҗәсе яхшырак?

Искәрмәләр:

4*. Мәсьәлә сайлап алу юлы белән чишелә. Саннарны 1 саныннан башлап сайлап алырга була. 1 дән 8 гә кадәрге саннар туры килми, чөнки аерма һәрвакыт 4 тән кечерәк калмый. Тартмада 9, 10, 11 яки 12 конфет алырга мөмкин: 12 - 9 = 3, 3 < 4; 12 - 10 = 2, 2 < 4; 12 - 11 = 1, 1 < 4; 12 - 12 = 0, 0<4. Җавап: 9, 10, 11, 12.

5*. Камил кәрзингә 6 тапкыр ( 10 - 4 = 6) эләккән. Шулай итеп, 10 ыргытудан Камилнең 6 сы туры килә, ә Маратның 10 ыргытудан 7 се туры килә; Маратның нәтиҗәсе яхшырак. Җавап: Маратныкы.

## Вариант 6

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 30 + 61 | 8 + 43 | 63 - 20 | 61 - 2 |
| 6 + 42 | 60 + 43 | 48 - 8 | 50 -25 |
| 9 + 31 | 45 + 23 | 70 - 4 | 83 -71 |

2. Әбинең 8 йомгак йоны булган. Берничә йомгактан ул Лилиягә башлык бәйләгән, ә калган 6 йомгактан Алиягә джемпер бәйләгән. Башлыкка ничә йомгак йон киткән?
3. Безнең песинең 7 баласы бар. Берничәсе аның җирән, икесе кара һәм берсе ак. Мәченең ничә җирән баласы бар?

4*. Кавын карбызга караганда 3 кг га җиңелрәк. Кавыннан 1 кг массалы кисәк, ә карбыздан 3 кг массалы кисәк кисеп алганнар. Кайсысы күбрәк калган: кавынмы яки карбызмы һәм ничә килограммга?

5*. Тәлинкәдә 10 слива бар. Әниләре, тәлинкәдә 6 сливадан күбрәк калырлык итеп, Алмазга берничә слива алырга кушкан. Алмазның ничә слива алуы мөмкин?

Искәрмәләр:

4*. Карбыздан 3 кг кисеп алгач, аның массасы кавын массасы кадәр булып кала. Кавыннан 1 кг кисеп алгач, ул карбыздан 1 кг га җиңелрәк булып чыга, ягъни карбыз кавыннан 1 кг га күбрәк кала. Җавап: Карбыз 1 кг га артыграк.

5*. Җавап: Алмаз 1, 2 яки 3 слива алырга мөмкин.

# ИКЕНЧЕ СЫЙНЫФ

## I ЧИРЕК

### Контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның математика буенча 1 нче сыйныф программа материалын үзләштерүләренең ныклыгын тикшерү. Укучыларның 20 эчендә саннарны таблицалы кушу һәм алу нәтиҗәләрен белүләре; 100 эчендәге саннарны куша һәм ала белүләре; бер гамәл эшләп, гади арифметик мәсьәләләр һәм ике гамәлле катлаулы булмаган төзелмә мәсьәләләр чишә белүләре тикшерелә.

Беренче бирем өчен һәр укучыга индивидуаль карточка әзерләү максатка ярашлы.

**Вариант 1**

1. Җавапларын языгыз

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 + 5= | 8 + 7= | 18-9= | 12-3 = |
| 5 + 8 = | 5 + 2 = | 10 - 7 = | 6 - 0 = |
| 0 + 7 = | 6 + 4 = | 14 - 8 = | 15 - 8 = |
| 3 + 4= | 9 + 3= | 11-6= | 13-7 = |

2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 24 + 13 | 9 + 67 | 68 - 26 | 80 - 8 |
| 45 + 5 | 71 + 20 | 50 - 37 | 100 - 90 |

3. Люциянең буе 1 м 26 см. Бер елда ул 2 см га үскән. Люциянең буе күпме булды?

4. Табибка керү өчен 12 авыру язылган. Беренче сәгатьтә табиб 4 авыруны, ә икенче сәгатьтә 5 авыруны кабул иткән. Аның ничә авыру кабул итәсе калган?

5*. Ике санның аермасы 7 гә тигез. Шундый саннарның өч парын языгыз.

6*. Трамвайда берничә кеше бара. Тукталышта трамвайдан 5 кеше төшә, 9 кеше керә. Трамвайда кешеләр артырмы яки кимерме һәм ничә кешегә?

Искәрмәләр:

5*. Андый саннар пары теләсә никадәр. Җавап: 9 һәм 2, 20 һәм 13, 7 һәм 0. Һәр укучы үзенең мисалларын уйлап таба һәм язып куя.
6*. Җавап: 4 кешегә арта.

## Вариант 2

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 3= | 0 + 0= | 16-9= | 13-7 = |
| 6 + 4 = | 7 + 9= | 14 - 6 = | 17 - 8= |
| 8 + 6 = | 3 + 8 = | 11 - 5 = | 8 - 0= |
| 4 + 5 = | 9 + 2 = | 13 - 4 = | 15 - 7= |

2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 26 + 54 | 32 + 8 | 100 - 6 | 40 - 28 |
| 43 + 31 | 50 + 27 | 29 - 17 | 56 - 30 |

3. Лена тартмадан 4 шакмак, ә Алия 6 шакмак алгач, тартма бушап калган. Тартмада ничә шакмак булган?

4. Иртән бер куакта 8 роза чәчәк аткан, ә икенчесендә 3 розага кимрәк аткан. Иртән бу куакларда ничә роза чәчәк аткан?

5*. Вәсил массасы 6 кг нан артык булган йөкне күтәрә алмый. Алар әбисе белән кибеттән 3 кг алма, 6 кг бәрәңге һәм 2 кг кыяр алган булсалар, Вәсил аларның кайсыларын күтәреп кайта ала?

6*. Термометр 12 градус салкынны күрсәткән. Берникадәр вакыттан соң терекөмеш баганасы 3 градуска түбән төшкән. Урамда салкынайдымы әллә җылындымы һәм ничә градуска?

Искәрмәләр:

5*. Укучылар барлык чишелешләрне язып куярга тиеш:
3 кг, 6 кг, 5 кг.
6*. Җавап: 3 градуска салкынрак.

**Вариант 3**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 6 = | 9 + 5 = | 11 - 4 = | 10 - 8 = |
| 2 + 7 = | 6 + 7 = | 18 - 9 = | 15 - 6 = |
| 1 + 8= | 0 + 8= | 13-8= | 6-0 = |
| 4 + 7 = | 9 + 9 = | 14 - 9 = | 12 - 5 = |

2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 46 + 13 | 80 + 8 | 60 - 31 | 39 - 19 |
| 9 + 91 | 36 + 54 | 70 - 7 | 97 - 80 |

3. Өй янындагы мичкәдә 50 л су булган. Яңгыр яуган һәм мичкәдәге суның күләме 6 л га арткан. Яңгырдан соң мичкәдә күпме су булган?
4. Чемоданның массасы 15 кг, ә рюкзакныкы 5 кг. Үлчәүгә чемодан, рюкзак һәм сумка куйганнар. Үлчәү 28 кг күрсәткән. Сумканың массасы күпмегә тигез?

5*. 5 см озынлыкта яшел кисемтә сызыгыз. Озынлыгы яшел кисемтәдән 2 см га аерыла торган кызыл кисемтә сызыгыз.

6*. Марат белән Зөфәр театрга билетлар сатып алганнар; Маратның 15 нче рәт 8нче урын. Зөфәрнең урыны Марат белән янәшәдә. Зөфәрнең билетында кайсы рәт һәм кайсы урын күрсәтелергә мөмкин? Дүрт җавапның берсен сайлап алыгыз:

1) рәт 8 урын 15;
2) рәт 8 урын 16;
3) рәт 15 урын 19;
4) рәт 15 урын 7.

Искәрмәләр:

5*. Мәсьәләнең ике чишелеше бар: кызыл кисемтәнең озынлыгы 7 см да, 3 см да булырга мөмкин.

6*. Җавап: рәт 15 урын 9 яки рәт 15 урын 7. Укучылар ике очракны да карарга тиеш.

**Вариант 4**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 + 9 = | 9 + 8 = | 12 - 8 = | 13 - 4 = |
| 6 + 6 = | 5 + 8 = | 4 - 0 = | 6 - 6 = |
| 3 + 8= | 0 + 9= | 11-7= | 12-9 = |
| 7 + 7 = | 8 + 4 = | 16 - 9 = | 14 - 5 = |

2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 20 + 40 | 32 + 50 | 65 - 15 | 40 - 16 |
| 56 + 4 | 84 + 7 | 70 - 4 | 29 - 13 |

3. Самолет салонына берничә пассажир кергән. Салонга тагын 7 кеше кергәч, анда 13 кеше булган. Беренче тапкыр ничә кеше кергән?
4. Тактаның озынлыгы 35 дм. Аның сул очыннан 6 дм озынлыктагы кисәк, ә уң очыннан 8 дм озынлыктагы кисәк кисеп алганнар. Тактаның калган өлешенең озынлыгын табыгыз.
5*. Ике санның суммасы шул ук саннарның аермасына тигез булырга мөмкинме? Шундый саннарны уйлагыз һәм язып куегыз.
6*. 14 нче рәсемдә сез ничә дүртпочмак күрәсез?

Искәрмәләр:

5*. Җавап: Булырга мөмкин, әгәр саннарның берсе (яки икесе) 0 булса. Укучылар төрле мисаллар яза алалар: 3 һәм 0, 25 һәм 0, 0 һәм 0 һ.б.
6*. Җавап: 5.

### Вариант 5

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 + 4 = | 3 + 7 = | 11 - 9 = | 12 - 4= |
| 6 + 8 = | 4 + 4 = | 8 - 8 = | 14 - 7= |
| 5 + 9 = | 7 + 8 = | 17 - 8 = | 16 - 8= |
| 9 + 7 = | 6 + 9 = | 13 - 5 = | 13 - 9= |

2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 36 + 4 | 64 + 20 | 71 - 7 | 90 - 63 |
| 62 + 36 | 5 + 78 | 38 - 30 | 57 - 24 |

3. Мин, өйдән чыгып, мәктәпкә киттем. 60 м үткәч, мәктәпкә кадәр 40 м калды. Мәктәп өйдән нинди ераклыкта урнашкан?
4. Үлчәүгә бертөрле ике пакет ярма һәм шикәр салынган бер пакет куйганнар. Үлчәү 5 кг күрсәтә. Ярмалы пакетның массасы 2 кг. Шикәр салынган пакетның массасын табыгыз.
5. Илсөяр үзенең акчасын санаганнан соң, зонтик сатып алу өчен, тагын 4 сум акчасы җитмәвен белгән һәм әнисеннән акча сорап алган. Әнисе аңа 10 сум акча биргән. Зонтик сатып алганнан соң, Илсөярнең күпме акчасы калган?
6*. Линейкадан файдаланмыйча, 5 см озынлыктагы кисемтә сызыгыз.

Искәрмәләр:

5*. Чишү: 10 - 4 = 6. Җавап: 6 сум.
6*. Биремнең максаты — күз белән чамалый белүне тикшерү. Укытучы укучыларны кисемтәне шакмаклар буенча сызмаска, ә дәфтәр битендә ирекле урнаштырырга куша. Балаларга сызыксыз кәгазь өләшеп чыгу яхшырак булыр.

## Вариант 6

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 + 6= | 7+6= | 10-6= | 12-5= |
| 7 + 8= | 4 + 0= | 14-9= | 17-9= |
| 9 + 5 = | 6 + 5 = | 16 - 7 = | 13 - 8 = |
| 8 + 8= | 8 + 9= | 11-3= | 11-6= |

2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 50 + 30 | 63 + 14 | 100 - 15 | 70 - 35 |
| 42 + 8 | 75 + 9 | 94 - 80 | 67 - 40 |

3. Суыткычта 30 йомырка булган. Йомырка тәбәсе пешергәннән соң, суыткычта 24 йомырка калган. Йомырка тәбәсе пешерергә ничә йомырка киткән?
4. Туган көнгә 6 кунак чакырылган. Табын хәзерләгәндә, әни һәр тәлинкә янына чәнечке белән пычак куеп чыккан. Ләкин ике кунак килмәгән. Ьәм аларга дип хәзерләнгән приборларны әни өстәлдән алып куйган. Өстәлдә ничә чәнечке һәм пычак калган?

5*. Вазада конфетлар бертөрле ике пакеттагыдан 20 гә артыграк. Вазада 30 конфет. Пакетта ничә конфет?

6*. Стаканга, чынаякка һәм кувшинга кофе, сок һәм чәй салганнар. Стаканда кофе түгел. Чынаякта сок та түгел һәм чәй дә түгел. Кувшинда чәй түгел. Кайсы савытка нәрсә салынган?

Искәрмәләр:

5*. Чишү: 30 - 20 = 10, 10 = 5 + 5. Җавап: 5.
6*. Мәсьәләнең шартыннан чынаякта кофе икәнлеге үзеннәнүзе аңлашыла. Стаканда кофе булмагач, анда сок яисә чәй булырга мөмкин. Ләкин кувшинда чәй түгел, һәм кофе да түгел, чөнки кофе — чынаякта. Димәк, кувшинда — сок. Ул вакытта стаканда — чәй.
Укучылар җавапларын гына язарга тиешләр: чынаякта — кофе, кувшинда — сок, стаканда — чәй.

## 1 чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты укучыларның исәпләүнең язма алгоритмнарыннан (исәпләү нәтиҗәләре 100 дән артмый) файдаланып, икеурынлы саннарны куша һәм ала белүләрен; гади арифметик мәсьәлә чишү өчен, арифметик гамәл (кушу яки алу) сайлый белүләрен; линейка ярдәмендә бирелгән озынлыктагы (сантиметрларда) кисемтә төзи белүләрен тикшерүдән гыйбарәт.

2 нче мәсьәләдә исәпләүләрне башкармаска кирәк. Укучылар яраклы дип тапкан аңлатманы сайлап алырга һәм аны күчереп язарга тиешләр.

Кисемтә төзү (3 нче бирем) линейка ярдәмендә башкарылырга тиеш. Әгәр сызым пөхтә итеп башкарылса, кисемтә дөрес төзелгән дип исәпләнә; кисемтә озынлыгы бирелгән озынлыкка туры килә (ялгышу теге яки бу якка 1—2 мм га гына булырга мөмкин); кисемтә очлары ноктвлар белән билгеләнгән (яки зур булмаган штрихлар белән).

## Вариант 1

1. Исәпләгез:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 15 | 45 | 58 | _46 | _60 | _91 |
| ±72 | +29 | +17 | 32 | 36 | 9 |

2. 6 + 2, 6 - 2, 6 : 2, 6 • 2 аңлатмалары бирелгән. «Тартмада 6 карандаш. Шундый 2 тартмада ничә карандаш?» мәсьәләсен чишү өчен кирәкле аңлатманы сайлап ал һәм күчереп яз.
3. 7 см озынлыкта кисемтә сыз.
4*. Кыйммәте 6 санына тигез булган аңлатма уйлап яз.
5*. Алу гамәле дөрес үтәлсен өчен, квадрат һәм түгәрәк эченә нинди цифрлар язарга кирәк:

-□2
48
3О

Искәрмәләр:

4*. Мисаллар: 12 : 2, 4 + 2, 20 - 14, 2 • 3.

5*. Квадрат эчендә 8, ә түгәрәк эчендә 4.

## Вариант 2

1. Исәпләгез:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 51 | 43 | 85 | _68 | _52 | _60 |
| ±16 | +29 | +15 | 42 | 36 | 5 |

2. 24 + 4, 24 - 4, 24 • 4, 24 : 4 аңлатмалары бирелгән. Түбәндәге мәсьәләне чишәргә ярдәм иткән аңлатманы сайлап алыгыз һәм күчереп языгыз. «Бертөрле 4 төймәнең бәясе 24 сум. Төймәнең бәясен табыгыз».
3. 8 см озынлыкта кисемтә сызыгыз.
4*. Ике дөрес тигезсезлек уйлап языгыз: берсе $<$ билгесе белән, ә икенчесе $>$ билгесе белән.
5*. Кәүсәриягә өч тәңкә акча белән 20 сум акча биргәннәр. Ул нинди тәңкәләр?

Искәрмәләр:
4*. Мисаллар $5 < 7$, $75 > 0$; $6 \cdot 2 < 17 + 24$; $20 > 15 : 3$.
5*. Җавап: Тәңкәләр: 10 сум, 5 сум, 5 сум.

## Вариант 3

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 18 + 56 | 67 - 14 | 38 + 62 |
| 27 + 13 | 100 - 43 | 97 - 58 |

2. 6 - 3, 6 : 3, 6 • 3, 6 + 3 аңлатмалары бирелгән. Түбәндәге мәсьәләне чишәргә ярдәм иткән аңлатманы язып алыгыз: Алты литрлы шешәгә мөлдерәмә итеп сок салганнар. Бу сокны ничә өч литрлы банкага тутырырга мөмкин?
3. Кызыл кисемтәнең озынлыгы 4 см. Озынлыгы 1 см га артыграк булган зәңгәр кисемтә сызыгыз.
4*. Өстәл өстендә матрешкалар тора. Һәр 3 зур матрешкага 5 кечкенә матрешка сыя. Өстәл өстендә ничә матрешка?
5*. Сатучы һәр кисәк сырны урталай бүлгән. 6 яртышар кисәк килеп чыкса, ничә кисәк сыр булган?

Искәрмәләр:
4*. Мөгаен, балаларның күпчелеге мәсьәләне болай чишәрләр: 5 • 3 = 15, 15 + 3 = 18. Башка, әйбәтрәк чишелеш бар: бер комплектта 6 матрешка, ә аларның барысы 18 (6 • 3 = 18).
5*. 6 яртышар кисәктә икешәр ярты кисәк (ягъни бөтен кисәк сыр) 3 тапкыр бар. Барлыгы 3 кисәк сыр (6 : 2 = 3). Җавап: 3. Җавапларын гына (3 саны) язган балалар бу мәсьәләне чишкәннәр дип санала.

## Вариант 4

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 56 + 38 | 82 + 18 | 100 - 28 |
| 74 + 15 | 78 - 65 | 31 - 16 |

2. 10 - 5, 5 • 10, 10 + 5, 10 : 5 аңлатмалары бирелгән. Түбәндәге мәсьәләне чишәргә ярдәм иткән аңлатманы күчереп языгыз. «Костюмга 5 м тукыма китә. Шундый 10 м тукымадан ничә костюм тегеп була?»
3. Яшел кисемтәнең озынлыгы 5 см. Озынлыгы 1 см га кимрәк булган кызыл кисемтә сызыгыз.
4*. Яшел һәм кызыл шарлар салынган пакеттан, карамыйча гына, 3 шар алганнар. Алар нинди төстә булырга мөмкин һәм һәр төслесе ничә?
5*. Пакетта кәрзиндәге кадәр лимон бар. Пакеттан 3 лимон, ә кәрзиннән 5 лимон алганнар. Кайда лимон күбрәк калган һәм ничәгә?

Искәрмәләр:

4*. Әгәр укучы мөмкин булган барлык очракларны да күрсәтсә, мәсьәләне тулысынча чишелгән дип исәпләргә кирәк: а) барлык шарларяшел; б) барлык шарлар кызыл; в) 2 яшел һәм 1 кызыл шар; г) 1 яшел һәм 2 кызыл шар.

5*. Пакеттан лимонны кәрзиндәгедән кимрәк алганнар, шуңа күрә анда лимон күбрәк кала; ничәгә икәнен дә белеп була: 5 - 3 = 2. Бу фикер йөртүләрне укучылар язмыйлар. 5 - 3 = 2 чишелешен язсалар, шул җитә. Җавап: Пакетта 2 гә артыграк.

## Вариант 5

1. Саннарны «баганалап» язып, исәпләүләр дөрес эшләнгәнме икәнен тикшерегез. Кайсы мисаллар дөрес чишелмәгән? Аларны, җавапларын дөресләп, аерым күчереп языгыз.

| | |
|---|---|
| 72 + 8 = 80 | 56 - 27 = 39 |
| 36 + 49 = 85 | 77 - 9 = 68 |
| 83 + 17 = 100 | 100 - 84 = 26 |

2. 4 + 1, 1 + 1 + 1, 4 • 3 + 1 аңлатмалары бирелгән. Кайсы аңлатма ярдәмендә мәсьәләне чишеп була: «Тартмада 4 зефир бар. Өч кыз берәр тартма зефир сатып алганнар. Кызлар ничә зефир сатып алганнар?»
3. Озынлыгы 10 см дан кимрәк булган теләсә нинди кисемтә сызыгыз. Ул кисемтәнең озынлыгын сантиметрларда языгыз.
4*. Ике вазада конфетлар бертигез. Бер вазага тагын 5 конфет куйгач, ә икенчесеннән 5 конфетны алгач, ике вазада бергә 20 конфет калган. Башта һәр вазада ничә конфет булган?

5*. Фәрит бакчада ничә алмагачка су сипсә, Кадрия дә шулкадәр сипкән. Фәрит тагын грушага да сипкәч, алар 9 агачка су сипкән булып чыккан. Фәрит ничә алмагачка су сипкән ?

Искәрмәләр:

4*. Бер вазага 5 конфет куеп, икенчесеннән 5 не алгач, вазалардагы конфетның гомуми саны үзгәрми: 20 булган һәм 20 калган, ягъни һәр вазада 10 ар конфет булган.
5*. Чишү: 9 - 1 = 8, 8 : 2 = 4. Җавап: 4.

**Вариант 6**

1. Гамәлләр дөрес эшләнгәнме икәнен тикшерегез; исәпләүләрне баганалап эшләгез. Дөрес чишелгән мисалларны аерым язып куегыз.

| | |
|---|---|
| 64 + 27 = 91 | 48 - 29 = 29 |
| 55 + 16 = 66 | 100 - 76 = 24 |
| 32 + 62 = 90 | 71 - 7 = 64 |

2. 8 : 2, 2 + 8, 2 • 8 аңлатмалары бирелгән. Кайсы аңлатма ярдәмендә мәсьәләне чишәргә мөмкин: «8 укучы 2 шәр агач утырткан. Укучылар ничә агач утыртканнар?»
3. Озынлыгы 5 см дан зуррак булган кисемтә сызыгыз. Бу кисемтәнең озынлыгын сантиметрларда языгыз.

4*. Залдагы барлык балаларны утырту өчен, 6 урындык җитми. Берничә урындык керткәч, 2 урындык артык булып чыккан. Залга ничә урындык керткәннәр?

5*. Энемнең уенчыклары сеңлемнеке кадәр. Энемә тагын 4 уенчык сатып алгач, аның 12 уенчыгы булды. Сеңлемнең ничә уенчыгы булган?

Искәрмә:

4*. Чишү: 6 + 2 = 8. Җавап: 8.

II ЧИРЕК

## «Аңлатмаларның кыйммәтләрен исәпләү һәм төзү»

Бу эштә гади һәм төзелмә санлы аңлатмаларны (җәяләр белән һәм җәяләрсез) яза белүләре, ике арифметик гамәлне эченә алган төзелмә аңлатмаларның кыйммәтләрен табу осталыклары тикшерелә.

Контроль эш тапкырлау таблицасын өйрәнгәннән соң үткәрелә.

**Вариант 1**

1. Аңлатма рәвешендә языгыз:
   27 һәм 5 нең суммасын;
   2 һәм 6 ның тапкырчыгышын;
   17 һәм 8 нең аермасын;
   6 һәм 2 нең өлешен.
2. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

| | |
|---|---|
| 48 - (8 + 5) | 3 • 6 : 2 |
| 48 - 8 - 5 | 8 • (6 + 1) |
| 56 - 20 + 36 | 12 - 6 : 3 |

3*. Миләүшәнең ике адымы 1 м. Аның бүлмәсенең иңе аның 8 адымына тигез. Бүлмәнең иңен метрларда языгыз.

4*. Өстәл өстендә өч тәңкә акча ята: 1 сум, 5 сум һәм 10 сум. Мин өстәлдән ике тәңкә алдым. Минем күпме акча алуым мөмкин?

Искәрмәләр:

3*. Чишү: 8 : 2 = 4. Җавап: 4 м.

4*. Җавап: 6 сум (1 + 5), 11 сум (1 + 10 ) яки 15 сум (5 + 10).

**Вариант 2**

1. Аңлатма рәвешендә языгыз:
   7 һәм 2 нең тапкырчыгышын;
   9 һәм 64 нең суммасын;
   10 һәм 5 нең өлешен;
   16 һәм 7 нең аермасын.
2. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

| | |
|---|---|
| 96 - 56 + 40 | (24 + 12) : 4 |
| 30 - (3 + 10) | 12 : 3 • 2 |
| 30 - 3 - 10 | 16 - 8 : 2 |

3* Әгәр өч төсле: кызыл, зәңгәр һәм яшел тукымалар булса, ике төсле ничә төрле флажок ясап булыр?

4*. Егерме, кырык, бер, биш, ж,иде сүзләреннән файдаланып, барлык икеурынлы саннарны цифрлар белән языгыз.

Искәрмәләр:

3*. Җавап: 3 флаг (кызыл-зәңгәр, кызыл-яшел һәм зәңгәр-яшел).

4*. Җавап: 20, 40, 21, 25, 27, 41, 45, 47.

**Вариант 3**

1. Аңлатма рәвешендә языгыз:
   36 һәм 9 саннарының өлешен 2 гә тапкырларга;
   27 һәм 9 саннарының аермасына 6 ны кушарга;
   5 һәм 4 саннарының суммасын 3 кә бүләргә;
   9 һәм 2 саннарының тапкырчыгышыннан 1 не алырга.
2. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

| | |
|---|---|
| 90 - (7 + 12) | 20 - 2 • 8 |
| 90 - 7 - 12 | 24 : (8 - 2) |
| 86 - 76 + 10 | (9 + 3) : 3 |

3*. Өстәге кран аша бакка бер сәгатьтә 12 чиләк су агып керә, ә түбәнге кран аша 8 чиләк су агып чыга. Ике кранны бер үк вакытта 2 сәг кә ачканнар. Бу вакыт эчендә бакта күпме су булыр?

4*. Зөлфия, Гөлфия һәм Дания өч төстәге — кызыл, зәңгәр һәм сары күлмәкләр кигәннәр. Зөлфия кызылны да, зәңгәрне дә кимәгән, ә Гөлфия кызыл күлмәктә түгел. Кызларның һәркайсында нинди төстәге күлмәк?

Искәрмәләр:

3*. Чишү: 12 - 8 = 4, 4 • 2 = 8. Җавап: 8.

4*. Җавап: Зөлфиядә сары күлмәк, Гөлфиядә зәңгәр, ә Даниядә кызыл күлмәк.

**Вариант 4**

1. Аңлатма рәвешендә языгыз:
   2 һәм 3 нең тапкырчыгышын 6 га бүләргә;
   14 һәм 15 саннарының суммасына 16 ны кушарга;
   7 һәм 4 саннарының аермасын 8 гә тапкырларга;
   48 һәм 6 саннарының өлешеннән 5 не алырга.
2. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

| | |
|---|---|
| 84 - 34 + 50 | 16 + 4 • 2 |
| 69 + 17 - 9 | 48 : (3 + 3) |
| 69 - 17 + 9 | 16 - 8 : 4 |

3*. Миләүшә, Ләйсән, Лилия һәм Кадрия гимнастика буенча ярышларда шушындый нәтиҗәләр күрсәткәннәр: 6 балл, 5 балл, 5 балл, 4 балл. Лилия Ләйсәнгә караганда күбрәк балл җыйган, ә Миләүшәнең баллары Кадриянеке кадәр. Ләйсән ничә балл җыйган? Сайлап алыгыз һәм дөрес җавапны языгыз: 1) 6 балл; 2) 5 балл; 3)4 балл.

4*. Шкафта 3 сай һәм 4 тирән тәлинкә булган. Шкафтан 4 тәлинкә алганнар. Нинди һәм ничә тәлинкә алырга мөмкиннәр?

Искәрмәләр:

3*. Җавап: 4 балл.

4*. Җавап: 1) 3 сай һәм 1 тирән тәлинкә; 2) 2 сай һәм 2 тирән тәлинкә; 3) 1 сай һәм 3 тирән тәлинкә; 4) 4 тирән тәлинкә.

## Вариант 5

1. Аңлатма төзегез:
   24 саныннан, бүлү тамгасыннан һәм 6 белән 2 саннарының өлешеннән;
   60 саныннан, алу тамгасыннан һәм 12 белән 18 саннарының суммасыннан;
   4 һәм 5 саннарының тапкырчыгышыннан, бүлү тамгасыннан һәм 20 саныннан;
   12 һәм 4 саннарының аермасыннан, тапкырлау тамгасыннан һәм 7 саныннан.
2. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

| | |
|---|---|
| 42 - (15 + 6) | 36 + 24 : 6 |
| 42-15 + 6 | 18:(2-3) |
| 100 - 75 + 25 | 18 : 2 • 3 |

3*. Миләүшәнең 50 сум акчасы булган. Әтисе аңа өч тәңкә акча биргән. Моннан соң аның барысы 100 сум акчасы булган. Әтисе Миләүшәгә нинди тәңкә акчалар биргән?

4*. Мин 1 дән 100 гә кадәрге барлык саннарны тәртип буенча яздым. Мин 5 цифрын ничә тапкыр язганмын?

Искәрмәләр:

3*. Әтисе Миләүшәгә 50 сумны 10 сум, 20 сум, 20 сумлык тәңкә акчалар белән биргән.

4*. Мөгаен, балалар башта язылышында 5 цифры булган барлык саннарны язып чыгарлар (5, 15, 25, 35, 45, 55, 65, 75, 85, 95), аннары җавапны язалар: 20 тапкыр.

## Вариант 6

1. Аңлатма төзегез:
   25 саныннан, алу тамгасыннан һәм 6 белән 4 саннарының тапкырчыгышыннан;
   47 һәм 8 нең суммасыннан, алу тамгасыннан һәм 21 белән 7 саннарының өлешеннән;

9 санынннан, тапкырлау тамгасыннан һәм 12 белән 4 саннарының аермасыннан;
40 һәм 15 саннарының аермасыннан, бүлү тамгасыннан һәм 5 санынннан.

2. Аңлатмаларның кыйммәтен табыгыз:

| | |
|---|---|
| 60 - 25 + 35 | 32 - 12 : 4 |
| 54 + (18 - 6) | 32 : (8 : 2) |
| 54 + 18 - 6 | 6 • (2 + 7) |

3*. Әгәр өч малайның һәркайсы вазадан 4 әр абрикос алса, вазада 1 абрикос кала. Вазада ничә абрикос булган?

4*. Кыйммәте булмаган аңлатма уйлап языгыз.

Искәрмәләр:

3*. Чишү: 4 • 3 = 12, 12 + 1 = 13. Җавап: 13.

4*. Әлеге очракта натураль саннар күплегендә кыйммәтләре булмаган аңлатмалар күздә тотыла; андый аңлатмалар бик күп. Мәсәлән, 5 - 6, 12 : 7.

## II чиреккә контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның тапкырлау таблицасын белүләрен һәм, тапкырлау таблицасын кулланып, бүлү нәтиҗәләрен таба белүләрен, гади арифметик мәсьәләне чишү өчен, гамәлне (тапкырлау яки бүлү) дөрес сайлый белүләрен; «зуррак», «кечерәк» сүзләре белән билгеләнгән саннар арасындагы бәйләнешләрнең мәгънәсен аңлауларын; кирәкле арифметик гамәлне сайлап, бирелгән бәйләнештәге саннарны чагыштыра белүләрен тикшерү.

II чиректә өйрәнелә торган уку материалының төп өлеше булып тапкырлау таблицасы һәм бүлүнең таблицалы очраклары тора. Бары II чирек барышында гына барлык сыйныф укучылары белән тапкырлау таблицасын яхшылап үзләштерү мөмкин түгел, бирелгән эштәге 1 нче бирем тапкырлау таблицасын үзләштерүнең иң беренче картинасын бирә. Табылган мәгълүматлар таблицаны ныгытып хәтерләрендә калдырмаган укучыларны ачыкларга ярдәм итә. Бу эшкә нульгә тапкырлау һәм бүлү гамәлләре кермәгән.

Беренче бирем өчен индивидуаль карточкалар әзерләү максатка ярашлы булыр; калган биремнәрне дәрескә кадәр тактага язып куярга мөмкин.

### Вариант 1

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2·5= | 4·7= | 14 : 7= | 10 : 2= |
| 7 • 9 = | 2 • 8 = | 42 : 6= | 16 : 8= |
| 6 • 6 = | 9 • 3= 40 | 40 : 8= | 63 : 9= |
| 3 • 8 = | 8 • 6 = | 28 : 7= | 21 : 7= |

2. 8 кенәрине 2 шәрләп читлекләргә урнаштырганнар. Ничә читлек кирәк булган?
3. Массалары бертөрле булган 4 пакет бәрәңге сатып алганнар. Әгәр һәр пакетта 3 әр кг булса, ничә килограмм бәрәңге сатып алганнар?
4. Гамәлне дөрес сайлагыз һәм чишелешен языгыз.
   4 саны 24 тән ничә тапкырга кечерәк?
   48 саны 6 дан ничәгә зуррак?
   4 саны 24 тән ничәгә кечерәк?
   48 саны 6 дан ничә тапкырга зуррак?

5* Тапкырчыгышы 12 гә тигез булган барлык саннар парын языгыз.

6*. 20 укучыны утыртырга икеурынлы 8 парта җитәрме?

И с к ә р мәлә р:

5*. Җавап: 1 һәм 12, 2 һәм 6, 3 һәм 4.
6*. Чишү: $2 \cdot 8 = 16$. $16 < 20$. Җавап: Җитми.

**Вариант 2**

1. Җавапларны языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| $5 \cdot 3 =$ | $8 \cdot 5 =$ | $56 : 7 =$ | $36 : 4 =$ |
| $7 \cdot 5 =$ | $4 \cdot 4 =$ | $27 : 3 =$ | $30 : 6 =$ |
| $4 \cdot 2 =$ | $9 \cdot 6 =$ | $48 : 8 =$ | $72 : 9 =$ |
| $3 \cdot 4 =$ | $3 \cdot 3 =$ | $16 : 2 =$ | $10 : 2 =$ |

2. Оста тимерчыбык кисәгеннән 5 тапкыр 6 шар м чыбык кисеп алган. Ул барысы ничә метр кисеп алган?
3. 9 л томат согын 3 банкага тигез итеп бүлеп салганнар. Бәр банкага ничә литр сок салганнар?
4. Гамәлне дөрес сайлагыз һәм чишелешен языгыз:
   15 саны 5 тән ничәгә зуррак?
   15 саны 5 тән ничә тапкырга зуррак?
   4 саны 20 дән ничәгә кечерәк?
   4 саны 20 дән ничә тапкырга кечерәк?

5*. 3 кә, 4 кә, 6 га бүленә торган 0 гә тигез булмаган сан уйлагыз һәм аны язып куегыз.

6*. Өч дус шахматта уйныйлар. Һәркайсы 2 шәр партия уйный. Барлыгы ничә партия уйналган?

И с к ә р м ә л ә р:

5*. Андый саннар күп. Укучылар нинди дә булса сан язсыннар, мәсәлән, 12; ул 3 кә дә, 4 кә дә, һәм 6 га бүленә. Әгәр вакыт калса, укучыларга башка саннар да уйларга һәм язарга тәкъдим итәргә мөмкин (24, 48 һ.б.).

6*. Мондый ялгыш булуы мөмкин: 2 · 3 = 6, чөнки формасы буенча мәсьәлә балалар тапкырлау ярдәмендә чишә торган мәсьәләләргә охшаш. Дөрес җавап: 3 партия. Саныйбыз: беренче уенчы икенче белән һәм өченче белән уйнаган — бу 2 партия: икенче уенчы өченче белән уйнаган — бер партия, барысы өч партия, монда һәр уенчы 2 партия уйнаган булып чыга.

## Вариант 3

1. Җавапларны языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 • 7 = | 2 • 3 = | 24 : 4 = | 36 : 6= |
| 5·6= | 8·9= | 7 : 7 = | 25 : 5= |
| 9.4 = | 9 · 6 = | 54 : 9 = | 72 : 8= |
| 8 • 8 = | 2 · 5 = | 28 : 7 = | 18 : 9= |

2. 3 тартманың һәркайсына 6 шар уенчык салганнар. Тартмаларга ничә уенчык салганнар?

3.Һәр күлмәккә 4 әр төймә тагарга кирәк. 12 төймә ничә күлмәккә җитәр?

4. Кирәкле гамәлләрне башкарып, язманы тәмамлагыз:
   28 саны 4 тән ... кә зуррак
   28 саны 4 тән ... тапкырга зуррак
   3 саны 21 дән ... гә кечерәк
   3 саны 21 дән ... тапкырга кечерәк.

5*. Өстәл өстендә 12 шакмак бар. Аларны зур тартмаларга 6 шар данә итеп яки кечкенә тартмаларга 3 әр данә итеп куярга була. Бу шакмакларны урнаштыру өчен, ничә һәм нинди тартмалар алырга мөмкин?

6*. Табиб Маратка дарулар язган.Ул аларны һәр көнне 3 әр таблеткадан 7 көн эчәргә тиеш. Табиб рецепты буенча әнисе сатып алган 50 таблетка дару Маратка җитәрме?

Искәрмәләр:

5*. Укучылар барлык мөмкинлекләрне табарга тиешле: 2 зур тартма, 4 кечкенә тартма. Җавапны язу формасы ирекле.

6*. Күпчелек балалар андый төр мәсьәләләрне дөрес чишмиләр. Мәсәлән, болай: «3-7 = 21. Җавап: 21» яки болай: «3- 7 = 21. 50 - 21 = 29. Җавап: 29». Бу саннарның берсе дә мәсьәләнең соравына җавап була алмый. 3 • 7 = 21 гамәлен эшләгәннән соң, чишүнең киләсе этабы булып 50 һәм 21 саннарын чагыштыру тора, ул 21 язмасы белән бирелергә тиеш. Шулай итеп, бу мәсьәлә чишелешенең тулы язмасын китерәбез: 1) 3 • 7 = 21; 2) 50 > 21. Җавап: Җитә.

**Вариант 4**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7• 4 = | 9 • 9 = | 14 : 2 = | 49 : 7 = |
| 3 • 8 = | 8 • 7 = | 40 : 5 = | 4 : 4= |
| 5 • 9 = | 7. • 6 = | 81 : 9 = | 48 : 6= |
| 4 - 6 = | 9 • 4 = | 35 : 7 = | 20 : 4= |

2. Бертөрле 9 банкада 3 әр кг маринадланган кыяр бар. Бу банкаларда барлыгы ничә килограмм кыяр булган?
3. 12 м озынлыктагы тактаны тигез озынлыктагы кисәкләргә кискәннәр. Әгәр һәр кисәкнең озынлыгы 4 м булса, тактаны ничә кисәккә кискәннәр?
4. Кирәкле гамәлләрне башкарып, язманы эшләп бетерегез:
   12 саны 6 дан ... га зуррак
   12 саны 6 дан ... тапкырга зуррак
   5 саны 20 дән ... тапкырга кечерәк
   5 саны 20 дән ... кә кечерәк

5*. Абыйсы белән сеңлесе урманда бер үк кадәр гөмбә тапканнар. Өйгә кайтканда, абыйсы бер гөмбәсен сеңлесенә биргән. Абыйсыныкына караганда сеңлесенең гөмбәсе ничәгә артыграк була?

6*. 12 м озынлыгындагы шнурны бертигез озынлыктагы 3 кисәккә кискәннәр. Моны эшләү өчен ничә киселеш ясарга туры килгән?

Искәрмәләр:

5*. Мәсьәлә беренче карашка бик гади тоелса да, чынлыкта алай түгел. Балаларның күбесе сеңлесендә абыйсындагыга караганда 1 гөмбәгә күбрәк дип чишәрләр. Чынлыкта ул алай түгел. Абыйсы үзенең бер гөмбәсен алгач, сеңлесенең абыйсы кәрзинендә калгандагыдан 1 гә артыграк гөмбәсе була. Әлеге гөмбәсен абыйсы сеңлесенә биргәч, сеңлесенең абыйсыныкына караганда гөмбәләре 2 гә артыграк була.

Киләсе дәрестә укытучы ул эшләрне тикшереп балаларга кайтаргач, бу мәсьәләгә кире кайтырга һәм аның чишелешен конкрет саннар өстендә күрсәтергә була. Мәсәлән, сеңлесе һәм абыйсының 7 шәр гөмбәләре булсын. Абыйсында 6 гөмбә кала (7 - 1 = 6), ә сеңлесендә 8 гөмбә була (7 + 1 = 8), ягъни абыйсыныкыннан 2 гөмбәгә артыграк. Нинди генә саннар алсак та, сеңлесенең һәрвакыт 2 гөмбәгә артыграк булыр.

6*. Укучыларның кайберләре бу мәсьәләне нәрсәнедер тигез кисәкләргә бүләргә кирәк булган мәсьәләләрдәге кебек итеп чишеп куюлары мөмкин, ягъни мондый чишелеш язарлар: 12 : 3 = 4. Чишелеш дөрес түгел. 2 киселеш ясарга кирәклеген аңлау кыен түгел, 3 не түгел; бүлү гамәле биредә урынсыз. Укучы җавапны гына язса, мәсьәләне чишелгән дип санарга була: 2 киселеш (нигезләүсез).

## Вариант 5

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 • 7 = | 7 • 9 = | 40 : 5 = | 42 : 7= |
| 9·8= | 6·4= | 16 : 4 = | 20 : 5= |
| 7 • 7 = | 8 • 7 = | 63 : 9 = | 64 : 8= |
| 5 • 6 = | 6 • 8 = | 56 : 8 = | 32 : 8= |

2. Бер тәрәзәгә пәрдә тегү өчен, 6 м тукыма кирәк. Квартирда бертөрле 3 тәрәзә бар. Барлык тәрәзә өчен күпме тукыма киткән?
3. Картиналар галереясы залында бер рәттә 2 шәр картинадан 8 картина элгәннәр. Картиналар ничә рәтне биләп торалар?
4. Түбәндәге санны языгыз:
   1) 12 дән 3 тапкырга кечерәк,
   2) 20 дән 5 кә зуррак,
   3) 8 дән 4 тапкырга зуррак,
   4) 15 тән 3 кә кимрәк.

5*. Кәрзиндә пакеттагыга караганда 8 помидорга артыграк. Кәрзиндә дә, пакетта да помидорлар бертигез булсын өчен, кәрзиннән пакетка ничә помидор алып салырга кирәк?

6*. Парлап кисешерлек итеп, линейка буенча өч сызык үткәрегез. Рәсемдә килеп чыккан өчпочмакны буягыз.

Искәрмә:

5*. Җавап: 4 помидор.

## Вариант 6

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 • 7 = | 5 • 9 = | 36 : 9 = | 35 : 7= |
| 9 • 6 = | 4 • 8 = | 20 : 5 = | 8 : 8= |
| 8 • 5 = | 9 • 7 = | 42 : 6 = | 63 : 9= |
| 3 • 7 = | 7 • 6 = | 48 : 8 = | 24 : 4= |

2. Һәр төсле тасманың озынлыгы 5 м. Кызыл, яшел һәм сары тасмалар сатып алганнар. Ничә метр тасма сатып алганнар?
3. Альбомның һәр битенә 4 фоторәсем ябыштырганнар. 8 фоторәсем альбомның ничә битен биләп тора?
4. Түбәндәге санны языгыз:
   1) 7 дән 14 кә зуррак,
   2) 7 дән 3 тапкырга зуррак,
   3) 18 дән 2 тапкырга кечерәк,
   4) 18 дән 2 гә кечерәк.

5*. Талия белән Алиянең конфетлары бертигез. Талия 2 конфетын ашагач, кызларның икесенә бергә 10 конфет калган. Кызларның һәркайсының башта ничәшәр конфеты булган?

6*. Икесенең бер уртак ноктасы булырлык итеп, ике кисемтә сурәтләгез. Барлык очракларны карагыз.

Искәрмәләр:

5*. Талия 2 конфетын ашаганчы, кызларның икесенә бергә 12 конфет (10 + 2 = 12) булган, ягъни 6 шар (12 : 2 = 6). Җавап: 6.

6*. Җавап: (15 нче рәсемне карагыз).

III ЧИРЕК

## «Берурынлы саннарны тапкырлау таблицасы» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның тапкырлау таблицасын үзләштерүләренең ныклыгын тикшерү.

### Вариант 1

1. Нәтиҗәләрен языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 • 3 = | 4 • 3 = | 7 • 2 = | 8■ 4= |
| 5 • 8 = | 0 • 7 = | 9 • 3 = | 5 • 9= |
| 5 • 2 = | 8 • 6 = | 9 • 4 = | 7 • 6= |
| 3 • 3 = | 2 • 2 = | 6 • 6 = | 8 • 5= |
| 9 • 7= | 9 • 5 = | 2 • 9 = | 9 • 9= |
| 4 • 2 = | 5 • 3 = | 4 • 7 = | 2 • 6= |

2*. Тигезлек дөрес булсын өчен, квадрат эчендә нинди сан язарга кирәк?

$$5\cdot\prod = 5.$$

3*. Өч малай ике көпчәкле һәм өч көпчәкле велосипедларда йөриләр. Барлык велосипедларда 7 көпчәк булган. Ничә ике көпчәкле һәм ничә өч көпчәкле велосипед булган?

Искәрмәләр:

2*. Җавап: 1.

3*. Мәсьәлә сайлап алу юлы белән чишелә. Җавап: 2 ике көпчәкле һәм 1 өч көпчәкле велосипед.

## Вариант 2

1. Нәтиҗәләрен языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 • 4 = | 3 • 5 = | 2 • 9 = | 7 • 5 = |
| 0 • 2 = | 2 • 8 = | 4 • 1 = | 3 • 9 = |
| 9 • 6 = | 3 · 2 = | 3 • 8 = | 4 • 5= |
| 6 • 7 = | 5 · 5 = | 7 • 3 = | 3 • 3= |
| 8 • 3 = | 7 · 9 = | 2 • 6 = | 6 • 8= |
| 4 • 4 = | 6 · 4 = | 5 • 4 = | 8 • 7= |

2*. Тигезлек дөрес булсын өчен, квадрат эченә нинди сан язарга кирәк:

7·□=0?

3*. 8 см озынлыктагы кадакны, тактаның бер ягыннан 2 см, ә икенче ягыннан 1 см чыгарлык итеп, тактага какканнар. Тактаның калынлыгын табыгыз.

Искәрмәләр:

2*. Җавап: 0.

3*. Чишү: 2 + 1 = 3. 8 - 3 = 5. Җавап: 5 см.

## Вариант 3

1. Нәтиҗәләрен языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 • 5 = | 6 • 3 = | 3 • 4 = | 7 • 5 = |
| 8 • 7 = | 5 • 4 = | 9 • 9 = | 2 • 2= |
| 5 • 9 = | 9 • 2 = | 5 • 3 = | 5 • 5= |
| 4 • 8 = | 7 • 6 = | 7 • 7 = | 2 • 8 = |
| 6 • 6 = | 5 • 0 = | 5 • 1 = | 1 • 1= |
| 7 • 9 = | 4 • 9 = | 8 • 3 = | 4 • 7= |

2*. Ике бәйләмдә 20 суган. Бәйләмнең берсеннән 5 суганны алгач, анда 7 суган калган. Икенче бәйләмдә ничә суган?

3*. Саннарның суммасы аларның тапкырчыгышына тигез була аламы? Тигезлекне языгыз.

Искәрмәләр:

2*. Чишү: 5 + 7 = 12, 20 - 12 = 8. Җавап: 8.

3*. Җавап: Була ала. 2 + 2 = 2 • 2.

## Вариант 4

Нәтиҗәләрен языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 • 8 = | 6 • 4 = | 1 • 0 = | 3 • 4= |
| 5 • 9 = | 9 • 5 = | 5 • 5 = | 7 • 7= |
| 8 • 7 = | 5 • 4 = | 8 • 4 = | 8 • 1= |
| 9 • 9 = | 3 • 0 = | 7 • 5 = | 6 • 7= |
| 2 • 8 = | 8 • 6 = | 6 • 9 = | 3 • 9= |
| 5 • 6 = | 4 • 3 = | 9 • 8 = | 8 • 8= |

2*. 0 • 1 • 2 · 3 • 4 тапкырчыгышы нәрсәгә тигез?

3*. 16 нчы рәсемдә ничә дүртпочмак бар? Сайлап алыгыз һәм дөрес языгыз:
1) 1; 2) 2; 3) 3; 4)4.

Искәрмәләр:

2*. Җавап: 0.

3*. Җавап: 3.

## Вариант 5

1. Нәтиҗәләрен языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 • 5= | 0 • 1 = | 5 • 5 = | 0 • 0= |
| 9 • 8= | 7 • 7 = | 9 • 9 = | 7 • 9= |
| 2 • 7= | 6 • 9 = | 5 • 8 = | 8 • 9= |
| 0 • 5= | 8 • 8 = | 3 • 9 = | 4 • 4= |
| 6 • 7= | 5 • 3 = | 4 • 3 = | 5 • 6= |
| 4 • 5= | 7 • 4 = | 9 • 1 = | 8 • 5= |

2* Бауда 5 төен төйнәгәннәр. Һәр ике күрше төен арасындагы ераклык 1 дм. Кырый төеннәр арасындагы ераклык күпмегә тигез?

3*. Баскычта 15 басма бар. Баскычның нәкъ уртасында булу өчен, ничәнче басмага күтәрелергә кирәк?

Искәрмәләр:

2*. Җавап: 4 дм.

3*. Җавап: Сигезенчегә.

## Вариант 6

1. Нәтиҗәләрен языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. 9 = | 0 • 0= | 7• 2 = | 8 • 7 = |
| 4 • 0 = | 6 • 5 = | 9 • 6 = | 7 • 4= |
| 3 • 8 = | 9 • 8 = | 8 • 8 = | 4 • 5= |
| 2 • 7 = | 9 • 9 = | 3 ■7= | 3 • 9 = |
| 6 • 6 = | 4 • 4 = | 8 • 6 = | 9 • 7= |
| 7 • 7 = | 6 • 7 = | 1 • 5 = | 5 • 5= |

2*. 17 нче рәсемдә ничә дүртпочмак рәсеме сурәтләнгән?

3*. 5 цифрын языгыз. Табылган сан 6 га бүленсен өчен, 5 санының уң ягына нинди сан язарга кирәк?

Искәрмәләр:

*2**. Җавап: 6.

3*. Җавап: 4.

## «Тапкырга зуррак» һәм «тапкырга кечерәк» бәйләнешләрен эченә алган мәсьәләләрне чишү темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның саннарны берничә тапкырга һәм берничә берәмлеккә арттыруга, саннарны аермалы һәм кабатлы чагыштыруга мәсьәләләр чишә белүләрен тикшерү.

### Вариант 1

1. Букетта кызыл розалар 20, ә аклары кызылларыннан 4 тапкырга кимрәк. Ак розалар ничә? Алар кызыллардан ничәгә кимрәк?
2. Кадриянең 9 значогы бар, ә Фәритнең значоклары 3 тапкырга кимрәк. Фәритнең значоклары ничә?
3. Зоология бакчасында 16 ташбака һәм 8 елан яши. Еланнар ташбакалардан ничә тапкырга кимрәк?

4* Үлчәүнең бер тәлинкәсендә карбыз, ә икенчесендә бертөрле 6 әфлисун. Үлчәүләр тигезләнеш торышында. Әфлисун карбыздан ничә тапкырга җиңелрәк?

5*. 18 нче рәсемдә ничә дүртпочмак бар?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: 6 тапкыр.

5*. Җавап: 3.

### Вариант 2

1. Пакетка — 6, ә сумкага пакеттагыдан 3 тапкырга артыграк шалкан салганнар. Сумкага ничә шалкан салганнар? Сумкага пакетка караганда ничә шалканга артыграк салганнар?
2. Кондитер фабрикасында 12 бисквит торты һәм 6 чәкчәк ясаганнар. Чәкчәкне бисквит тортына караганда ничә тапкырга кимрәк хәзерләгәннәр?
3. 8 кг җиләк-җимеш һәм 2 тапкырга кимрәк яшелчә сатып алганнар. Ничә килограмм яшелчә сатып алганнар?

4*. Каенлы авылыннан Наратлы авылына 2 юл, Наратлыдан Урманлы авылына 3 юл бара. Каенлыдан Наратлы аша Урманлыга ничек барып була? Андый юллар ничә? (рәс. 19.)

5*. Кәгазь битендә 10 нан зур булмаган, ләкин 10 нан кечкенә дә булмаган сан язганнар. Ул нинди сан икән?

Искәрмәләр:

4*. Чишелеш: $2 \cdot 3 = 6$. Җавап: 6 юл.

5*. Җавап: 10.

**Вариант 3**

1. Тупыл агачының биеклеге 18 м. Миләш аннан 2 тапкырга тәбәнәгрәк. Миләшнең биеклеген табыгыз. Тупыл миләштән ничә метрга биегрәк?
2. Балалар бакчасында иртәнге ашка йомырка биргәннәр: каты итеп 8 йомырка, ә пешәр-пешмәс итеп 2 тапкырга артыграк пешергәннәр. Ничә йомырканы пешәр-пешмәс итеп пешергәннәр?
3. Залга 4 яңа өстәл һәм 28 урындык куйганнар. Урындыкларны өстәлләргә караганда ничә тапкырга артыграк куйганнар?

4*. Сыйныфта 31 укучы. Барлык укучыларны парталарга утыртып бетерү өчен, икеурынлы ничә парта кирәк?

5*. Тартмада 5 ак һәм 3 кара шакмак ята. Тартмага карамыйча, алар арасында һич югы бер кара шакмак булырлык итеп, шакмакның нинди иң аз санын алырга кирәк?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: 16.

5*. Җавап: 6.

**Вариант 4**

1. Кадриягә 8.яшь, аның абыйсы Сәлим Кадриядән 3 тапкыр зуррак. Кадрия абыйсыннан ничә яшькә кечерәк?
2. Турист өйдән күлгә кадәр велосипедта 24 мин барган, ә күлдән урманга бару өчен аның вакыты 3 тапкырга кимрәк киткән. Күлдән урманга бару өчен күпме вакыт киткән?
3. Рәссам 12 портрет һәм 6 пейзаж ясаган. Пейзажны ул портретларга караганда ничә тапкырга кимрәк ясаган?

4*. Әгәр әйбернең бәясе 70 сум торса, нинди иң аз сандагы тәңкә акчалар белән (кайтарып бирмичә) әйберне түләп алырга була?

5* . Ике санның суммасы нульгә тәмамлана. Кушылучылар нинди цифрга тәмамланырга мөмкин?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: ике тәңкә акча белән: 50 сум һәм 20 сум.

5*. Җавап: 0 һәм 0, 1 һәм 9, 2 һәм 8, 3 һәм 7, 4 һәм 6, 5 һәм 5.

**Вариант 5**

1. Сукмактан буага үрдәкләр һәм үрдәк бәбкәләре килә. Һәр үрдәккә 4 әр бәбкә туры килә. Үрдәкләр бәбкәләрдән ничә тапкыр кимрәк?
2. Әтисенә 42 яшь, улы әтисеннән 3 тапкыр кечерәк. Улына ничә яшь? Әтисе улыннан ничә яшькә зуррак?

3. 2 кг ромашка чәчәкләре һәм аннан 3 тапкырга артыграк юкә чәчәкләре киптергәннәр. Ничә килограмм юкә чәчәкләре киптергәннәр?
4*. Әгәр ике так санны кушсаң, так сан килеп чыга дип әйтә Илдар. Бу дөресме? Кире кага торган мисал китерегез.
5*. Бүген көндезге 12 сәг тә Мәскәүдә яңгыр ява. 14 сәг тән соң кояшлы көн көтеп буламы? Җавапны аңлатыгыз.

Искәрмәләр:

4*. Җавап: Дөрес түгел. Мәсәлән, 5 + 7 = 12. 12 — җөп сан.
5*. Җавап. Юк. Мәскәүдә төнге 2 сәг була.

## Вариант 6

1. Чынаякка 1 чәй кашыгы кофе һәм 2 кашык песок салганнар. Песокны кофедан ничә тапкырга артыграк салганнар?
2. Колганы буага 20 дм га батырганнар. Колганың су өстендә калган өлеше су астындагы өлешеннән 4 тапкырга озынрак. Колганың суга батырылмаган өлешенең озынлыгын табыгыз.
3. Стеналарны буяу өчен, 6 банка буяу һәм берничә банка эмаль алганнар. Эмаль ак буяудан 2 тапкырга кимрәк тотылган. Ничә банка эмаль тотылган?
4*. Җөп һәм так саннарның суммасы нинди сан була: җөпме яки такмы? Җавапларның берсен сайлап алыгыз һәм аны языгыз. Әгәр мөмкин булса, аны нигезләү өчен мисал китерегез. Җавап: 1) Җөп. 2) Так. 3) Белмим.
5*. Килеп чыккан аңлатманың кыйммәте 42 гә тигез булырлык итеп, 6 5 2 язмасында гамәл тамгаларын һәм җәяләрне куегыз. Тигезлекне языгыз.

Искәрмәләр:

4*. Җавап: Так, мәсәлән, 5 + 4 = 9.
5*. Җавап: 6 • (5 + 2) = 42.

## III чиреккә контроль эш

Эшнең максаты укучыларның, арифметик гамәлләр башкарып (кушу, алу, тапкырлау, бүлү), катлаулы булмаган төзелмә мәсьәләләр чишә белүләрен, өйрәнелгән алымнардан файдаланып, таблицадан башка тапкырлау һәм бүлүне башкаруларын, аерым алганда, сумманы санга тапкырлау (бүлүне) белүне, бүлгәндә 0 һәм 1 нең үзлекләрен белүне, турыпочмаклыкның яклары озынлыкларының суммасын таба белүләрен тикшерүдән гыйбарәт.

**Вариант 1**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 17 • 3 = | 68 : 4 = | 7 : 7= |
| 21 • 4 = | 93 : 3 = | 0 : 1 = |
| 8 • 10= | 100 : 4 = | 0 : 9= |
| 36 • 2 = | 80 : 40 = | 3 : 1= |

2. Һәркайсында 7 шәр м булган 2 кисәк йон тукыма һәм 15 м эчлек тукыма сатып алганнар. Барлыгы ничә метр тукыма сатып алганнар?
3. Ягы 5 см булган квадрат сызыгыз. Аның яклары озынлыгының суммасын табыгыз.

4*. Һәр костюмга 8 әр төймә тагарга кирәк. Тартмада 25 төймә. Бу төймәләр ничә костюмга җитә?

5*. Электр поезды 18 вагоннан тора. Алсу белән Фаил алдан сөйләшеп куялар. Алсу поездның башыннан санаганда тугызынчы вагонга, ә Фаил ахырдан тугызынчы вагонга утырырга сөйләшәләр. Алар бер вагонда барырлармы?

Искәрмәләр:

4*. Мәсьәләне чишү өчен калдыклы бүлүне кулланабыз: 25 : 8 = 3 (калд. 1). Җавап: Өч костюмга.

5*. Баштан тугызынчы вагон һәм ахырдан тугызынчы вагон — төрле вагоннар. Җавап: Юк.

**Вариант 2**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 16 • 4 = | 80 :20= | 0 : 7= |
| 9· 11= | 96 :3 = | 6 : 6= |
| 30 • 2 = | 70 :5 = | 1 : 1= |
| 32 • 3 = | 64 :4 = | 0 : 1= |

2. Бабайга 48 яшь, оныгы Алмаз бабасыннан 8 тапкыр кечерәк, ә Алмазның әнисе Алмаздан 4 тапкырга зуррак. Әнисенә ничә яшь?
3. Яклары 4 см һәм 3 см булган турыпочмаклык сызыгыз. Аның барлык якларының суммасын табыгыз.

4*. Һәр ящикка эченә курчак салынган 8 тартма сыя. Шундый 75 тартманы урнаштыру өчен, ничә ящик кирәк булыр?

5*. Һәр балалар велосипеды өчен 1 зур һәм 2 кечкенә тәгәрмәч кирәк. 12 кечкенә һәм 7 зур тәгәрмәч әзерләгәннәр. Ул тәгәрмәчләрдән ничә велосипед җыеп була?

Искәрмәләр:

4*. Чишү: 75 : 8 = 9 (калд. 3). Барысы 9 + 1 = 10 ящик кирәк.
5*. Ике ысул белән фикер йөртергә мөмкин: 1. 7 зур тәгәрмәч булганлыктан, алар 7 велосипедка җитә. Ул вакытта кечкенә тәгәрмәчләр 14 кирәк булачак. Ләкин алар 12, ике тәгәрмәч җитми. 6 ны тикшерәбез. Табабыз: 6 • 2 = 12. Төп-төгәл. Димәк, 6 велосипед җыеп була. 2. Кечкенә тәгәрмәчләр 6 велосипедка җитә (12 : 2 = 6), зур тәгәрмәчләр 7. Димәк, 6 велосипед өчен алар җитә. Җавап: 6.

## Вариант 3

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 12 • 8 = | 100 : 5 = | 7 : 1= |
| 4 • 20= | 36 : 3 = | 0 : 1= |
| 16 • 3 = | 60 : 5 = | 1 : 1= |
| 24 • 4 = | 54 : 4 = | 9 : 9= |

2. 27 кг абрикос вареньесын 9 банкага тигез итеп бүлеп салганнар. 8 банкага ничә килограмм варенье салганнар?
3. Квадратның барлык яклары озынлыгының суммасы 12 см га тигез. Бу квадратны сызыгыз.
4*. Сыйныф бүлмәсендә икеурынлы 18 парта бар. Исемлек буенча бу сыйныфта 35 укучы. Әгәр барлык укучы да килсә, буш урыннар калырмы?
5*. 70 л сөтне 20 литрлы бидоннарга салып, алып барырга кирәк. Моның өчен иң аз санда ничә бидон кирәк булыр?

И с к ә р м ә л ә р:

4*. Ихтимал, кайбер балалар төгәл яки дөрес булмаган җаваплар бирерләр. Мәсәлән, «36 урын» яки «Бер урын кала». 36 санының мәсьәлә җавабына бернинди катнашы юк. Чишү: 1) 2 • 18 = 36. 2) 35 < 36. Җавап: Юк.
5*. Практика күрсәткәнчә, кайбер балалар, 70 : 20 = 3 (калд. 10) калдыклы бүлүен эшләп, мәсьәләнең соравына ялгыш яки төгәл булмаган җавап бирәләр, мәсәлән: «3 бидон» яки: «3 бидон һәм 10 л кала», яки «3 бидон һәм 10 л дүртенче бидонда». Дөрес җавап: 4 бидон.

**Вариант 4**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 46 • 2 | 86 : 2 | 4 :4 |
| 5 • 20 | 60 : 30 | 10 : 1 |
| 19 • 4 | 78 : 6 | 0 :8 |
| 27· 3 | 51 : 3 | 1 :1 |

2. Бер түтәлдән 12 кыяр, әикенчесеннән 15 кыяр җыеп алганнар. Барлык кыярны, тигезләп, 3 пакетка тутырганнар. Һәр пакетка ничә кыяр салганнар?
3. Турыпочмаклыкның бер ягының озынлыгы 3 см, икенче ягы 2 тапкырга зуррак. Бу турыпочмаклыкны сызыгыз һәм аның барлык яклары озынлыгының суммасын табыгыз.

4*. Хуҗалыкта 80 тавык. Тавыклар үрдәкләргә караганда 2 тапкырга күбрәк, ә үрдәкләр казларга караганда 2 тапкырга күбрәк. Казлар ничә?

5*. Бабайның 34 конфеты булган. Ул аларны, һәркайсына 6 шар конфет тиярлек итеп, үзенең оныкларына бүлеп бирә, һәм үзендә 4 конфет калган. Бабайның ничә оныгы бар?

Искәрмәләр:

4*. Чишү: 80 : 2 = 40, 40 : 2 = 20. Җавап: 20.

5*. Чишү: 34 - 4 = 30. 30 : 6 = 5. Җавап: 5 онык.

**Вариант 5**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 37 • 2 | 93 : 3 | 0 : 4 |
| 18 • 4 | 72 : 6 | 8 : 8 |
| 3 • 30 | 60 :20 | 0 : 1 |
| 29 • 3 | 50 :2 | 1 : 1 |

2. Ларекта һәркайсы 8 әр кг лы 15 ящик банан булган. Бер көндә 9 ящигы сатылган. Ничә килограмм банан калган?
3. Турыпочмаклыкның ике зур ягының суммасы 8 см, ә кечкенә ягынын; озынлыгы 2 см. Турыпочмаклыкның барлык яклары озынлыгы суммасын табыгыз.

4*. Мүк җиләгеннән варенье кайнатканнар. Бу вакытта һәр 2 стакан җиләккә 3 стакан шикәр комы алганнар. Әгәр 12 стакан шикәр комы алынган булса, варенье өчен ничә стакан җиләк алганнар?

5*. Өске киштәдә 3, ә аскысында 2 китап бар. Аскы киштәдә китаплар өске киштәдәгедән 2 тапкырга артыграк булсын өчен, аскы киштәгә ничә китап куярга кирәк?

Искәрмәләр:

4*. Чишү: 12 : 3 = *4,* 4 • 2 = 8. Җавап: 8.

5*. Аскы киштәдә 6 китап булырга тиеш (3 • 2 = 6). Ләкин анда инде 2 китап бар. Димәк, аскы киштәгә тагын 4 китап куярга кирәк ( 6 - 2 = 4). Җавап: 4 китап.

## Вариант 6

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 18 • 5 | 48 : 4 | 0 :7 |
| 24 • 3 | 100 :20 | 1:1 |
| 9•10 | 80 :5 | 0:1 |
| 48 • 2 | 78 : 3 | 8 :1 |

2. 20 кг шикәр сатып алганнар. 6 кг нан варенье кайнатканнар, ә калганын 2 шәр кг итеп пакетларга тутырганнар. Ничә пакет килеп чыккан?
3. Турыпочмаклыкның тигез булмаган якларының суммасы 15 см. Моны белеп, бу турыпочмаклыкның барлык яклары озынлыгының суммасын табып буламы? Ничек?

4*. Өстәл өстенә зәңгәр, кызыл һәм яшел төстәге 3 ваза куйганнар. Һәр вазада һич югы бер груша булырлык итеп, 6 грушаны бу вазаларга таратып чыгарга кирәк. Моны ничек эшләргә була?

5*. Тартмада кызыл һәм яшел җепле кәтүкләр ята. Алган кәтүкләр арасыннан 2 кәтүк җеп бер үк төсле булсын өчен, тартмадан иң аз санда ничә кәтүк алырга кирәк?

Искәрмәләр:

*4*.* Грушаларны вазаларга 10 төрле ысул белән таратып куярга була. Ихтимал, балалар таратуның барлык ысулларын да табып яза алмаслар. Берничә ысул тапсалар да ярый, ләкин икедән ким булмасын. Укытучы өчен барлык ысулларны китерәбез: (1, 1, 4), (1, 4, 1), (1, 2, 3), (1, 3, 2), (2, 1, 3), (2, 3, 1), (2, 2, 2,), (3, 1, 2), (3, 2, 1), (4, 1, 1).

5*. Җавап: 3 кәтүк. Алган кәтүкләр арасында 1 яшел һәм 2 кызыл (димәк, бер төстәге ике кәтүк бар) яки 1 кызыл һәм 2 яшел (яңадан бер төстәге 2 кәтүк бар) кәтүк булуы мөмкин һәм, ниһаять, алган кәтүкнең өчесе дә яшел яки барлык өчесе дә кызыл (бу очракларның һәркайсында бер үк төстәге 2 кәтүк бар).

Башкача да фикер йөртеп була. Начаррак очракны карыйк: 2 кәтүк алганнар, һәм алар төрле төстә булып чыкканнар. Ул вакытта тагын бер кәтүк алсаң, ул я яшел, я кызыл төстә була. Һәм алган 3 кәтүк арасында бертөрле төстәге 2 кәтүк әлбәттә булачак.

## IV чиреккә контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның 1000 эчендә саннарны язып куша һәм ала белүләрен, 3 арифметик гамәлне эченә алган санлы аңлатмаларның (җәяләр белән һәм җәяләрсез) кыйммәтләрен таба белүләрен, зурлыклар арасындагы өйрәнелгән бәйләнешләрне эченә алган төзелмә арифметик мәсьәләләрне чишә белүләрен тикшерү.

### Вариант 1

1. Гамәлләрне эшләгез:

$\begin{array}{r} 45 \\ +\ 79 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 136 \\ +\ 418 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 225 \\ +\ 694 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 347 \\ +\ 143 \\ \hline \end{array}$

$\begin{array}{r} 682 \\ -\ 453 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 307 \\ -\ 156 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 416 \\ -\ 237 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 900 \\ -\ 354 \\ \hline \end{array}$

2. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

а) (62 + 8) : 7 + 3; б) 40 - 32 : 8 : 2.

3. Яшелчә базасында һәркайсында 3 әр кг булган 20 пакет бәрәңге һәм 2шәркг лы 15пакет кишер хәзерләгәннәр. Барлык пакетларда бергә ничә килограмм яшелчә?

4*. 1 һәм 0 цифрлары ярдәмендә барлык өчурынлы саннарны языгыз.

5*. 20 нче рәсемдә ничә турыпочмаклык сурәтләнгән?

Искәрмәләр:
4*. Җавап: 100, 101, 110,111.
5*. Җавап: 6.

### Вариант 2

1. Гамәлләрне эшләгез:

$\begin{array}{r} 37 \\ +\ 78 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 156 \\ +\ 249 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 461 \\ +\ 344 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 278 \\ +\ 356 \\ \hline \end{array}$

$\begin{array}{r} 580 \\ -\ 127 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 428 \\ -\ 165 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 836 \\ -\ 258 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 700 \\ -\ 276 \\ \hline \end{array}$

2. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

а) 30 : (10 - 4) + 6; б) 35 : 7 + 3 • 4.

3. Бакчадан 20 кыяр, аннан 4 тапкырга кимрәк помидор, ә кишерне кыяр белән помидорның икесе кадәр алып кергәннәр. Бакчадан ничә кишер алып кергәннәр?

4*. (18 : 3 : 3) : (18 : 3 : 3) аңлатмасының кыйммәте күпмегә тигез?

5*. Безнең сыйныфтагы һәр өченче укучы математика түгәрәгенә йөри. Әгәр түгәрәктә 12 кеше шөгыльләнсә, безнең сыйныфта ничә укучы?

Искәрмәләр:

4*. Бирелгән аңлатманың кыйммәтен табу өчен исәпләүләр эшләүнең бөтенләй кирәге юк: аңлатмага игътибар белән карасаң, аның кыйммәте 1 гә тигез икәнен шунда ук төшенәсең (бертөрле ике санның өлеше). Кайбер балаларның аңлатмада күрсәтелгән гамәлләрне эшли башлаулары мөмкин: 18 : 3 = 6, 6 : 3 = 2 һ.б. Сыйныфта шундый ничә укучы барлыгын санау кызыклы булыр. Эшләрне тикшергәч, укытучы алдагы дәрестә бу мәсьәләнең чишелешен бөтен сыйныф белән тикшерә ала.

5*. Чишү: 12 • 3 = 36. Җавап: 36.

## Вариант 3

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 48 + 84 | 621 + 197 | 597 - 398 | 458 - 239 |
| 316 + 278 | 258 + 469 | 500 - 273 | 604 - 132 |

2. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

а) 48 : 8 • 2 + 8; б) 20 + 40 : (10 - 5).

3. Китап 100 битле. Камил чәршәмбе көнне 15 бит, ә пәнҗешәмбе көнне 3 биткә кимрәк укыган. Камилгә бу китапның ничә битен укыйсы калган?

4*. Әгәр сан 2 гә һәм 3 кә бүленсә, ул сан һичшиксез аларның суммасына, ягъни 5 кә бүленергә тиеш дип уйлый Илсур. Бу фикерне кире кага торган мисаллар китерегез.

5*. Аллеяның озынлыгы 15 м. Аның ике башына да берәр юкә утыртканнар. Аннары тагын бер-береннән бер үк ераклыкта булган 2 юкә утыртканнар. Һәр ике күрше юкә арасы ничә метр?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: Дөрес түгел. Мисал: 6 саны 2 гә һәм 3 кә бүленә. Ләкин 6 саны 5 кә бүленми.

5*. Җавап: 5 м.

**Вариант 4**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 55 + 79 | 524 + 293 | 451 - 282 | 957 - 728 |
| 108 + 465 | 365 + 365 | 600 - 277 | 508 - 364 |

2. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

а) 43 - (13 + 7 • 2); б) 4 + 26 - 6 • 4.

3. Зоопаркта 3 арыслан бар, маймыллар арысланнардан 4 тапкырга күбрәк, ә арысланнар маймылларга караганда 2 гә күбрәк. Арысланнар ничә?

4*. Мәдинә, һәр дүртенчесе кызыл, ә калганнары ак булырлык итеп, 20 мәрҗәнне җепкә тезгән. Ничә кызыл һәм ничә ак мәрҗән?

5*. Һәр атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм шимбә көннәрендә Рәшит бассейнга йөри, ә калган көннәрдә ул «Оста куллар» түгәрәгенә йөри. Атнасына ничә көн ул түгәрәккә йөри?

Искәрмәләр:

4*. Чишү: 20 : 4 = 5, 20 - 5 = 15. Җавап: 5, 15.

5*. Җавап: 4.

**Вариант 5**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 78 + 56 | 463 + 494 | 427 - 136 | 361 - 234 |
| 245 + 27 | 86 + 275 | 800 - 614 | 509 - 347 |

2. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

а) 34 - 4 • (56 : 8); б) 64 + 36 - 6 • 8.

3. Кибет киштәсендә виноград согы салынган өч литрлы 8 банка һәм шулкадәр шундый ук банкаларда томат согы тора. Барлык банкаларда ничә литр сок бар?

4*. Үлчәүнең сул тәлинкәсендә карбыз ята, ә уң тәлинкәсендә — кавын һәм 1 әр кг лы 3 гер. Карбыз ничә килограммга авыррак?

5*. *AB* һәм *BC* кисемтәләренең озынлыклары суммада *AC* кисемтәсенең озынлыгын тәшкил итәләр (рәс. 21). *AC* кисемтәсенең озынлыгы 16 см га тигез. *AB* һәм *BC* кисемтәләре арасындагы ераклыкны табыгыз.

Искәрмәләр:

4*. 3 кг га.

5*. Чишү: 16 : 2 = 8. Җавап: 8 см.

**Вариант 6**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 64 + 36 | 237 + 82 | 593 - 96 | 686 - 207 |
| 136 + 529 | 58 + 196 | 300 - 154 | 713 - 522 |

2. Аңлатмаларның кыйммәтләрен табыгыз:

а) 25 + 5 • (41 - 38); б) 56 - 6 + 4 • 9.

3. Мәскәү заводы 600 суыткыч эшләп чыгарган. Бу суыткычлар санының бишенче өлешен Мәскәү өлкәсенә җибәргәннәр, ә калганнарын Мәскәүнең 6 кибетенә тигезләп бүлгәннәр. Һәр кибет ничә суыткыч алган?

4*. Үлчәүнең сул тәлинкәсендә 5 кг лы гер тора, ә уң тәлинкәсендә — 1 кг лы гер һәм бер пакет он. Сул тәлинкә уңны тарта. Әгәр уң тәлинкәгә тагын 2 кг лы гер куйсаң, үлчәү тигезләнеш торышына килә. Пакетта күпме он булган?

5*. Ике сан суммасының 5 кә бүленүе билгеле. Һәр кушылучының 5 кә бүленүе дөресме? Кире кага торган мисал китерегез.

Искәрмәләр:

4*. Җавап: 2 кг.
5*. Җавап: Дөрес түгел. Мәсәлән, 12 + 8 суммасы 5 кә бүленә, ләкин 12 дә, 8 дә 5 кә бүленмиләр.

## ӨЧЕНЧЕ СЫЙНЫФ

### I ЧИРЕК

### Кереш контроль эше

Эшнең максаты — укучыларның 2 нче сыйныф программасының төп сорауларын үзләштерүләренең ныклыгын тикшерү. Укучыларның тапкырлау таблицасын һәм бүлүнең тиешле очракларының нәтиҗәләрен белүләре; таблицадан тыш тапкырлау һәм бүлүне башкара белүләре, төзелмә санлы аңлатманың кыйммәтен таба белүләре, язып исәпләү алымнарыннан файдаланып, өчурынлы саннарны куша һәм ала белүләре, арифметик мәсьәләләр чишә белүләре, турыпочмаклыкның периметрын таба белүләре тикшерелә.

Беренче бирем өчен карточкалар хәзерләү максатка ярашлы.

## Вариант 1

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 • 7= | 2 •0= | 10 : 2 = | 72 : 8= |
| 8 • 4= | 6 •8 = | 30 : 6 = | 35 : 5= |
| 6 • 3= | 5· 4 = | 63 : 7 = | 20 : 4= |
| 9 • 9= | 9 •2 = | 0 : 8 = | 36 : 6= |
| 12 · 4= | 25·3 = | 100:5= | 48:12 = |

2. Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: 48 - (70 : 2 + 13)
3. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| +473 | +48 | +306 | +411 |
| 124 | 425 | 207 | 39 |
| _427 | _683 | _200 | _517 |
| 145 | 92 | 154 | 68 |

4. Бер пачка чәйнең массасы 50 г. Әни 4 пачка чәй һәм бераз казылык сатып алган. Барлык әйбернең массасы 700 г. Әни күпме казылык сатып алган?
5. 12 см озынлыктагы тимерчыбыкны квадрат формасындагы рамка килеп чыгарлык итеп бөкләгәннәр. Шул рамка ягының озынлыгын табыгыз.

6* . Наилә дүртурынлы сан язган, аннан 1 не алган, һәм өчурынлы сан килеп чыккан. Ул дүртурынлы санны языгыз.

7*. Театр гардеробында 1 — 250, 251 — 500, 501 — 750 номерлы табличкалар эленеп тора. Мәдинә пальтосын гардеробка тапшырган һәм 499 саны язылган номерок алган. Мәдинә үзенең пальтосын кайсы табличка яныннан алыр?

Искәрмәләр:

6*. Җавап: 1000.

7*. Бу эшне тәкъдим иткәндә, укытучы 1 — 250 язмасының алуны белдермәгәнен аңлата. Ул — 1 дән алып 250 гә кадәр (250 не дә кертеп) булган саннарны аңлата. Җавап: 251 — 500.

## Вариант 2

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 • 7 = | 8 • 6 = | 16 : 4 = | 0 : 4= |
| 7 • 8 = | 7 • 9 = | 18 : 3 = | 24 : 3= |
| 9 • 3 = | 5 • 4 = | 40 : 8 = | 63 : 9= |
| 5 • 0 = | 6 • 7 = | 81 : 9 = | 30 : 5= |
| 15 • 2 = | 24 • 3 = | 50 : 2 = | 51 : 17 = |

2. Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: 50 : 5 • 10 - 1.
3. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 228 | +64 | +507 | +444 |
| ±351 | 136 | 202 | 66 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| $\begin{array}{r}-928\\ \underline{617}\end{array}$ | $\begin{array}{r}-591\\ \underline{465}\end{array}$ | $\begin{array}{r}-235\\ \underline{88}\end{array}$ | $\begin{array}{r}-606\\ \underline{39}\end{array}$ |

4. 400 г кара кофе һәм 50 шәр г лы 3 пачка чәй сатып алганнар. Барлык сатып алган әйберләрнең массасын табыгыз.
5. Турыпочмаклык формасындагы эскәтернең кырыйларына тасма теккәннәр. Әгәр эскәтернең үлчәмнәре 2 м һәм 1 м 50 см булса, ничә метр тасма тотканнар?
6*. Мин әгәр сан 5 кә бүленсә, ул сан я 5 цифрына, я 0 цифрына тәмамлануын искәрттем. Бу дөресме? Моны раслаучы мисаллар китерегез.
7*. Нинди саннарның аермасы 49 га тигез? Буш шакмакларга кирәкле цифрларны языгыз һәм тулысынча язып бетерегез:

$$\begin{array}{r}-8\square\\ \underline{\triangle 2}\\ 49\end{array}$$

Искәрмә:

7*. Җавап: — $\begin{array}{r}81\\ \underline{32}\\ 49\end{array}$

**Вариант 3**

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 0 • 8 = | 6 • 9 = | 18 : 2 = | 27 : 3 = |
| 4 • 7 = | 5 • 5 = | 25 : 5 = | 0 : 7 = |
| 8 • 9 = | 4 • 0 = | 42 : 6 = | 20 : 4 = |
| 6 • 1 = | 7 • 7 = | 54 : 9 = | 56 : 8 = |
| 32 • 5 = | 17 • 4 = | 96 : 2 = | 56 : 14 = |

2. Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: 420 + 80 : 5 • 2.
3. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 421 + 268 | 524 - 113 | 503 + 208 | 762 - 682 |
| 54 + 336 | 438 - 29 | 267 + 489 | 901 - 476 |

4. Тамаша залында 200 кеше булган. Барлык тамашачыларның биштән бер өлеше — балалар. Залда ничә олы тамашачы булган?
5. Ягының озынлыгы 15 см га тигез булган квадрат формасындагы яулыкка челтәр тегү өчен, күпме челтәр кирәк булыр?
6*. Иртәнге сәгать 6 дан көндезге 12 гә кадәр һәм сәгать 12 дән икенче көнне сәгать 6 га кадәр ничә сәгать уза?

7*. Дамир һавада йөрергә уйлый һәм елганың сул як яры буйлап китә. Бу вакытта ул елганы 3 тапкыр үтеп чыга. Елганың сул ярында яки уң ярындамы ул килеп чыккан?

Искәрмәләр:

6*. Кайбер балаларга беренче карашкаалда сөйләнгән вакыт бер үк кебек тоелыр. Чынында исә беренче очракта 6 сәг, ә икенчесендә 18 сәг вакыт үтә.
7*. Җавап: уң як ярда.

## Вариант 4

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 • 0 = | 0 •3= | 12 : 4 = | 24 : 8 = |
| 1 • 7 = | 6 •6= | 48 : 6 = | 40 :5 = |
| 9 • 4 = | 5 •9= | 49 : 7 = | 27 : 3 = |
| 5 • 8 = | 7 •6= | 0 : 6 = | 64 : 8 = |
| 21 • 5 = | 40 •8= | 120 : 5 = | 98 : 49 = |

Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: 30 + 5 • (36 : 4).
Гамәлләрне эшләгез:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 153 + 234 | 204 + 305 | 428 - 305 | 558 - 467 |
| 28 + 187 | 374 + 487 | 289 - 146 | 802 - 54 |

4. 250 г маргарин һәм 750 г ак май сатып алганнар. Сатып алган әйберләрнең массасын табыгыз.
5. Әгәр квадратның бер ягының озынлыгы 8 м булса, квадрат якларының озынлыклары суммасын табыгыз.
6*. Фаиләгә иртән сәгать 9 да торырга кирәк. Кич белән сәгать 6 да ул,уяткычны сәгать 9 га куеп, йокларга ята. Күпме вакыттан соң уяткыч аны уятыр?
7*. Марат елгага килә, чишенеп суга керә һәм йөзеп китә. Ул, елганы 4 тапкыр йөзеп, ярга чыга. Ул киемнәре яткан ярга килеп чыкканмы?

Искәрмәләр:
6*. Уяткыч кичке сәгать 9да шалтырый, шулай итеп, ул Фаиләне 3 сәг тән соң уятыр.
7*. Җавап: Әйе.

## Вариант 5

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 • 6 = | 5 • 9 = | 15 : 3 = | 16 : 8= |
| 4 • 9 = | 9 • 3 = | 40 : 5 = | 27 : 9= |
| 7 • 7 = | 4 • 8 = | 24 : 8 = | 0 : 6= |
| 0 • 1 = | 6 • 7 = | 32 : 4 = | 42 : 7= |
| 18 • 9 = | 32 • 4 = | 150 : 75 = | 300 : 2 = |

2. Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: 12 • (32 - 28) : 2.
3. Саннарның суммасын һәм аермасын табыгыз:

| | |
|---|---|
| 437 һәм 186; | 810 һәм 95; |
| 169 һәм 71; | 536 һәм 464. |

4. 40 кг алманы тигез итеп 5 тартмага бүлеп салганнар һәм 3 сен балалар бакчасына илткәннәр. Балалар бакчасына ничә килограмм алма илткәннәр?
5. Квадратның барлык якларының суммасы 20 дм га тигез. Аның бер ягының озынлыгын табыгыз.
6*. Ике залда 50 урындык. Бер залдан икенчесенә 10 урындык чыгаргач, залларда урындыклар бертигез була. Һәр залда ничәшәр урындык булган?
7*. Әни белен пешергән. Кичке аш вакытында 12 беленне ашыйлар. Кичке аштан соң пешергән барлык беленнең өчтән бере калган. Әни ничә белен пешергән?

Искәрмәләр:

6*. Чишү: 1) 50 - 10 = 40. *2)* 40 : 2 = 20. 3) 20 + 10 = 30. Җавап: 20, 30.
7*. Болай фикер йөртергә була: 12 белен — пешергән барлык беленнең өчтән икесе. Димәк, барлык беленнең өчтән бере — ул 6 (12 : 2 = 6). Барлыгы 18 белен пешергәннәр (6 • 3 = 18). Җавап: 18.

## Вариант 6

1. Җавапларын языгыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 • 7 = | 9 • 7 = | 15 : 5 = | 28 : 4= |
| 6 • 5 = | 8 • 9 = | 40 : 8 = | 56 : 7= |
| 3 • 8 = | 6 • 0 = | 81 : 9 = | 36 : 4= |
| 5 • 4 = | 7 • 6 = | 24 : 6 = | 0 : 2= |
| 15 • 6 = | 44 • 3 = | 90 : 15 = | 190 : 2 = |

2. Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: 75 : (4 • 20 - 5).
3. Саннарның суммасын һәм аермасын табыгыз:

| | |
|---|---|
| 405 һәм 399; | 632 һәм 188; |
| 193 һәм 87; | 401 һәм 296. |

4. Хат ташучы безнең өйгә 24 журнал, журналлардан 3 тапкырга кимрәк хатлар, ә хатлардан 36 га артыграк газета китергән. Безнең өй кешеләре ничә газета алган?
5. Турыпочмаклык якларының озынлыклары 4 см һәм 6 см. Аның барлык якларының озынлыклары суммасын табыгыз.

6*. Үлчәүгә тары ярмасы салынган бер пакет һәм дөге салынган бер пакет куйганнар. Йөкнең массасы 5 кг була. Аннары, ул пакетларны алмыйча, үлчәүгә тары ярмасы салынган тагын бер пакет куйганнар. Үлчәүдә 8 кг ярма, булган. Пакетта ничә килограмм дөге булган?

7*. Юл буена 4 яңа багана утыртканнар. Һәр ике күрше багана арасы 5 м. Кырый баганалар бер-береннән нинди ераклыкта урнашканнар?

Искәрмәләр:

6*. Аерма тары ярмасы салынган пакет исәбенә килеп чыга. Димәк, пакетта тары ярмасы 3 кг. Чишү: 8 - 5 = 3 (кг), 5 - 3 = 2 (кг). Җавап: 2 кг.

7*. Укучылар ялгыш җибәрергә мөмкиннәр: 5 • 4 = 20. Чынлыкта кырый баганалар арасындагы ераклык 15 м га тигез (5 • 3 - 15).

## I чиреккә контроль эш

Эшнең максаты — өченче сыйныф укучыларының I чирек ахырына алган белем һәм осталыкларының сыйфатын тикшерү. Күбурынлы саннарны яза һәм чагыштыра белүләре; күбурынлы саннарны куша һәм ала белүләре; зурлыкларның берәмлекләре арасындагы бәйлелекне белүләре; шакмаклы кәгазь битендә геометрик фигуралар төзи, аларны хәрефләр белән билгели белүләре тикшерелә.

### Вариант 1

1. Саннарны цифрлар белән языгыз: тугыз мең өч йөз илле биш, ун мең. Ул саннарны чагыштырыгыз.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 364 | 673 | 30 605 | 4 327 | 54 308 | 20 010 |
| 3 871 | 12 824 | 9168 | 2 418 | 9165 | 587 |

3. 150 кг ны — граммнарда, 7 м 5 дм ны — дециметрларда, 6 мин ны секундларда күрсәтегез.
4. Приборның массасы 5 кг 300 г, ә футлярның массасы 800 г. Приборның футляры белән бергә массасын табыгыз.
5. Түбәләре *M, K,* һәм *O* булган өчпочмак сурәтләгез. Өчпочмакның исемен языгыз.

6*. Өчурынлы санның сул ягына 1 цифрын язганнар. Сан күпмегә арткан?

7*. 3, 6, 8 цифрлары ярдәмендә барлык өчурынлы саннарны языгыз. Һәр санның язылышында барлык цифрлар да төрле булырга тиеш.

Искәрмәләр:

6*. Җавап: 1000 гә.

7*. Җавап: 368, 386, 638, 683, 836, 863. Киләсе дәрестә бу мәсьәләне андый төрдәге мәсьәләнё чишү ысулы белән таныштыру максатында класста барлык укучылар белән чишү файдалы булыр.

Язмада бер санны да төшереп калдырмас өчен болай эшлибез: беренче 3 цифрын алабыз һәм башта аның янына 6 һәм 8 цифрларын язабыз, аннары 6 цифрын алабыз, аңа башта 3 һәм 8 саннарын, ә аннары 8 һәм 3 саннарын һәм, ниһаять, соңгы 8 цифрына 3 һәм 6 саннарын, ә аннары 6 һәм 3 саннарын язабыз. 6 сан килеп чыга.

## Вариант 2

1. Саннарны цифрлар белән языгыз: сигез мең, җиде мең бер йөз егерме өч. Ул саннарны чагыштырыгыз.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3 217 | 538 | 27 608 | _4 261 | _67 410 | _3 000 |
| +6 402 | +14 675 | +4 130 | 1 284 | 2 973 | 126 |

3. 80 000 г ны — килограммнарда, 5 м 27 см ны — сантиметрларда, 3 сәг 15 мин ны минутларда белдерегез.
4. Яшел челтәрнең озынлыгы 1 дм 7 см, ә кызыл челтәрнең озынлыгы 13 см га артыграк. Кызыл челтәрнең озынлыгы күпмегә тигез?
5. Ягының озынлыгы 4 см га тигез булган квадрат сызыгыз. Аның түбәләрен хәрефләр белән тамгалагыз һәм квадратның исемен языгыз.

6*. Бишурынлы сан килеп чыксын өчен, нинди дүртурынлы санга 1 не кушарга кирәк?

7*. 22 нче рәсемдә өчпочмаклар ничә?

Искәрмәләр:

6*. Җавап: 9999 га.

7*. Җавап: 8 өчпочмак. Бу мәсьәләне барлык балалар белән алдагы дәресләрнең берсендә карарга кирәк. Берсен дә төшереп калдырмыйча, өчпочмакларны җиңел генә санап була торган ысулны файдаланыгыз: берәрләп сурәтләнгән өчпочмакларны санйбыз, алар 4: *АОВ, ВОС, СОМ, АОМ,* һәм икешәр өчпочмактан торганнарын санйбыз, алар да 4: АВС, *АМС,АВМ,ВСМ.*

**Вариант 3**

1. 15036 санын разряд кушылучылары суммасы рәвешендә языгыз.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 2 318 + 9274' | 7 239 - 4268 | 528 + 1367 |
| 10 279 + 829 | 20 349 - 3256 | 30 100 - 5347 |

3. 205 см ны — метрларда, 2 мин 8 с ны — секундларда, 16 т ны килограммнарда белдерегез.
4. Мәктәптә дәресләр 8 сәг 30 мин та башлана. Дәрес 45 мин дәвам итә, ә беренче дәрестән соң тәнәфес 5 мин. Икенче дәреснең башлану вакытын исәпләгез.
5. Уртак очлары *A* ноктасы булган *AB* һәм *AC* кисемтәләрен сызыгыз.

6*. 0, 4, 2, 7, 9, 1 цифрларының һәрберсеннән бер генә тапкыр файдаланып, иң зур алтыурынлы сан языгыз.

7*. Бер генә уртак яклары булырлык итеп, ике өчпочмак сызыгыз.

Искәрмәләр:

6*. Иң зур алтыурынлы сан 974210, иң кечкенәсе — 102479.
7*. Мөмкин булган чишелешләрнең кайберләрен китерәбез (рәс. 23).

**Вариант 4**

1. 20160 санын разряд кушылучылары суммасы рәвешендә күрсәтегез.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 5 328 + 1 936 | 16 058 + 9 876 | 76 273 - 4 582 |
| 471 + 3 924 | 9 586 - 3 877 | 101 010 - 90 909 |

3. 5 км 240 м ны — метрларда, 120 мин ны — сәгатьләрдә, 6 кг ны граммнарда белдерегез.
4. Яшелчә кибетенә 1 т кәбестә китерәләр. Төшкә кадәр 200 кг, ә төштән соң 1 ц 50 кг кәбестә саталар. Кибеттә күпме кәбестә калган?
5. *ABCE* турыпочмаклыгында *AB* ягының озынлыгы 3 см га тигез, ә *BC* ягының озынлыгы 4 см га тигез. Ул турыпочмаклыкны сызыгыз.

6*. Саннарның кайсы зуррак: 9*** яки 1****?

7*. Бирелгән рәттән һәр киләсе санны болай табарга була: моннан алдагы санны 2 гә тапкырларга һәм нәтиҗәгә 1 не кушарга кирәк. Рәттә беренче сан 1 гә тигез. Киләсе өч санны языгыз.

Искәрмәләр:

6*. Бирелгән саннарны саннар язылышындагы барлык цифрларны белмичә дә чагыштырып була. Беренче санның дүртурынлы, ә икенчесенең бишурынлы икәнен күрү дә җитә. Теләсә нинди дүртурынлы сан, хәтта иң зуры да, бишурынлы саннан кечкенә. Шуңа күрә 9*** < 1****. Шуны күздә тотарга кирәк, кайбер балалар 9*** саны 1**** санынннан зуррак дип чишәрләр, чөнки аның язылышы 9 дан башлана, ә 9 саны 1 дән зуррак.
7*. Җавап: 3, 7, 15.

## Вариант 5

1. Мондый санны языгыз: а) егерме мең һәм өч йөз, б)дүрт мең һәм биш дистә.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 2 074 + 9 027 | 36 754 + 3 207 | 14 639 - 5 821 |
| 653 + 24 084 | 8 962 - 7 690 | 90 000 - 30 654 |

3. 180 с ны — минутларда, 5 см 9 мм ны — миллиметрларда, 120 000 кг ны тонналарда белдерегез.
4. Сәгать 10 сәг 55 мин ны күрсәтә. Ул сәгать 7 мин ка артка кала. Чынлыкта вакыт күпме?
5. Кәгазь битендә сызыклар кисешкән урынны С ноктасы белән билгеләгез. Аннан уңда 10 шакмак санагыз һәм В ноктасы билгеләгез. В ноктасыннан аска таба 5 шакмак санагыз һәм А ноктасы билгеләгез. Билгеләнгән нокталарны тәртип буенча кисемтәләр белән тоташтырыгыз. Килеп чыккан фигураның исемен языгыз.

6*. Һәр тортны урталай бүлгәннәр, һәр яртыны тагын урталай бүлгәннәр. 12 тәлинкәнең һәркайсына 1 әр кисәк торт куйганнар. Ничә торт булган?

7*. 16 санын суммалары иң кечкенә булган ике санның тапкырчыгышы рәвешендә языгыз.

Искәрмәләр:

6*. Мәсьәлә фикер йөртеп чишелә. Сайлап карарга кирәк: бер яки ике торт азрак: әгәр аны мәсьәләдә әйтелгәнчә, ягъни 4 кисәккә бүлсәк, ике торттан 8 өлеш чыгар, 12 түгел, тагы бер торт кирәк, ягъни барысы 3 торт. Башкача да фикер йөртеп була. 12 тәлинкәнең һәркайсына 1 әр кисәк торт куйганнар, ягъни 12 дүртенче өлешләрне, һәр тортны 4 кисәккә бүлгәннәр, ягъни барысы 3 тортны кискәннәр:12 : 4. Әлбәттә, бу фикерләрне балалар язмыйлар, җавапны язу җитә.
7*. Җавап: 16 = 4 • 4.

## Вариант 6

1. Түбәндәге санны языгыз: а) өч йөз егерме дистә, б) өч мең дүрт дистә һәм бер берәмлек.
2. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 5 374 + 4 865 | 276 + 2 765 | 58 627 - 9 465 |
| 103 849 + 68 036 | 9 274 - 3 856 | 30 000 - 23 154 |

3. 1050 кг ны — тонна һәм килограммнарда, 70 дм ны — метрларда, 2 сәг 50 мин ны минутларда белдерегез.
4. Поезд киткәнче туристның 3 сәг буш вакыты була. Кинотеатрда ул 1 сәг 20 мин буена фильм карый, аннары ярты сәгать паркта була, ә калган вакытта ул музейда картиналар күргәзмәсен карый. Турист музейда күпме вакыт булган?
5. *ABC* өчпочмагы сызыгыз. Бу өчпочмакны ике өчпочмакка бүләрлек итеп, кисемтә үткәрегез.

6*. Мин бер пачка кәгазь сатып алдым, анда 250 бит. 100 бит кәгазьнең массасы 160 г. Бөтен пачканың массасы нинди?

7*. 24 кызыл һәм 18 ак розалардан букетлар ясыйлар. Һәр букетта 3 кызыл һәм 3 ак роза булырга тиеш. Иң күбе ничә букет ясап була?

Искәрмәләр:

6*. Мәсьәләне чишү өчен, бер битнең массасын белү мәҗбүри түгел. Пачкада 250 бит. Анда 100 әр бит 2 тапкыр һәм тагын 50 бит (100 нең яртысы). Шуңа күрә бөтен пачканың массасы 400 г (160 • 2 = 320, 160 : 2 = 80, 320 + 80 = 400).

7*. Ихтимал, кайбер балалар мәсьәләне ялгыш чишәрләр: 24 + 18 = 42, 3 ÷ 3 = 6, 42 : 6 = 7. Җавап 7 түгел. Бу очракта сүз барган букетлар саны ак розалар санына бәйле, чөнки алар кызыллардан кимрәк. Барлык ак розалардан 6 букет ясап була (18 : 3 = 6). Бу сан мәсьәләнең җавабы була да инде.

## II ЧИРЕК

### «Тизлек, вакыт, юл» темасы буенча контроль эш

Контроль эштә өч арифметик мәсьәлә тәкъдим ителә. Эшнең максаты — укучыларның предмет турысызыклы тигез хәрәкәт иткәндә тизлек, вакыт һәм юл арасында бәйләнешне аңлауларын тикшерү.

Контроль эш теманы үткәннән соң якынча 1,5—2 атнадан соң үткәрелә.

**Вариант 1**

1. Авылдан шәһәргә кадәр араны хат ташучы мотоциклда 60 км/сәг тизлек белән 2 сәг тә үтә. Авылдан шәһәргә кадәр ничә километр?
2. Автобус 180 км ны 4 сәг тә үтә. Ул нинди тизлек белән барган?
3. Турист 12 км ны 4 км/сәг тизлек белән үтә. Ул ничә сәгать барган?

4*. Тизлекне үлчи торган приборның ничек дип аталганын беләсезме? Дөрес җавапны сайлап алыгыз һәм аны языгыз: 1) Термометр. 2) Рулетка. 3) Спидометр. 4) Сәгать. 5) Үлчәү.

5*. Мотоцикл, 80 км/сәг тизлек белән хәрәкәт итеп, юлда берничә тапкыр туктап алып, 160 км юл үтә. Әгәр тукталышлар 25 мин вакытны алган булса, мотоциклчының барлык юлга күпме вакыты киткән?

Искәрмәләр:

4*. Җавап: Спидометр.
5*. Чишү: 160 : 80 = 2 (сәг.). 2 сәг 25 мин = 2 сәг 25 мин. Җавап: 2 сәг 25 мин.

**Вариант 2**

1. Теплоход 4 сәг тә 120 км юл үткән. Теплоход нинди тизлек белән хәрәкәт иткән?
2. Автомашина 120 км/сәг тизлек белән 5 сәг барган. Бу автомашинаның үткән юлын табыгыз.
3. Товар поезды 40 км/сәг тизлек белән 160 км юл үтә. Поезд бу юлны күпме вакытта үткән?

4* Космик корабль 8 км/с тизлек белән оча. Ул 1 мин та күпме ара очып үтә? Корабльнең тизлеген км/мин та языгыз.

5*. Агач яфракларын тибрәтә торган талгын җил 5 м/с тизлек белән исә, ә агачларның тамырларын куптарып ала торган ураган җиленең тизлеге 35 м/с ка җитәргә мөмкин. Ураган җиле талгын җилдән ничә тапкырга көчлерәк?

Искәрмәләр:

4*. Чишү: 1 мин = 60 сек. 8 • 60 = 480. Җавап: 480 км, 480 км/мин.
5*. Чишү: 35 : 5 = 7. Җавап: 7 тапкыр.

**Вариант 3**

1. Поезд 4сәг 95км/сәгтизлек белән барган. Ул күпме юл үткән?
2. Самолет 3 сәг тә 2 940 км юл очып үткән. Самолет нинди тизлек белән очкан?
3. Ташбака, туктамыйча 5 м/мин тизлек белән хәрәкәт итсә, ул 100 м араны күпме вакытта үтәр?

4*. Автомобильнең тизлеге 60 км/сәг. Ул тизлекне км/мин ларда белдерегез.

5*. Автомашина авылдан иртәнге сәг 7 дә чыга һәм иртәнге 9 да шәһәргә барып житә. Әгәр автомашина 120 км/сәг тизлек белән хәрәкәт итсә, авылдан шәһәргә кадәр булган ераклыкны табыгыз.

Искәрмәләр:

4*. Чишү: 1 сәг = 60 мин, 60 : 60 = 1. Җавап: 1 км/мин.

5*. Чишү: 9 - 7 = 2 (сәг). 120 • 2 = 240 (км). Җавап: 240 км.

**Вариант 4**

1. Вертолет 4 сәг тә 820 км очып үтә. Вертолетның тизлеген табыгыз.
2. Чаңгычы 200 м/мин тизлек белән 8 мин хәрәкәт итә. Чаңгычы күпме юл үткән?
3. «Ракета» теплоходы 48 км/сәг тизлек белән 96 км юл үтә. Теплоход юлда күпме вакыт булган?

4*. Мин бинокльдән 1000 м/мин тизлек белән хәрәкәт итүче җисемне күзәттем. Ул тизлекне км/мин ларда белдерегез.

5*. Малай өеннән чыга һәм 50 м/мин тизлек белән мәктәпкә китә. 100 м баргач, үзеннән алда барган иптәшен күрә. Һәм 3 мин тан аны куып житә. Малай өеннән чыгып иптәше белән очрашканчы күпме вакыт үткән?

Искәрмәләр:

4*. Чишү: 1000 м = 1 км. Җавап: 1 км/мин.

5*. Чишү: 100 : 50 = 2 (мин). 2 + 3 = 5 (мин). Җавап: 5 мин.

**Вариант 5**

1. 3 сәг тә Фәрит велосипедта 36 км, ә Камил шул ук вакыт эчендә 45 км юл үтә. Аларның кайсысы тизрәк хәрәкәт иткән?
2. Әкәм-төкәм 9 м/мин тизлек белән 108 м ара үрмәләп үткән. Юлда ул яфрак ашау өчен 2 мин ка туктый. Әкәм-төкәм юлда барлыгы күпме вакыт булган?

3. Малай яшен яшьнәгәнен күрә, ә 5 с тан соң күк күкрәгәнен ишетә. Һавада тавышның тизлеге 330 м/с ка тигез булса, яшенле яңгыр нинди ераклыкта булган?
4*. Үсемлекләр арасында бамбук — үсү тизлеге буенча чемпион. Әгәр бамбук агачы тәүлегенә 40 см га үссә, 20 см биеклектәге бамбук күпме вакыттан соң 3 м га җитә?
5*. Куян төлкедән 60 км/сәг тизлек белән кача. Төлкенең артта калуын сизеп, куян тизлеген өч тапкыр киметә һәм өенә кадәр калган араны чирек сәгатьтә йөгереп үтә. Төлке артта калганнан соң, куян өенә кадәр ничә километр йөгергән?

Искәрмәләр:

4*. 3 м - 20 см = 2 м 80 см = 280 см. 280 : 40 = 7 (көн). Җавап: 7 көн.

5*. Чишү: 60 : 3 = 20 (км/сәг). 20 : 4 = 5 (км). Җавап: 5 км.

## Вариант 6

1. Тәнзилә 40 м ны 5 с та, ә Мәдинә 42 м ны 7 с та йөгереп үтә. Кайсы кыз әкренрәк йөгергән?
2. Космик корабль 7 км/с тизлек белән 84 км очып үтә. Ул ничә секунд очкан?
3. Эт үзеннән 50 м еракльтта эскәмиядә утырып торган хуҗасын күрә һәм аның янына 10м/с тизлек белән йөгерә. Ул хуҗасы янына ничә секундта йөгереп килеп җитә?
4*. Зәңгәр акула 30 км/сәг тизлек белән йөзә. Шул ук тизлек белән акула 10 мин та күпме ара йөзеп үтәр?
5*. Куян урманда аучы белән бәрелешә, һәм бу көтелмәгәнлектән алар төрле якка йөгерә башлаганнар: куян 17 м/с тизлек белән, ә аучы 5 м/с тизлек белән йөгергән. 10 с тан соң алар бер-береннән нинди еракльтта булганнар?

Искәрмәләр:

4*. Чишү: 10 мин — ул сәгатьнең алтыдан бер өлеше. Акула ул вакыт эчендә 5 км йөзеп үтә ала (30 : 6 = 5). Җавап: 5 км.
5*. Чишү: 17·10 = 170(М). 5-10 = 50(м). 170 + 50 = 220. Җавап: 220 м.

### II чирек өчен контроль эш

Контроль эшнең максаты укучыларның кўбурынлы санны берурынлы санга тапкырлый һәм бүлә белүләрен, зурлыкларны куша һәм ала белүләрен, турыпочмаклыкның мәйданын таба белүләрен тикшерүдән гыйбарәт.

**Вариант 1**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | |
|---|---|
| 44 • 56 | 728 : 2 |
| 1 509 • 4 | 824 : 8 |
| 2 500 • 8 | 1 095 : 3 |

2. Исәпләгез:

| | |
|---|---|
| 2 см 5 мм + 25 мм, | 1 сәг + 20 мин, |
| 65 кг 240 г + 850 г, | 2 сәг 30 мин - 45 мин. |

3. Турыпочмаклыкның бер ягының озынлыгы 4 дм, ә икенчесенең 2 дм. Җавапларның кайсысы бу турыпочмаклыкның мәйданын белдерә: 1) 6 дм$^2$, 2) 8 дм$^2$, 3) 8 дм, 4) 12 дм.

4*. Квадрат сызыгыз. Һәр ягында 3 әр нокта булырлык итеп, аның якларында 8 нокта билгеләгез.

5*. Нинди фигураның мәйданы иң зур (рәс. 24)? Дөрес җавапны сайлап алыгыз: а) 1; б) 2; в) 3; г) 4.

Искәрмә:

5*. Җавап: 3 нче фигура.

**Вариант 2**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | |
|---|---|
| 237 • 6 | 702 : 3 |
| 3 508 • 2 | 618 : 6 |
| 4 300 • 7 | 2 048 : 8 |

2. Исәпләгез:

| | |
|---|---|
| 2 сәг 32 мин + 50 мин, | 3 т - 260 кг, |
| 1 сәг - 40 мин, | 2 м 50 см - 1 м 80 см. |

3. Турыпочмаклыкның яклары 3 см һәм 6 см. Бу турыпочмаклыкның мәйданы нинди? Сайлап алып, дөрес җавапны языгыз: 1) 18 см, 2) 81 см, 3) 18 см, 4) 9 см.

4*. 26 нчы рәсемдә сурәтләнгән барлык кисемтәләрнең исемнәрен языгыз.

5*. Вазада 24 слива булган. Берничә ир туган аларны үзара тигез итеп бүләргә уйлаганнар. Һәркайсы 7 шәр слива алгач, вазада 3 слива калган. Ничә туган булган һәм һәркайсы ничәшәр слива алган?

Искәрмәләр:

4*. Сул очлары *А* ноктасында булган кисемтәләр өчәү: *АС, АМ, АВ.* Очлары С ноктасында булган кисемтәләр икәү: *СМ* һәм *СВ,* очы *М* ноктасында булган кисемтә берәү — *МВ.* Барысы 6 кисемтә табыла (3 + 2 + 1 = 3).

5*. Туганнар 21 слива (24-3 = 21) алганнар. Һәркайсы 7 слива алганга күрә, туганнар өчәү була: 21 : 7 = 3. Әгәр туганнар калган 3 сливаны да үзара бүлешсәләр, туганнарның һәркайсы 8 әр слива алыр (моны ике юл белән белергә була: 24 : 3 = 8 яки 3 : 3 = 1, 7 + 1 = 8).

## Вариант 3

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | |
|---|---|
| 198 • 7 | 852 : 4 |
| 7 061 • 5 | 510 : 2 |
| 2 800 • 4 | 2 527 : 7 |

2. Исәпләгез:

1 сәг 20 мин + 2 сәг 50 мин, 1 500 г - 1 кг 200 г,
6 мм + 60 см, 1 мин 30 с - 40 с.

3. Ягы 10 см булган квадратның мәйданын табыгыз. Бирелгән җавапларның кайсысы дөрес: 1) 100 см, 2) 40 см, 3) 40 см, 4) 100 см.

4*. Абыйсы белән сеңлесенең 20 шәр кура җиләге булган. Абыйсы үзенең 8 җиләген ашаган, ә сеңлесе, абыйсының ашаганнан соң ничә җиләге калган булса, шулкадәр җиләген ашый. Алар икесе бергә ничә җиләк ашаганнар?

5*. Үлчәүнең бер тәлинкәсенә бер бөтен сыр, ә икенче тәлинкәсенә шундый ук массалы сырның ятрысын һәм 2 кг лы гер куйганнар. Үлчәүләр тигезләнеш торышында. Бер бөтен сырның массасын табыгыз.

Искәрмәләр:

4*. Ихтимал, балалар бу мәсьәләне болай чишәрләр: сеңлесе 12 җиләк ашаган (20 - 8 = 12), абыйсы белән сеңлесе бергә 20 җиләк ашаганнар (12 + 8 = 20). Тагын да кызыграк чишү ысулы бар: абыйсы белән сеңлесе бергә берсендә булган кадәр җиләк ашаганнар, ягъни 20 не. Бернинди исәпләүләр дә кирәкми. Җавап: 20 җиләк.

5*. Укучылар 2 кг лы гер бер бөтен сырның икенче яртысын алыштыруына төшенергә тиешләр, чөнки үлчәүләр тигезләнеш торышында. Димәк, сыр массасының яртысы 2 кг. Бөтен сырның массасы 4 кг (2 • 2 = 4). Җавап: 4 кг.

## Вариант 4

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | |
|---|---|
| 567 • 3 | 784 : 8 |
| 1 094 • 7 | 432 : 4 |
| 5 800 • 5 | 1 054 : 2 |

2. Исәпләгез:

20 мин + 1 сәг 45 мин, 3 дм - 1 дм 4 см,
840 г + 3 кг 400 г, 2 сәг - 30 мин.

3. Ягы 8 дм булган квадратның мәйданын исәпләгез. Дөрес җавапны күчереп алыгыз: 1) 64 $см^2$, 2) 32 $дм^2$, 3) 64 $дм^2$, 4) 32 дм.

4*. Мидхәт Әминәдән 3 яшькә зуррак. Ике елдан соң Мидхәт Әминәдән ничә яшькә зуррак булыр?

5*. Дәфтәр битендәге шакмаклардан файдаланып, һәркайсының мәйданы 4 $см^2$ булган төрле берничә фигура сурәтләгез.

Искәрмәләр:

4*. 3 яшькә.

5*. Берничә чишелеш китерәбез (рәс. 27).

**Вариант 5**

1. Гамәлләрне эшләгез:

534 • 9 532 : 4
2 406 • 4 924 : 3
7 200 • 5 11 060 : 7

2. Исәпләгез:

5 т 600 кг + 850 кг, 45 мин + 55 мин,
8 м + 3 м 5 дм, 2 сәг - 1 сәг 30 мин.

3. Балалар мәйданчыгы урнашкан турыпочмаклы участокның бер ягының озынлыгы 3 м, ә икенче ягы 2 тапкырга артыграк. Ул участокның мәйданын исәпләгез.

4*. Арыслан 9 с та 200 м йөгереп үтә. Ул 600 м ны шул тизлек белән ничә секундта йөгереп үтәр?

5*. Үлчәмнәре бертигез булган лимоннарны данәләп саталар. 2 дән күбрәк һәм 6 дан кимрәк лимон сатып алганнар. Барлык сатып алган әйберләрнең массасы 950 г. Бер лимонның массасы күпме?

Искәрмәләр:

4*. Мәсьәләне чишү өчен, арысланның тизлеген белергә кирәкми. Әгәр 200 м ны 9 с та йөгерсә, шул ук тизлек белән 600 м ны йөгереп үтү өчен, аңа 3 тапкыр артыграк вакыт кирәк булыр. Чишү: 600 : 200 = 3, 9 • 3 = 27. Җавап: 27 с.

5*. 2 дән зур һәм 6 дан кечкенә саннар өчәү: 3, 4, 5, 950 саны сатып алган лимоннар санына калдыксыз бүленергә тиеш. Һәр санны тикшерәбез: 950 : 3 — туры килми, 950 : 4 — туры килми. 950 : 5 — 190. Бер лимонның массасы 190 г. Җавап: 190 г.

**Вариант 6**

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | |
|---|---|
| 298 • 4 | 792 : 3 |
| 1 206 • 5 | 820 : 4 |
| 3 600 • 3 | 1 864 : 6 |

2. Исәпләгез:

| | |
|---|---|
| 35 с + 40 с, | 13 м - 60дм, |
| 15 кг 250 г + 6 кг 850 г, | 1 сәг - 20мин. |

3. Квадратның барлык яклары озынлыгының суммасы 20 дм. Квадратның мәйданын табыгыз.

4*. Турыпочмаклы формада булырлык итеп, бертөрле калынлыкта ике торт пешергәннәр. Бер торт үлчәмнәре икенчесенеҢ үлчәменнән ике тапкырга зуррак. Зур тортның массасы 2 кг. Кечерәк тортның массасын табыгыз.

5*. 3 кг лы карбызны, бер кисәге икенчесеннән ике тапкырга авыррак булырлык итеп, тигез булмаган ике кисәккә бүлгәннәр. Кечерәк кисәкнең массасын белегез.

Искәрмәләр:

4*. Бер тортның үлчәмнәре икенчесеннән 2 тапкырга кимрәк булганга, аның массасы да 2 тапкырга кимрәк, ягъни 1 кг була дип, ялгыш чишәчәкләр кайбер укучылар. Чынында исә ул алай түгел. Кечерәк торт шул ук калынлыкта зур тортның дүрттән бер өлешен тәшкил итә (рәс. 25), ягъни аның массасы 4 тапкыр кимрәк. Чишелеше болай: 2 кг = 2000 г, 2000 : 4 = 500. Җавап: 500 г.

5*. Зуррак кисәкнең массасы ике кечкенә кисәкнеке кадәр. Зуррак кисәкне кечерәк кисәк массасы кебек кисәкләргә бүлсеннәр, ди. Ул вакытта массалары буенча бертөрле өч кисәк килеп чыгар иде. Аларның һәркайсының массасы 1 кг (3 : 3 = 1). Димәк, карбызның кечерәк кисәгенең массасы 1 кг.

III ЧИРЕК

## III чирек өчен контроль эш

Эшнең максаты — укучыларның вакланманың мәгънәсен аңлауларын, санның вакланмасын таба белүләрен, икеурынлы һәм өчурынлы санга тапкырлый белүләрен, зурлыклар арасындагы өйрәнелгән бәйләнешләрне эченә алган төзелмә арифметик мәсьәләләрне чишә белүләрен тикшерү.

Контроль эш тексты дәрескә кадәр тактага язып куела. 1 нче биремгә рәсемне укытучы тактада ясый яки алдан зур булмаган плакатлар әзерли. Бу биремгә җавапны балалар язманы сулдан уңга бер юлга вакланма рәвешендә язалар.

**Вариант 1**

1. Һәр фигураның нинди өлеше штрихланганын языгыз, (рәс. 29).
2. Вазада 15 ак һәм кызыл канәферләр. Ак канәферләр барлык канәферләрнең−2/5сен тәшкил итә. Вазада ак канәферләр ничә?
3. Тапкырлауны башкарыгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 52 •84 | 128 • 53 | 309 • 124 |
| 37 • 90 | 251 • 407 | 620 • 300 |

4. Шикәр комы 3 әр кг итеп пакетларга салынган. Чия һәм җиләк вареньесы ясаганнар. Чия вареньесы өчен 12 кг шикәр комы, ә җиләк вареньесы өчен 9 кг шикәр комы тотылган. Варенье кайнату өчен, ничә пакет шикәр комы тотылган?

5*. 7 — *x* аңлатмасының ничә кыйммәте бар?

6*. Җирдә бозлыклар коры җирнең 1/7 ен алып торалар. Таулармы яки бозлыклармы зуррак мәйданны алып торалар? Сайлап алып, җавапны языгыз: 1) Таулар. 2) Бозлыклар. 3) Җавап бирә алмыйм.

Искәрмәләр:

5*. Әлеге очракта *x* урынына 0 дән 7 гә кадәр саннарның теләсә кайсын куярга була, шуңа күрә аңлатманың 8 кыйммәте бар (7, 6, 5, 4, 3, 2, 1, 0). Җавап: 8 кыйммәт.

6*. Җавап: Таулар.

**Вариант 2**

1. Һәр фигураның нинди өлеше штрихланган (рәс. 30) булуынязыгыз.
2. Кечкенә аквариумда 12 балык. Барлык балыкларның 2/3 сен зур аквариумга күчергәннәр. Зур аквариумга ничә балык күчергәннәр?
3. Тапкырлауны башкарыгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 48 • 29 | 273 • 305 | 126 • 275 |
| 70 • 67 | 526 • 40 | 384 • 600 |

4. Иртән сәгать 8 дә без энем белән өйдән чыгып, төрле юлдан мәктәпкә киттек. Энем мәктәпкә дәресләр башланырга 10 мин кала килеп җиткән, ә мин, кыскарак юлдан килеп, 5 мин азрак вакыт сарыф иттем. Мәктәптә дәресләр 8 сәг 30 мин та башлана. Безнең һәркайсыбыз мәктәпкә ничә минутта барып җиткән?

5*. *x* урынына куйгач, 7 - *x* аңлатмасының кыйммәте булмаслык итеп, өч сан уйлап языгыз.

6*. Бүлмәнең мәйданы 20 $м^2$, ә аның киңлеге 4 м. Ул бүлмәгә үлчәмнәре 2 м һәм 3 м булган ковер җәергә буламы?

Искәрмәләр:

5*. 7 - $x$ аңлатмасының мәгънәсе булмаган $x$ ның андый натураль кыйммәтләре теләгән кадәр күп. Болар — 8 дән башланган барлык саннар. Балалар сайлап табарга һәм өчесен язып куярга тиешләр, мәсәлән: 8, 12, 46. Кайбер укучылар 7 санын да язарга мөмкин. Ул хата була: $x$ ның бу кыйммәтендә 7 - $x$ аңлатмасының кыйммәте 0 гә тигез (7-7 = 0).

6*. Чишү: Бүлмәнең буе 5 м (20 : 4 = 5). Җавап: Була.

**Вариант 3**

1. Нинди дә булса кисемтә сызыгыз. Аны тигез өч кисәккә бүләргә тырышыпкарагыз. Бу кисемтәнең 2/3 сен кызыл карандаш белән буягыз.
2. Без энем белән диңгез яр буеннан 30 кабырчык җыйдык. Мин барлык кабырчыкларның 3/5 ен җыйдым. Энем ничә кабырчык җыйган?
3. Тапкырлауны башкарыгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 16 • 98 | 236 • 29 | 415 • 273 |
| 50 • 63 | 715 • 308 | 300 • 453 |

4. Пристаньнан бер үк вакытта капма-каршы юнәлештә ике теплоход кузгала. Берсе 40 км/сәг тизлек белән, ә икенчесе 30 км/сәг тизлек белән бара. Хәрәкәт башланып 2 сәг тән соң, алар арасындагы ераклык нинди булыр?

5*. Велосипедчы 15 км/сәг тизлек белән бара. 20 мин та ул күпме ара үтәр?

6*. Турыпочмаклы кәгазь битенең буе 50 см, ә иңе 30 см. Бу битне һәркайсының мәйданы 100 $см^2$ булган квадратларга кискәләп буламы? Андый квадратлар ничә?

Искәрмәләр:

5*. Фикерләүнең иң гади ысулын күрсәтәбез. 1 сәг тә 20 мин 3 тапкыр бар (60 : 20 = 3). Димәк, 20 мин — ул сәгатьнең өчтән бере. Велосипедчы һәр сәгать саен 15 км барганлыктан, сәгатьнең өчтән берендә ул 5 км юл үтә (15 : 3 = 5). Җавап: 5 км.

6*. Укучылар квадрат ягының озынлыгы 10 см (100 = 10 • 10)га тигез икәненә төшенергә тиешләр. 30 см да 3 тапкыр 10 см бар, ә 50 см да 5 тапкыр 10 см бар. Димәк, турыпочмаклыктан бирелгән якларның озынлыклары белән 15 квадрат кисеп

алырга була. Чишелешне болай язарга була: 1) 30 : 10 = 3, 2) 50 : 10 = 5, 3) 3 • 5 = 15. Җавап: 15.

Чишелешнең тагын бер ысулы бар: 50 • 30 = 1 500 ($см^2$), 1 500 : 100 = 15. Ләкин бу ысул әйбәт түгел: башка санлы бирелгәннәр булганда, ул хатага китерә. Мәсәлән, турыпочмаклык якларының озынлыклары 50 см һәм 8 см булсын, ә квадрат мәйданы 100 $см^2$ • 400 (50 • 8) 100 гә бүленүгә карамастан (4 килеп чыга), андый үлчәмле турыпочмаклыктан бер квадрат та кисеп алырга ярамый.

## Вариант 4

1. Туристларгруппасында 10 кешенең 3 есе — инглизләр, ә калганнары — французлар. Инглизләргруппаның нинди өлешен тәшкил итәләр? Французлар бөтен группаның нинди өлешен тәшкил итәләр? Нәтиҗәләрен вакланма рәвешендә языгыз.
2. 12 кг җир җиләге һәм кура җиләге вареньесы кайнатканнар. Җир җиләге вареньесы барлык кайнатылган вареньеның 3/4 е кадәр булган. Ничә килограмм кура җиләге вареньесы кайнатканнар?
3. Тапкырлауны башкарыгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 22 • 48 | 925 • 26 | 298 ·134 |
| 57 • 60 | 157 • 209 | 270 ·150 |

4. Башта турист 80 км/сәг тизлек белән 3 сәг автомашинада бара, аннары поездга утыра һәм автомашинада барган кадәр ераклык үтә. Әгәр поезд 60 км/сәг тизлек белән хәрәкәт итсә, ә тукталышларга ярты сәгать вакыты киткән булса, турист поездда ничә сәгать барган?

5*. Өстәл өстендә үлчәмнәре төрле булган өч тартма тора: зур, уртача һәм кечкенә. Тартмаларда шарлар ята: зур тартмада уртачадагыдан 2 тапкырга артыграк шар, ә уртачада кечкенәсендәгедән 2 тапкырга артыграк. Зур тартмада кечкенәсендәгедән шарлар ничә тапкыр артыграк?

6*. Турыпочмаклы кәгазь битенең мәйданы 18 $см^2$. Бу кәгазь битеннән ягы 3 см булган ничә квадрат кисеп алып була?

Искәрмәләр:

5*. «2 тапкырга зуррак» чагыштырмасы транзитивлык үзлегенә ия түгел. Шуңа күрә зур тартмада кечкенә тартмадагыдан шарлар 2 тапкырга артык түгел (кайбер балалар чишкәнчә), ә 4 тапкыр артык. Әйтелгәнне мисал өстендә күрсәтәбез. Зур тартмада 16 шар, уртачасында — 8, ә кечкенәсендә 4 шар булсын. 16 саны 4 тән 4 тапкыр зуррак. Бу башка саннар өчлеге өчен дә дөрес: 12, 6, 3, 20, 10, 5 һ.б.

6*. Балаларның күпчелеге мәсьәләне формаль чишәрләр, квадратның мәйданы 3 • 3 = 9 (см$^2$), димәк, 18 см$^2$ мәйданлы турыпочмаклыктан ике квадрат кисеп алырга була (18 : 9 = 2). Ләкин бу чишелешне дөрес дип санарга ярамый. Мәсьәләдә турыпочмаклыкның үлчәмнәре турында бернәрсә дә әйтелмәгән. Турыпочмаклыкның үлчәмнәре 1 • 18 см яки 2 • 9 см булырга мөмкин. Андый турыпочмаклыктан ягының озынлыгы 3 см булган бер генә квадрат та кисеп алып булмый. Әгәр турыпочмаклыкның үлчәмнәре 3 • 6 см булса, аннан 2 квадрат кисеп алырга була. Шуңа күрә җавапны болай язарга була: «Билгесез». Билгеле, җавапның мондый формасына балалар күнекмәгән. Шуңа күрә алдагы дәрестә бу яки моңа охшаш мәсьәләне барлык укучылар белән тикшерү һәм чишү файдалы булыр.

## Вариант 5

1. Чия компотын бертөрле 5 стаканга бүлеп салганнар. Балалар 3 стакан компот эчкәннәр. Балалар компотның нинди өлешен эчкәннәр? Җавапны вакланма рәвешендә языгыз.
2. Бакчадан 40 кыяр алып кайтканнар. Барлык кыярның ^- ен тозлаганнар. Ничә кыярны тозлаганнар? Ничә кыяр калган?
3. Тапкырлауны башкарыгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 44 • 27 | 608 • 24 | 621 • 158 |
| 90 • 53 | 700 • 58 | 420 • 304 |

4. 2 м озынлыктагы тукыма кисәгеннән бертөрле яулыклар теккәннәр: башта 6 данә, ә аннары тагын 4 не. Яулыкның иңе кисәкнең иңе кадәр. Бер яулыкка күпме тукыма киткән?

5*. Авылдан шәһәргә 12 км/сәг тизлек белән хат ташучы юлга чыга. Шул ук вакытта аңа каршы шәһәрдән авылга 6 км/сәг тизлек белән турист юлга чыга. Авылдан шәһәргә кадәр ераклык 9 км. Ярты сәгатьтән соң алар арасындагы ераклык нинди булыр?

6*. 10 см озынлыгындагы квадрат кисәкле кәгазьне 25 см$^2$ мәйданлы квадратларга кискәләгәннәр. Һәр квадратны диагонале буенча бөкләгәннәр һәм өчпочмакларга кискәннәр. Ничә өчпочмак килеп чыгар?

Искәрмә:

5*. Ярты сәгатьтә хат ташучы 6 км (12 : 2 = 6) юл үтә, ә турист 3 км (6 : 2 = 3) үтә. Авылдан шәһәргә кадәр ераклык 9 км булганга күрә, хәрәкәт башланып ярты сәгать үткәч, алар очрашалар (6 + 3 = 9). Очрашу моментында алар арасындагы ераклык 0 км. Җавап: 0 км.

## Вариант 6

1. Төсле кәгазь битен дүрткә бөклиләр, ә аннары бу битнең дүрттән бер өлешен кисеп алалар. Битнең ничәнче өлеше кала? Җавапны вакланма рәвешендә языгыз.
2. Күлдә 20 үрдәк .булган. Кинәт куаклар арасыннан тавыш ишетелә. Һәм барлык үрдәкнең 4/5е очып китә. Ничә үрдәк очып киткән?
3. Тапкырлауны башкарыгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 65 • 38 | 503 • 17 | 364 • 296 |
| 46 • 70 | 900 • 64 | 210 • 307 |

4. Ике ташбака бер үк вакытта сукмак буйлап кара-каршы хәрәкәт итәләр һәм 3 мин тан соң очрашалар. Берсенең тизлеге 6 м/мин, ә икенчесенең 5 м/мин. Хәрәкәт башланганчы ташбакалар арасында булган ераклыкны табыгыз.

5*. Кеше юл буйлап 4 км/сәг тизлек белән бара. Ул 3 км ны күпме вакытта үтәр?

6*. Чикерткә 10 м/с тизлек белән оча. Ул 1 сәг тә ничә километр очып үтәр?

Искәрмәләр:

5*. Мәсьәләнең шарты буенча кеше 4 км ны 1 сәг тә үтә, ягъни 4 км ны 60 мин та. Димәк, 1 км ны ул 15 мин та үтә (60 : 4 = 15), ә 3 км ны 45 мин та (15 • 3 = 45) барыр. Җавап: 45 мин та.

6*. 1 сәг тә 3 600 с (60 • 60 = 3 600). Мәсьәләнең шарты буенча 1 с та чикерткә 10 м очып үтә, ә 1 сәг тә, ягъни 3 600 с та, ул 3 600 тапкыр зуррак ераклыкта очар, ягъни 10 • 3 600 = 36 000 (м) '= 36 км. Җавап: 36 км.

IV ЧИРЕК

## «Күбурынлы саннар белән арифметик гамәлләр» темасы буенча контроль эш

Эшнең максаты өченче сыйныф укучыларының исәпләү күнекмәләрен үзләштерү дәрәҗәсен ачыклаудан гыйбарәт. Бу эштә, язып исәпләү алымнарыннан файдаланып, арифметик гамәлләрне ( кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү) башкара белүләре, шулай ук төзелмә санлы аңлатманың кыйммәтен таба белүләре тикшерелә.

Әлеге контроль эш «Өчурынлы санга бүлү» темасын өйрәнгәннән соң үткәрелә.

**Вариант 1**

1. Гамәлләрне башкарыгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 615 + 957 | 231 • 15 | 318 : 3 |
| 10 305 - 8264 | 97 • 98 | 9 072 : 42 |

2. Аңлатманың кыйммәтен табыгыз:

1 400 - 400 : 50 + 30

3*. Әгәр 3 дистәне 4 дистәгә тапкырласаң, ничә дистә килеп чыгар? Сайлап алып, дөрес җавапны языгыз: 1) 12 дистә, 2) 120 дистә, 3) 7 дистә.

4* 1 + 2 + 3 + 4 + 5 + 6 + 7 + 8 + 9 + 10 саннарының суммасын табыгыз.

Искәрмәләр:

3*. Җавап: 120 дистә.

4*. Балаларның тәртип буенча 1 + 2 = 3, 3 + 3 = 6, 6 + 4 = 10 һ.б. дип кушуларын көтәргә була. Бу ысул дөрес булса да, бик озын һәм кызыксыз. Әгәр укучы мәсьәләне бу ысул белән чишсә, чишелешне 5 ле билгесе белән бәяләү кирәкмәс. Кушылучыларны группалауга нигезләнгән чишелешнең башка ысулын күрсәтәбез. Кушылучыларны болай группалыйбыз: беренчене соңгы белән, икенчесен соңгыдан алдагы һ.б., ягъни 1 һәм 10, 2 һәм 9, 3 һәм 8, 4 һәм 7, 5 һәм 6, һәр парда саннар суммасы 11 гә тигез. Андый парлар барлыгы биш. Димәк, барлык саннар суммасы 55 кә тигез (11 • 5 = 55). Җавап: 55.

**Вариант 2**

1. Гамәлләрне башкарыгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 1 498 + 526 | 427 • 3 | 2 035 : 5 |
| 3 916 - 837 | 218·24 | 2 380:14 |

2. Аңлатманың кыйммәтен табыгыз:

320 - 80 + 20 : 5

3*. Квадратның мәйданы 36 $см^2$ га тигез. Аның ягының озынлыгы күпмегә тигез? Сайлап алып, җавапның берсен языгыз: 1) 18 см, 2) 9 см, 3) 6 см. 4) Белмим.

4*. Әгәр 1 санын үз-үзенә мең тапкыр тапкырласаң, ничә килеп чыгар?

Искәрмәләр:

3*. Мәсьәлә куеп карау юлы белән чишелә. 1, 2, 3, 4... саннарын тәртип буенча куеп карап, укучылар нәтиҗәгә килерләр: 6 см.

4*. Җавап: 1

## Вариант 3

1. Гамәлләрне башкарыгыз:

| | | |
|---|---|---|
| 7 804 + 2 169 | 89·36 | 15 624:63 |
| 9 000 - 5 093 . | 405 • 236 | 34 290 : 135 |

2. Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: 1 500 : (50 + 25 • 2).

3*. Турыпочмаклык якларының озынлыклары суммасы 12 см. Бу турыпочмаклыкның яклары нинди озынлыкта булырга мөмкин?

4*. Квадрат ягының озынлыгы 1 дм. Бу квадратны ягының озынлыгы 1 см булган кечкенә квадратларга кискәләгәннәр һәм алардан киңлеге 1 см булган 1 буй тезгәннәр. Әлеге буй нинди озынлыкта килеп чыккан?

Искәрмәләр:

3*. Җавап: 3 см һәм 3 см (квадрат), 4 см һәм 2 см, 5 см һәм 1 см.
4*. Җавап: 1 м.

## Вариант 4

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 50 386 + 2 947 | 428 • 35 | 4 158 : 27 |
| 12 803 - 6 931 | 204 • 567 | 25 544 : 124 |

2. Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: 600 + 300 : (450 - 300).

3*. Турыпочмаклыкның мәйданы 12 см². Аның якларының озынлыклары нинди булырга мөмкин?

4*. Икеурынлы санда 5 дистә һәм берничә берәмлек. Бу санның цифрлары арасына 0 язганнар. Килеп чыккан өчурынлы сан икеурынлы саннан ничәгә зуррак?

Искәрмәләр:

3*. Җавап: 12 см һәм 1 см, 2 см һәм 6 см, 3 см һәм 4 см.

4*. Икеурынлы санны болай язабыз: 5*, ул вакытта өчурынлы сан мондый рәвештә булыр: 50*. Өчурынлы сан белән икеурынлы сан аермасы берәмлек разрядында торган цифрга бәйсез рәвештә 450 гә тигез булыр:

$$\begin{array}{r} 50* \\ \underline{5*} \\ 450 \end{array}$$

Җавап: 450.

## Вариант 5

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 5 106 + 14987 | 223 • 605 | 16 872 : 24 |
| 80 000 - 1267 | 407·216 | 48 664:316 |

2. Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: (270 + 30) • 20 : 4.

3*. Ике җәяүле ике авылдан бер үк вакытта кара-каршы юлга чыгалар. Бер җәяүленең тизлеге 5 км/сәг, ә икенчесенең 4 км/сәг. Авыллар арасындагы ераклык 3 км. Хәрәкәт башланып бер сәгать үткәч, җәяүлеләр арасында нинди ераклык булыр?

4*. Миләүшә Ленадан 3 тапкыр зуррак. Бер елдан соң Миләүшә Ленадан шулай ук 3 тапкыр зуррак була дип раслап буламы? Бирелгән җавапларның берсен сайлап алып языгыз: 1) Әйе. 2) Юк. 3) Белмим.

Искәрмәләр:
3*. Хәрәкәт башланып бер сәгать үтүгә, 5 км/сәг тизлек белән баручы җәяүле 5 км үтәр. Ул вакыт эчендә ул икенче авылга барып җитә (аңа кадәр 3 км) һәм тагын 2 км бара. Икенче җәяүле беренче авылга (3 км) барып җитә һәм тагын 1 км бара. Димәк, хәрәкәт башланып бер сәгатьтән соң, җәяүлеләр арасындагы ераклык 6 км (3 + 2 + 1 = 6) булыр. Җавап: 6 км.
4*. Җавап: Юк.

## Вариант 6

1. Гамәлләрне эшләгез:

| | | |
|---|---|---|
| 1 992 + 10 909 | 320 • 105 | 14 168 : 46 |
| 30 506 + 9 138 | 203 • 407 | 197 209 : 199 |

2. Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: 560 : 7 • 10 : 5.

3*. Елгада су 3 км/сәг тизлек белән ага. Елга агымы буйлап кәгазь көймә йөзә. Көймә 1 мин та ничә метр йөзәр?

4*. Мин электр поездына ашыгам һәм 6 км/сәг тизлек белән барам. Өйдән станциягә кадәр нәкъ 1 км. Поездга өлгерү өчен миңа 20 мин вакыт җитәрме?

Искәрмәләр:
3*. Чишү: 1 км = 1 000 м. Димәк, елгада су 3 000 м/сәг тизлек белән ага. 1 мин та көймә 60 тапкырга кимрәк ара йөзәр: 3000 : 6 = 50 (м). Җавап: 50 м.
4*. 20 мин — ул сәгатьнең өчтән бере. Әгәр бер сәгатьтә 6 км барган булсам, сәгатьнең өчтән берендә мин 2 км барам. Җавап: Өлгерәм.

### IV чиреккә контроль эш

Эшнең максаты укучыларның натураль саннар өстендә дүрт арифметик гамәлне эшли белүләрен; зурлыклар арасындагы өйрәнелгән бәйлелекләрне эченә алган төзелмә арифметик мәсьәләләрне чишә белүләрен; гади тигезләмәләрне чишә белүләрен; турыпочмаклыкның периметрын һәм мәйданын таба белүләрен тикшерүдән гыйбарәт.

Турыпочмаклык төзүне (бирем 4) укучылар линейка ярдәмендә башкаралар.

**Вариант 1**

1. Гамәлләрне эшләгез:

   4 231+ 698 6 230 - 894 124·6 2 568:8

2. Кибеттә 85 кг лимон, лимоннан 3 тапкыр күбрәк апельсин, лимоннан 20 кг кимрәк мандарин сатканнар. Кибеттә барысы ничә килограмм цитрус сатылган?
3. Тигезләмәне чишегез: $a + 48 = 90$.
4. Ягы 3 см булган квадрат сызыгыз. Аның периметрын һәм мәйданын табыгыз.

5*. «Әгәр дүртпочмак якларының озынлыклары тигез булса, ул дүртпочмак квадрат була» дигән раслама дөресме?

6*. Мин мәктәптән өйгә 15 мин кайтам, ә минем иптәшемә шул ук юл өчен 3 мин артыграк вакыт кирәк. Безнең кайсыбызның тизлеге зуррак?

Искәрмәләр:

5*. Җавап: Дөрес түгел.

6*. Җавап: Минем.

**Вариант 2**

1. Гамәлләрне эшләгез:

   3 980 + 493 8 113 - 694 305 • 7 1 935 : 3

2. Чәршәмбе көнне сәяхәтче 200 км юл үтә, ә пәнҗешәмбе көнне җомга көнне барган кадәр юл үтә. Барлык юл 1 000 км була. Сәяхәтче пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрне ничәшәр километр юл үткән?
3. Тигезләмәне чишегез: $x \cdot 4 = 108$.
4. Якларының озынлыклары 3 см һәм 4 см булган турыпочмаклык сызыгыз. Аның периметрын һәм мәйданын табыгыз.

5*. Линолеумның киңлеге 2 м. Иңе 4 м һәм буе 5 м булган бүлмә идәненә линолеум җәйгәннәр. Ничә метр линолеум кирәк булган?

6*. 64 санын мөмкин булган барлык ысуллар белән ике санның тапкырчыгышы рәвешендә күрсәтегез.

Искәрмәләр:

5*. Чишү: 5 + 5 = 10 (м). Җавап: 10 м.

6*. Җавап: 64 = 1 • 64, 64 = 2 • 32, 64 = 4 • 16, 64 = 8 • 8.

**Вариант 3**

1. Гамәлләрне эшләгез:

   739 + 12 680 5 010 - 792 49 • 53 324 : 12

2. Бер-берсеннән 320 км ераклыкта урнашкан ике вокзалдан иртән 8 дә кара-каршы ике электропоезд юлга чыгалар һәм станциядә 2 сәг тән соң очрашалар. Берсенең тизлеге 85 км/сәг. Икенчесенең тизлеген табыгыз.
3. Тигезләмәне чишегез: $4000 - x = 50$.
4. Ягының озынлыгы 4 см булган квадрат сызыгыз. Аның периметрын һәм мәйданын табыгыз.
5*. Бертөрле 4 стаканга сөт салып чыкканнар. Барлык стаканнардагы сөт банкадагы сөт кадәр. Банка һәм стаканның икесендә бергә 1 кг сөт бар. Стаканда ничә грамм сөт булган?
6*. 0 гә тигез булмаган ике санның тапкырчыгышы һәрвакытта да шул саннарның суммасыннан зурракмы? Бу фикерне кире кага торган мисал китерегез.

Искәрмәләр:

5*. Банкага 4 стакан сөт керә. Ул вакытта стаканда һәм банкада 5 стакандагы кадәр сθт, ягъни 1 кг 200 г сөт була. Бер стаканда күпме сөт барлыгын беләбез: 1 200 : 5 = 240 (г). Җавап: 240 г.

6*. Һәрвакытта та түгел. Мәсәлән: 4 • 1 = 4, 4 + 1 = 5. 4 һәм 1 нең тапкырчыгышы 4 һәм 1 нең суммасыннан зуррак түгел.

## Вариант 4

1. Гамәлләрне эшләгез:

1 090 + 91 807 3 030 - 196 83 • 76 3 120 : 52

2. Зәр кглы 126 пакет бәрәңге һәм шул кадәр үк килограмм кишер китергәннәр. Кишер 2 шәр кг итеп сеткаларга тутырылган. Ничә сетка кишер китергәннәр?
3. Тигезләмәне чишегез: $y : 42 = 7$.
4. Якларының озынлыгы 5 см һәм 4 см булган турыпочмаклык сызыгыз. Аның периметрын һәм мәйданын исәпләгез.
5*. Ягының озынлыгы 6 см булган квадрат төзегез. Аның диагональләренең берсен үткәрегез. Сез һәр өчпочмакның мәйданын исәпли алырсызмы?
6*. Ярты килограмм май һәм килограмм ярым сарделька сатып алганнар. Сез барлык сатып алган әйберләрнең массасын билгели аласызмы?

## Вариант 5

1. Гамәлләрне эшләгез:

999 + 8 877 101 010 - 9 191 205·306 38 862:127

2. 315 кг кара карлыганны тигез итеп 35 кәрзингә салганнар. Мәктәп буфетына 7 кәрзин карлыган җибәргәннәр. Мәктәп буфетына ничә килограмм карлыган җибәргәннәр?
3. Тигезләмәне чишегез: 200 : $y$ = 5.
4. Буе 6 см, ә иңе 2 тапкыр кимрәк булган турыпочмаклык сызыгыз. Аның периметрын һәм мәйданын табыгыз.
5*. 5 : $x$ аңлатмасының кыйммәте 0 гә тигез булырдай $x$ ның кыйммәте бармы? Дөрес җавапны сайлап алыгыз: 1) Әйе, 5. 2) Әйе, 0. 3) Юк.
6*. Лимон тутырылган ящикның массасы 25 кг. Барлык лимонның яртысын сатканнан соң, ящикны үлчәүгә куялар. Үлчәү 15кг ны күрсәткән. Буш ящикның массасы күпме?

Искәрмә:

6*. Чишү: 25 - 15 = 10 (кг), 15 - 10 = 5 (кг). Җавап: 5 кг.

**Вариант 6**

1. Гамәлләрне эшләгез:

50 308 + 490 20 000-1992 502 106 110 250:105

2. Бер кисәктә 45 м ситсы, ә икенчесендә шундый ук 30 м ситсы бар. Барлык ситсыдан ательеда үлчәмнәре һәм фасоннары бертөрле булган 25 хатын-кыз күлмәкләре теккәннәр. Һәр кисәк ситсыдан ничә күлмәк чыккан?
3. Тигезләмәне чишегез: 30 • $x$ = 150.
4. Бер ягының озынлыгы 2 см, ә икенче ягы 3 тапкырга озынрак булган турыпочмаклык сызыгыз. Аның периметрын һәм мәйданын табыгыз.
5*. Радиусы 3 см булган түгәрәк сызыгыз. Түгәрәк эченә сыя торган иң зур кисемтәнең озынлыгы нинди?
6*. Беренче сан икенчесеннән 2 тапкырга зуррак. Әгәр кечерәк санга 4 не кушсаң, зуррак сан килеп чыга. Ул саннарны языгыз.

Искәрмәләр:

5*. 6 см (түгәрәкнең диаметры).

6*. Җавап: 8, 4.


1
2



3



4


5
6

6 + = 9



7

 − 4 = 5

8



9



10



11

12



13



14



15



16



17



18




19



20




21




22



23




24



25




26



27



28



29



30

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз........................................................................................ 3

## Дүртьеллык мәктәп

### Беренче сыйныф

I чирек............................................................................................ 9
II чирек........................................................................................ 13
III чирек ........................................................................................ 17
IV чирек........................................................................................ 25

### Икенче сыйныф

I чирек........................................................................ ............ 28
II чирек........................................................................................ 35
III чирек ........................................................................................ 39
IV чирек........................................................................................ 41

### Өченче сыйныф

I чирек ........................................................................................ 44
II чирек........................................................................................ 52
III чирек ........................................................................................ 56
IV чирек ........................................................................................ 60

### Дүртенче сыйныф

I чирек........................................................................................ 65
II чирек........................................................................................ 72
III чирек ........................................................................................ 78
IV чирек ........................................................................................ 83

## Өчьеллык мәктәп

### Беренче сыйныф

I чирек ........................................................................ 105
II чирек........................................................................ 111
III чирек........................................................................ 116
IV чирек........................................................................ 126

### Икенче сыйныф

I чирек........................................................................ 133
II чирек........................................................................ 141
III чирек ........................................................................ 150
IV чирек........................................................................ 160

### Өченче сыйныф

I чирек........................................................................ 163
II чирек........................................................................ 172
III чирек........................................................................ 179
IV чирек........................................................................ 184

Учебное издание

**Рудницкая Виктория Наумовна**

**ТЕМАТИЧЕСКИЕ И ИТОГОВЫЕ КОНТРОЛНЫЕ РАБОТЫ ПО МАТЕМАТНКЕ В НАЧАЛЬНОЙ ШКОЛЕ**

*(переβод с русского на татарский язык)*

Редакция мөдире *Р. С. Вафина*
Редакторы *Л. Х. Мөхәммәтҗанова*
Бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *М. И. Данилевская*
Корректоры *Т. Н. Сагдуллина*

Нәшриятка 183 нче номерлы лизенция 1997 елның 7 апрелендә бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 11.06.01. Форматы 60×90¹⁄ιβ.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 12,5.
Нәшер-хисап табагы 9,46. Тиражы 6 500 д. Заказ 4-25.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
. Тел./факс (8432) 92-57-48.
E-mail: magarif@mail. ru
Http: //magarif. kazan. ru/

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.